Сл. 2. Развитие идентичности как цель. Можно ли развивать идентичность? Может, речь должна идти о поддержании идентичности, укреплении ее? Тем более, что всякая цель, поставленная в стратегии в терминах процесса («развитие»), существенно снижает полезность стратегии. Цель должна ставиться в терминах результата, продукта, а не процесса. Иначе, цель «развитие», преобразованная в глагольную форму, будет звучать как «Развивать…», т. е как указание на бесконечный процесс. Тогда это не цель, а намерение. То же и о конкурентоспособности. Ее также не развивают, а усиливают, наращивают и т. п.

Интеллектуальный и культурный капитал как основа. Капитал всегда принадлежит кому-то. О чьем капитале идет речь? Укрепление инновационной ментальности – это технология? Или все же еще одна задача? Или еще одна основа? Если все же технология, то она согласуется только с понятием конкурентоспособности, но не идентичности. Как-то бы все же согласовать все три позиции слайда. Это же ключевые параметры стратегии.

Сл. 3. Адаптация татарского мира к изменяющемуся миру показывает:

а) пассивность, т. к. адаптация – это всего лишь приспособление;

б) вторичность, где изменяющийся мир – это аргумент, а татарский мир всего лишь функция. Почему не вести речь об активном взаимодействии, взаимопроникновении татарского мира и изменяющегося мира? Или поиске и определении вклада татарского мира в изменяющийся мир? Это, кстати, вполне могло бы выступать стратегической целью – понятной и измеримой, а также вдохновляющей и мотивирующей, так как понятен и очевиден результат – достойное и узнаваемое место татар в мире. Если развитие обозначено уже как цель, то почему развитие повторяется еще и как принцип. Принципы и цели – это абсолютно разные элементы концепции.

Сл. 7. Разве так уж необходим в стратегии термин «духовные скрепы»? С одной стороны, он устоялся и стал привычным, но, с другой, он слишком абстрактен для стратегии. Это метафора, которую вряд ли следует использовать в программном документе. С точки зрения стратегического менеджмента, «духовные скрепы» – это какие концептуальные элементы? Кроме того, список этих непонятных «скреп» не проходит проверку на банальность. Он не информативен и не добавляет ничего в программный документ, кроме «воды», тем самым снижая его ценность.

Сл. 8. Стиль: «разобщенность сообщества». Здесь уж или разобщенность, или сообщество?

«Разъединенность механизмов формирования элит». Разве эти механизмы соединены? И какие это механизмы?

Сл. 9. Образование, пространство и культура не есть миссия. Тем более, пространство.

Я готова включиться в дискуссию по тем сторонам стратегии, которые охватывают науку и образование. И почту за великую честь внести свою скромную лепту.

Я внимательно прочла ряд материалов, посвященных разработке стратегии, и обнаружила, что столь важного опроса так и не было проведено. Если мы согласуем небольшой список вопросов, мы можем задать их татарам, живущим за рубежом, через Фейсбук. Я готова принять участие и в разработке опросника, и в сборе результатов.

***С уважением к вам и вашему благородному делу,***
***Файруза Салихджановна Исмагилова,***

*д.психол.н., профессор,*
*приглашенный исследователь и визит-профессор*
*Люблянского Университета, Республика Словения, г. Камник.*

## РЕДАКЦИЯГӘ ХАТ

## МИН – МИЛЛӘТНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ.

Татар. Татар милләте. Бу сүзләр бик күп мәгънәне үз эченә сыйдырган. Татар милләте диюгә, күз алдына аның күп гасырлык тарихы, үткәне, бүгенгесе, киләчәге килеп баса. Бөек халкымның үткәне дә бик авыр вакыйгалар белән бәйле. Татарларны гел буйсындырырга, аның җирләренә хуҗа булырга, байлыкларын таларга теләгәннәр. Ләкин горур, бердәм халкымны дошман буйсындыра алмаган. Явыз Иван татар милләтен юкка чыгарырга, таптап, изеп, диннәреннән ваз кичтереп, чукындыруу политикасын тормышка ашырырга тели. Халкым монда да көчле булып кала, бирешми, динен гореф-гадәтләрен, телен саклап кала. Татар дигән исемен горур йөртә, гореф-гадәтләрен буыннан-буынга тапшырып, саклап килә. Милли бәйрәмебез «Сабан туй» ел саен зурлап уздырыла. Анда татар халкына гына хас милли уеннар уйнала. Көрәш, ярыш, җырлар-биюләр белән үрелеп бара бәйрәм. «Нәүрүз», «Карга боткасы», «Сөмбелә» кебек милли бәйрәмнәребез милләтебезнең йөзе булып тора. Чөнки монда халкымның милли ашлары, көй-моңнары, уен кораллары, кул эшләре барысы да чагылыш таба. Гүя өлкән буын үзенең мирасын яшьләргә тапшыра. Без яшьләр бу мирасны кабул итеп, саклап, киләчәк буыннарга тапшырырга тиешбез.

Минем уйлавымча, татар теле кебек камиль тел, тәмле һәм затлы милли ашлар, матур милли киемнәр, милли моң бары тик милләтебездә генә. Бу татар халкының чын байлыгы. Ә бу байлык киләчәктә сакланырмы, язмышы нинди булыр? Шушы сорау күпләрне борчый. Чөнки татар теле кирәкми, бу тел өйдә сөйләшер өчен генә, – дип кайберәүләр лаф ора. Балаларын рус мәктәпләренә биреп алар милләтебезнең тамырына балта чабалар. Дөресен әйткәндә, үзләре үк дөньяны аңламаган балалар тәрбиялиләр. Әби-бабай, әти-әни арасындагы милли җепләр өзелә. Балада татар каны акса да, рус телле, милләтсез кеше барлыкка килә.

Татар милләтен авыллар яшәтә. Без, авыл яшьләре, телебезне саклап, милләтебезнең киләчәге өчен борчылып яшәргә бурычлы. Без сакламасак, без якламасак, бу бай мирасыбызны кем саклар?

Саклрбыз, бездә татар каны ага, без яклрбыз. Татар халкы горур, шуңа да аның киләчәге өметле.

***Миләүшә Гарифянова***

## Милли һәм төбәк тарихын өйрәнүнең фәнни-методологик яклары

## Научно-методологические аспекты изучения национальной истории и краеведения

*Д. М. Исхаков*

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЭПИК ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЯШЕРЕНГӘН МИЛЛИ ТАРИХЫБЫЗ

### Икенче язма: «Идегәй» дастанының серләре

*(Дәвамы. Башын карагыз: № 4, 2018; № 1, 2019).*

### Алтын Урда, Ак Урда һәм Бүз Урда...

«Идегәй» дастанын өйрәнгәндә тагы бер, шактый катлаулы һәм фәндә әле дә чишелеп бетмәгән, мәсьәлә буенча яңа фикер әйтергә мөмкинлек туа – сүз Җучи Олысының үз атамасы турында. Бу турыда бара торган бәхәсләрнең нигезендә берничә проблема ята: беренчедән, аның ике өлешкә бүленеп – Ак һәм Күк Урдаларга – кайсы өлешенең ничек аталуы буенча; икенчедән, Алтын Урда (русча «Золотая Орда», инглиз телле әдәбиятта, русчадан калька рәвешендә, «Golden Horde») терминының барлыкка килүе (генезисы) һәм мондый атаманың Җучи Олысының гомуми исеменә әйләнүенең сәбәпләре.

Шул уңайдан тарихи әдәбиятта таралган «Алтын Урда/Золотая Орда» төшенчәсенең историографиягә рус әдәбияты аркылы керүе турындагы карашның [Кушкумбаев: 2017-а. С. 356] дөреслеге мәсьәләсе дә бар. Соңгы карашның нигезе – XVI-нчы гасырның икенче яртысына караган «Казанская история/Казанский летописец» дип аталучы рус чыганагына барып тоташа, чөнки ул әсәрдә чынлап та «царство Златыя Орда царя Ахмата», «Золотая Орда», «великие Орды Златыя» дигән атамалар очрый (карагыз: [Казанская история: 1954. С. 45, 49, 53, 55]). Ләкин бу фикер башка бер, европалы автор язган хезмәттәге, мәгълүмат тарафыннан юкка чыгарыла. Бу очракта без баварияле солдат (ул Идегәй дәверендә Җучи Олысында хезмәт итә) Иоганн Шильтбергер хезмәтен истә тотабыз. Ә ул автор исә шушы дәүләт турында язганда, аңа карата «Алтын Татария/Золотая Татария» һәм «Бөек/Олуг Татария/Великая, Большая Татария» яисә «Татария» генә дигән терминнарны куллана [Шильтбергер: 1984. С. 33–34, 43, 44–46]. «Татария» төшенчәсен «Татар иле» дип карап булганга, аның «Урда», ягъни, дәүләт булып оешкан татарлар берләшмәсен аңлатканлыгын тө-

шенергә мөмкин [Исхаков: 2007]. Кыскасы, «Татария» ул шул ук «Урда» дигән терминның калькасы. Моннан күренә – XV-нче гасыр башында инде Жучи Олысына карата ике атама кулланылган – «Алтын/Золотая Татария/Урда» һәм «Олуг (Бөек) Татария/Урда». Чынлыкта «Казанский летописец» исемле хезмәттә дә нәкъ шушы ук терминнар кулланыла (андагы «великие Орды Златыя» «Олуг/Бөек» һәм «Алтын/Золотая» Орда («Татария») төшенчәләрен чагылдыра дип уйлыйбыз). Әгәр дә без тагы бер документны – 1393-нче елны Туктамыш ханның Литваның бөек князе вә Ляхистанның (Польшаның) короле Ягайлога язган хатын карасак, анда Алтын Урданың «Олуг Олыс» дип исемләнгәнен күрә алабыз [Özyetegin, Kemeloğlu: 2017. S. 40–41]. Монда «Олыс» – «Урда» төшенчәсен чагылдыра.

Менә шушы ике рәт атамалар булуы – «Алтын» һәм «Олуг» Олыс/Урдалар – аңлатуны таләп итә дә, чөнки бу ике терминның үзара мөнәсәбәтләре бик үк аңлашылып бетми. Моңарчы алар арасындагы бәйлелекне Жучи Олысында хөкем иткән Чыңгызыйларның сәяси үзәге – кабул итүләр дә алып барыла торган ставкасының, «алтын» термины белән билгеләнүе аркылы аңлаталар иде (карагыз: [Федоров-Давыдов: 1973. С. 64–67; Исхаков, Измайлов: 2007. С. 83–84]). Бу фикер тулаем алганда дөрес булса да, ул тикшерелә торган мәсьәләнең кайбер якларын бик үк аңлатып бетерми – мәсәлән, «Ак Урда» белән «Алтын Урда» төшенчәләренең үзара мөнәсәбәтләре нинди булганлыгын. Ачык күренә бит, бу ике термин арасында эчтәлек ягыннан аерымалыклар бар, аларның мәгънәләре бер үк түгел. Менә шуңа күрә дә безгә «Идегәй» дастанына мөрәҗәгать итү кирәк, чөнки анда булган мәгълүмат, безнең фикеребезчә, югарыда куелган сорауларга тулырак һәм тарихи яктан дөресрәк итеп җавап бирергә мөмкинлек бирә.

«Идегәй» дастанының татарлар арасында табылган вариантларында мондый юллар бар:

Алтын Урда, Ак Урда
Алтмыш йортка юл иде [Идегәй: 1988. 20 б.].

Монда «Алтын Урда» һәм «Ак Урда» терминнары бер-берсен алмаштыручы, тәңгәл булган төшенчәләр буларак кулланыла. Әмма, «Алтын Урда» төшенчәсе эпосның татар версияләрендә аерым да кулланыла, мәсәлән, аның соңгы юлларында:

*Идел-Урал буйлары татарлары варианты*

Кырым, Казан, Әждаркан
Башлы-башлы ил булды,
Алтын Урда таралды
[Идегәй: 1988. 245 б.]

*Кырым татарлары варианты*

Алтын Орду торкъалды,
Хан сарайы къалмады.
Къырым, Казан, Аждархан
Айры-айры иль болды
[Къырымтатар: 1991. 57 б].

Башка халыклар арасында таралган дастан вариантларында бу төшенчә – «Алтын Урда» термины – күренми, шул исәптән, нугайларда да. Әмма, аларда башка бер термин бар. Ул – «Ак Урда» төшенчәсе. Мәсәлән, эпосның нугай версияләрендә «алтмыс/туксан басты Ак Урда» дигән билгеләмәләр бар [Эдигэ: 2016. 79, 84, 302 бб.]. Шуңа охшаган термин дастанның казах версияләрендә дә очрый – «Еңесі биік Ак Орда», «Алты канат Ак Орда» [Кушкумбаев: 2015. С. 41; Эдіге: 1989. С. 90]. Исегезгә төшерик, Идел-Урал буе татарларында да «алтмыш/туксан башлы Урда» термины күзәтелә, ләкин ул «ак» дип билгеләнми. Әмма, татарларның «Идегәй» эпосында «Ак Урда» термины барыбер килеп чыга. Ул Идегәйнең үзенең улы Морадымга (Нур-ад Дингә) әйткән сүзләреннән күренә:

Алтын тауга барганмын,
Түрә булып алганмын,
Халкын җыеп алып килеп,
Ак Урдага салганмын, – ди Идегәй [Идегәй: 1988. 21 б.].

Тикшерелә торган мәсьәлә турында сүз алып барганда, эпостагы «Алтын Урда», «Ак Урда» төшенчәләрен куллануның бер нюансы барлыгын искәртеп китү кирәк: дастанга «урда» терминын хан ставкасына карата куллану да, аңа якынайтырга тырышу да хас. Мәсәлән, «Идегәй» дастанында әйтелә:

Алтыннан суккан урдасын,
Көмештән суккан ишеген
Төсе суык чын булат
Очы белән ачмасам… [Идегәй: 1988. 85 б.].

Эпосның нугай һәм казах версиләрендә дә шундый ук мәгънә салынган:

*Ногай варианты*
Алтындан сокган ак орданын
Көмештен соккан ак эсик
Туъссе сувык чын болат
…………………………[Эдигэ: 2016. 84, 88, бб.].

*Казах варианты*
Алтын соққан Ақордаң,
Күмістен соққан ақ есік [Кушкумбаев: 2017–а. С. 359].

Күренә ки, бу очракта сүз дәүләт, халык турында түгел, ә ставка – чатыр, тирмә турында бара. Шулай булгач, Алтын Урда/Ак Урда төшенчәсенең ике мәгънәсе барлыгы ачыла – ул, бер яктан, сәяси берләшмәне – дәүләтне белдерсә, икенче яктан аның сәяси үзәген – хан ставкасын аңлаткан.

Шул ук хәлне без эпоста параллель рәвештә кулланылган «Бүз Урда» төшенчәсе буенча да күзәтә алабыз. Беренчедән, дастанның татар, казах һәм нугай версияләрендә «Ак Урда» урынына «Бүз Урда» атамасы да кулланыла. Мәсәлән, «Иңәсе биек Бүз Урда» [Идегәй: 1988. 78, 81 бб.], «Энегесе бийик Боз Урда» [Эдигэ: 2016. С. 38, 85, 163, 183, 211, 278], «Еңсесі биік Боз Орда» [Кушкумбаев: 2015. С. 40]. Бер караганда, монда сүз дәүләт турында бара һәм «Бүз/Боз Урда/Орда» термины «Алтын Урда/Ак Урда» төшенчәсен алыштыра кебек. Казах тарихчысы А.К. Кушкумбаевның моның шулай икәнлегенә басым ясап, «Бүз/Боз Урда/Орда» төшенчәсенең «аксыл/якты» мәгънәсе барлыгын күрсәтеп, аның «Ак Урда» урынына күчмәләрдә кулланылган образлы-метафорик термин булганлыгын искәртүен искә алсак [Кушкумбаев: 2015. С. 41], бу бигрәк тә шулай. Ләкин, икенче яктан караганда, «Бүз Урда» дигән төшенчә дә дастанда югарыда әйтелгән «сәяси үзәк, хан ставкасы» термины мәгънәсенә ия. Әйтик, дастанның нугай версияләрендә мондый юллар бар:

Каслы, каслы, каслы орда,
Босагасы боз орда,
Босагасы болаттан,
Болатка алтын ялаткан [Эдигэ: 2016. С. 214, 289].

Бу очракта шушы «Урданың» үзенең «Алтыннан суккан», ишегенең «көмештән суккан» икәнлеге турындагы югарыда китерелгән җөмлә белән турыдан-туры мәгънәви охшашлык барлыгы ярылып ята. Шулай ук, дастанның казах версияләрендә күренгән «Алты канат Ак Орда» дигән термин да дәүләткә түгел, ә ставка – чатырга карарга мөмкин, чөнки Алтын Урдада/Ак Урдада «алты канат» бер вакытта да булмаган, алар икәү генә (уң, сул канатлар). Тагы бер уйландыра торган төшенчә – «Иңәсе биек Бүз Урда/Ак Урда». Бу сүзләрне тәрҗемә иткәндә А.К. Кушкумбаев «иңәне» «биек» сүзе белән бергә «высоковерхая», «высокая, просторная» дип тәрҗемә итеп [Кушкумбаев: 2015. С. 40–41], аңа дәүләтне аңлатучы термин буларак карарга кирәклегенә ишарә ясый. Чынлыкта исә бу терминологик рәт тә дәүләтне түгел, ә хан ставкасын, чатыр/тирмәне белдерә булса кирәк. Нәкъ менә шул чатырның кырыйлары – иңгәләре, биек булган булырга тиеш. Әйтик, дастанның нугай версияләренең берсендә (русча гына сакланган), Джамбай Идегәйгә әйтә: Туктамыш ханга кил дә «припади к его ногам в его высоком (игътибар – Д. И.) белом шатре», – дип [Эдигэ: 2016. С. 56].

Хәзер безгә инде тарихи материалларга таянып тикшерелә торган мәсьәләгә ачыклыклар кертеп китү мөмкин. Ул эшне башкарганда үзебезнең (карагыз: [Исхаков: 2014] бер хезмәткә һәм А.К. Кушкумбаевның

[2015; 2017-а; 2017-б; 2017-в] элегрәк басылган хезмәтләренә таянып эш итәрбез. Алга таба китерелгән фикерләрнең кайбер детальләрен, монда язылмаган очракта, шул мәкаләләрдән карарга кирәк.

### Ак Урда төшенчәсе

Тарихи чыганаклардан Җучи Олысындагы тәхет куелган үзәкнең, ягъни, хан ставкасының XIII-нче гасырда ак төстәге тирмә/чатыр булганлыгы турында мәгълүмат сакланган. Әйтик, Абуали Шафи б. Мөхәммәт (Каһирә шәһәрендә 1329/30-нчы елны үлгән) үзенең елъязмаларында Берке ханнан Мисырга Бейбарс солтан янына килгән илчеләреннән ишеткәннәр турында яза: «Они разъяснили ему (солтанга – Д. И.) все, о каждой должности отдельно, равно как о том, что у него (Беркедә – Д. И.) войлочный шатер, в котором помещается 500 всадников и который внутри отделан жемчужинами и драгоценными камнями» [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 70]. Менә шушы бик зур «киез чатыр» (тирмә) турында аль-Муфаддаль исемле Мисыр елъязмачысы (информациясе 1259–1341 елларга карый) хезмәтендә Бейбарс илчелегенең Берке хан вакытында Җучи Олысына баруы турында язмада тулырак яза. Бу автор әйтә: «...царь Берке ... находился в большом шатре, в котором помещается 100 человек (башка вариантларда – «500 человек/всадников»), покрытом белым войлоком (менә ул Ак Урда! – Д. И.), внутри обитом шелковыми материями и китайками и украшенным жемчужинами и драгоценными камнями. Он (хан) сидел (там) на престоле...» [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 92–93, 97]. Бу чатырны Плано Карпини һәм Вильгельм Рубрук та күргәннәр. Беренче автор Бату ставкасында булганда «чатырларны» искә төшерә һәм әйтә: «... алар бик зур һәм матур иделәр, тукымадан эшләнеп, элек венгр короленыкы булганнар», – дип [Карпини Плано Джованни: 1997. С. 73]. Димәк, сүз бу очракта хәрби трофейлар турында бара. Шул ук чатырны Вильгельм Рубрук да тасвирлый: «...безне палатка уртасына кадәр керттеләр... [Анда Бату] озын, ятак кебек киң тәхет урынында тәхеттә утыра һәм ул бөтенләе белән алтынланган иде...» [Де Рубрук Вильгельм: 1997. С. 117]. Моннан аңлашыла – чатыр эчендә алтын белән капланган тәхет урыны (престол) да булган. Шуңа күрә дә без Ак Урдадан әкренләп Алтын Урдага күчә алабыз һәм ул күчешне гарәп сәясәтчесе Ибн Баттута хезмәтенә таянып ясарга мөмкин.

### Алтын Урда төшенчәсе

Ибн Баттута, Җучи Олысында Үзбәк хан дәверендә булып, үзенең шәхси күзәтүләренә нигезләнеп, хан чатыры турында яза: «...Җомга көнне, намаздан соң» хан «алтын чатыр дип исемләнүче (димәк, бу – Алтын Урда – Д. И.), бизәлгән һәм хикмәтле чатырга кереп утыра». Чатыр

«алтын белән капланган агач рәшәткәләрдән тора..., аның уртасында агач тәхет урыны торып, ул алтын йөгертелгән (исегездәме югарыдагы «алтын ялатылган» дигән фраза дастаннан? – Д. И.) [иде]; аның аяклары көмештән, ә өске ягы кыйммәтле ташлар белән бизәлгән», – ди бу автор. Ибн Баттута дәвам итә: «Солтан (Үзбәк хан – Д. И.) шушы тәхеткә утыра». Алга таба ул, бик тәшвишләп, чатырда кемнең (ханның хатыннарының, балаларының, бәкләренең) кайсы урында утырганлыгын күрсәтә [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 132–133].

Шулай итеп, безнең каршыбызда Җучи Олысының чәчәк аткан дәверендәге сәяси үзәге – Алтын Урданың, хан ставкасының, тасвирламасы килеп чыга. Әле бу зур чатыр Урда күчеп йөри торган урыннарда кулланылган, ә кыш көннәрендә исә ханнар һәм аның бәкләре далада түгел, ә Сарай шәһәрендә яшәгәннәр. Аларның яшәгән биналары турында язганда (үз күзләре белән күреп!), Ибн Баттута солтанның (Үзбәк ханның) андагы сарае турында да мәгълүмат бирә – аның исеме «Алтынташ» булганлыгын әйтеп, гарәп сәяхәтчесе атаманың беренче өлешен алтын белән бәйли, ә икенче кисәген – «таш» төшенчәсен, «баш» дип тәрҗемә итә [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 143]. «Идегәй» дастанының татар версиясендә дә Сарай (шәһәр булса кирәк) белән бергә «Сары мәрмәр Алтын Таш» шулай ук искә алына [Идегәй: 1988. 166 б.]. Ләкин бу урынны дөрес аңлау өчен безгә әл-Омари хезмәтенә мөрәҗәгать итү кирәк. Ибн Фадлаллах әл-Омари (1348/49-нчы елны үлгән) үзенең тарихи-географик хезмәтендә Сарай шәһәрендә «патша һәм аның якыннарының» кыш көне яши торган «зур сарае» булуын күрсәтеп, ул урынның «стеналар, башня һәм әмирләрнең өйләре белән әйләндереп алынганлыгын» да әйтә һәм хан сараеның авырлыгы «ике мисыр кантыры» булган «алтын ярымай» белән төгәлләнгәнлеген күрсәтә [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 109]. Шуңа күрә, бәлки, сарайның исеме «Алтынбаш» булгандыр, ягъни, мәгънәсе ягыннан «златоглавый/алтынбашлы» килеп чыгарга мөмкин. Менә шушы алтын белән бәйле сарайны А.К. Кушкумбаев Җучи Олысы хөкемдарларының официаль резиденцияләренең кышкы (стационар) варианты итеп карарга тәкъдим итә [Кушкумбаев: 2015. С. 40]. Без бу фикер белән тулысынча килешәбез.

Тикшерелә торган «Алтын Урда» исемле чатыр, чынлап та булган һәм бер тарихи чыганактан без аның кайчан юкка чыканын да белә алабыз. Ул турыда Үтәмеш-хаҗиның «Чыңгыз намә» исемле әсәрендә түбәндәге мәгълүмат китерелә. Үзбәк ханның хатыны Тай-Дула бегим, хан үлгәннән соң, Хызырны чакырып китереп аны хан иткәч, «туй бүләге итеп ул Үзбәк ханнан һәм Җанибәк ханнан калган алтын юртаны куйган». Ләкин, Хызыр хан аны хатынлыкка алудан баш тарткач, Тай-Дула бегим аңа кар-

шы хәрәкәт итә башлый. Шул вакытта ачуы чыккан хан «алтын юртаны ватып, аның алтынын үзенең казаклары арасында бүлергә уйлый». Бегим шунда хан янына кеше җибәреп, әйтә: «...Алай эшләмәсеннәр. Алтын белән көмеш булмаганда хан булган кеше өчен бу [алтын юрта] – байлык. Башка яхшы кешеләр тарафыннан төзелгән бинаны җимермәсеннәр», – дип. Ләкин Хызыр хан аның сүзләрен тыңламый һәм ул юртаны «ватып аны бүлә» [Утемиш-хаджи: 1992. С. 112].

Шулай итеп Җучи Олысының сәяси үзәге булган «Алтын Урда»/«Алтын юрта» юкка чыга. Бәлки бу чыганактагы мәгълүмат аллегорик мәгънәгә иядер, ягъни Алтын Урданың таркала башлаганлыгын белдерүче бер билгедер, әмма, шулай булса да, монда тарихи факт та чагыла төсле – «Алтын юрта» чынлап та ватыла, ахрысы.

## Бүз Урда төшенчәсе

Шушы төшенчәнең мәгънәсен тикшергәндә, Үтәмеш-хаҗиның «Чыңгыз-намә» исемле хезмәтендәге бер урынга игътибар итәргә кирәк (ул турыда казах тарихчысы А.К. Кушкумбаев язган иде – карагыз: [Кушкумбаев: 2017-а]). Бу әсәрнең авторы Шибан, Туктамыш, Тимур-Кутлуг һәм Урус ханнарның варисларының үзара мөнәсәбәтләрен тасвирлаганда – ә сүз аларның кайсысының даладагы социаль иерархияда югарырак, кайсысының түбәнрәк булуы турында бара – мондый бер тарихи легенда китерә.

Имеш, Чыңгызхан Җучиның улларына юрталар куеп, киңәш (корунш, корылтай) үткәрә һәм анда Җучи Олысын бүлү мәсьәләсе карала. Шул вакытта Саин ханга (Батуга) уң канат бирелә (Идел һәм аның виләйәтләре), ә Эҗәнгә (Орда-Иченга) сул канат эләгә (Сыр елгасы һәм аның буендагы виләйәтләр). Шушы вакыйгалар барган вакытта, Чыңгызхан Җучиның уллары өчен мондый юрталар куйдыра: «Алтын босагалы ак өргәне Сайын ханга [Батуга] салды, күмүш босагалы кок орданы Эҗәнгә [Орда-Иченга] салды, болат босагалы боз орданы Шәйбанга салды» [Утемиш-хаджи: 1992. С. 92, 93, 121]. А.К. Кушкумбаевның фикере буенча, «өргә» дигән термин монголларда булган «урга» төшенчәсен белдереп, хөкем итүчеләрнең чатыр-ставкасын чагылдыра [Кушкумбаев: 2017-а. С. 356]. Шуңа күрә дә Батуга (Сайын ханга) бирелгән юртаның тулы атамасы «Алтын бусагалы ак урга/урда» булып чыга. Соңгы ике Чыңгызыйның юрталарын тасвирлаганда аларның исемнәрендә «урга» урынына инде «урда/орда» сүзе кулланыла. Игътибар итик, Шибанга бирелгән юртаның атамасы – «болат босагалы боз орда». Шулай итеп, монда «Боз Орда» төшенчәсе килеп чыга.

Билгеле, А.К. Кушкумбаев язганча – ә без аның белән тулысынча килешәбез – бу легендар хикәяттә Җучи улларына урдалар – юрталар бирү символик булса да, алар аркылы Җучиның нәселе эчендәге иерархия бил-

геләнә: бусагасы алтын булган Ак Урда ханнары – Батуидлар – өлкәнрәк, ә бусагасы көмештән булган Күк Урда ханнары – Ордуидлар – түбәнрәк дәрәҗәле булып чыгалар. Шибанидларга исә булат бусагалы Бүз Урда ханнары буларак тагы да түбәнрәк урын калдырыла.

Димәк, дастандагы «Бүз Урда» төшенчәсе «Ак Урда» термины белән тәңгәлләштерелсә дә (моны «бүз» дигән сүзнең «ак, аксыл» дигән сүзгә мәгънәви яктан якынлыгы да күрсәтә; мәсәлән, «акбүз ат» – ул «аксыл төсле» атны аңлата), ул берникадәр дәрәҗәдә мөстәкыйль җисем буларак та карала ала. Әмма, төсләр чагыштырмасыннан чыгып карасаң, башта «Бүз Урда» халкы «Ак Урдга», ягъни, Җучи Олысының уң канатына кергән дип уйларга туры килә. Бу турыда бәхәсләр барса да, безнең элегрәк язган фикеребез шушы караштан чыгып әйтелде [Исхаков: 2009; 2013], кайбер башка галимнәр дә шундый ук карашны белдерделәр [Парунин: 2015].

Әгәр дә тарихи чыганаклардан чыгып эш итсәк, Батуидлар хөкем иткән Җучи Олысының көнбатыш өлеше – уң канаты – башта «Ак Урда» исемен алып (ә ул ак төстәге хан ставкасы – Ак чатыр/юрта/урда, атамасыннан), соңыннан «Алтын Урда» (Алтын белән бизәлгән «Алтын чатыр/урда» атамсыннан) төшенчәсенә бәйле рәвештә карала башлый. Шуңа күрә дә «Идегәй» дастанында бу ике термин синонимнар буларак кулланыла. Ә менә «Бүз Урда» төшенчәсе без тикшергән эпоста искә алынса да, күбрәк «чатыр/юрта/ставка» мәгънәсенә ия. Бәлки, ул берникадәр дәрәҗәдә шактый иртә юкка чыккан (Үзбәк хан дәверендә яисә бераз соңрак) «Күк Урда» терминын алмаштыргандыр. Ул алмашу Җучи Олысындагы XIV-нче йөзнең 60-нчы елларында башланган сәяси кризистан соң Күк Урда һәм Шибанидлар Олысы (Бүз Урда) ханнарының дәүләтнең уң канатына үтеп кереп, анда идарәгә килүләре белән дә бәйле булырга мөмкин.

Тулаем алганда, «Алтын Урда» атамасы Җучи Олысның чын исеме түгел, аның дөрес, официаль атамасы, 1393-нче елда язылган Туктамыш ханның хатында күренә – «Олуг Улыс». Нәкъ шул төшенчәне соңыннан рус документларында таралган дәүләтнең төп варисы булган һәм «Саин урынын» («Саинов стул»), ягъни, Алтын Урданың ставкасын, саклаучы «Большая Орда» дип исемләнүче дәүләткә бирәләр.

Әмма, «Идегәй» дастанында «Ак Урда/Алтын Урда» терминнарының сәяси үзәге/хан ставкасы мәгънәсе ачык күренсә дә, аларның дәүләти берләшмәне билгеләгән мәгънәсе дә чагыла. Әйтик, Котбның «Хөсрәу вә Ширин» исемле әсәрендә (ә ул Тинибәк б. Үзбәк ханга бүләк итү өчен язылган) «Ак Урда» дәүләт буларак атала [Парунин: 2015. С. 56]. Шуңа күрә дә без Иоганн Шильтбергердагы «Алтын Татария/Олуг (Бөек) Татария» терминнарының Җучи Олысына, ягъни дәүләткә, карата кулланылганын, күзәтә алабыз (карагыз: [Парунин: 2015. С. 55]). Моннан шундый нәтиҗә килеп

чыга: «Алтын Урда» төшенчәсен Җучи Олысына карата куллану, әгәр дә аның килеп чыгышын дөрес итеп аңлатсаң, чынлыкта мөмкин.

Шушы атама турында тарихи чыганакларда кызык кына мәгълүматлар да бар. Әйтик, Кытай чыганакларында Җучи Олысы «Цзинь жань хань»/«Ханство Золотой Юрты» дип исемләнгән [Кычанов: 2000. С. 157]. Үз чиратында, бу атаманың инде без карап үткән Үтәмеш-хаҗидагы «Алтын юрта» һәм «Алтун босагалы Ак өргә/урда» белән бәйләнгән булуы ачык. Әмма, Җучи Олысына кадәр «Олуг Алтын урда» (оригиналда – «Урду-и-заррин-и-бузург»/«Большая Золотая ставка») әле Чыңгызхан ставкасы буларак 1224-нче елны ук Монгол империясендә билгеләп үтелә. Ахрысы, нәкъ шул сәяси үзәкне кытайлылар Пен Да-я һәм Сюй-Тин үзләренең «Хэй-да ши-лю» («Кара татарлар турында кыскача хәбәрләр») исемле хезмәтләрендә искә алалар: «...Алтын чатыр (тирмә) эчендә берничә йөз кеше сыя...» Аны Плано Карпини да күрә: «...был приготовлен ... шатер, называемый у них Золотой Ордой» (димәк бу шул ук «Урду-и-заррин-и-бузург» – Д. И.) [Исхаков: 2014]. Шундый ук ставка (берсе җәйге, икенчесе – кышкы) Юань империясендә Хубилай каан вакытында да булган һәм Марко Поло аның тасвирламасын калдырган [Поло Марко: 1998. С. 251, 261–263]. Ахыр чиктә, бу «Алтын Урда» дигән ставка куерю традициясе бик ерак заманнарга барып тоташа – ул борыңгы төрки каһанлыкларда да билгеле [Кушкумбаев: 2017-б.; 2017-в.].

«Идегәй» дастанында кабатлана торган «алтыннан суккан урда» [Идегәй: 1988. 85 б.; Эдигэ: 2016. С. 84], «босагасы алтын сарай», «босагасы болаттан, болатка алтын ялаткан» [Эдигэ: 2016. С. 246, 263, 289] дигән сүзләр татарлар һәм нугайлар арасында иске рухи традицияләрнең XIV–XV-нче йөзләрнең чикләрендә әле яшәгәнлеген күрсәтәләр. Ә кырым татарларындагы дастан версияләрендә Идегәйнең улы Нуретдинның Туктамыш ханга әйткән сүзләре моны тагы да ныгыта:

Алтын Сарайны къурдургъан
Алтын босагъа аъойдырган
Чыңгызмын, – ди бер Чыңгызый [Къырымтатар: 1991. С. 46]

Шулай итеп, «Идегәй» дастанын ныклап өйрәнеп, анализлап карасаң, аннан милли тарихыбызны баета торган бик күп яңа мәгълүмат табарга була.

Алдагы язмабызда инде вәгъдә ителгән «Чура батыр» дастанына тукталырбыз һәм ул әсәр безне Алтын Урданың сәяси һәм мәдәни варислары булган татар ханлыкларының XVI-нчы йөзнең беренче яртысы тарихларына, ягъни, «Идегәй» дастаныннан 100–130 еллар соңрак булган дәвергә, алып керер. Ул дәвернең исә үз проблемалары һәм үзенчәлекләре

булган һәм безгә аларны шушы дастан аркылы күрергә һәм аңларга мөмкинлек бар.

*(Дәвамы бар).*

**Әдәбият:**

Золотая Орда в источниках. Т. I. Арабские и персидские сочинения. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды, в переводах В. Г. Тизенгаузена. Ч. I. Извлечения из сочинений арабских. Ч. II. Извлечения из сочинений персидских. Сост., ввод. ст. и коммент. Р. П. Храпачевского. М., 2003.

Идегәй. Татар халык дастаны. Казан: Татар кит. нәшр., 1988.

Исхаков Д. М., Измайлов И. Л. Этнополитическая история татар (III – середина XVI вв.). Научное издание. Казань: РИЦ «Школа», 2007.

Исхаков Д. М. Улус Джучи: татарская или монгольская держава? // Сборник материалов Международного конгресса «Российская историческая наука на современном этапе: перспективы исследования и реализации национальной образовательной политики» (Казань, 18–19 апреля 2007 г.). Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2007. С. 293–300.

Исхаков Д. М. Исторические очерки. Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 2009.

Исхаков Д. М. Между Булгаром и Казанью: Этнополитические процессы в Булгарском (Казанском) вилаяте в 60–70-х годах XIV – 40-х годах XV веков. Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 2013.

Исхаков Д. М. Золотоордынская этнология татар: Эпический и исторический «золотой трон» («алтын тәхет») // Золотоордынское обозрение. Golden Horde Review. 2014. № 3(5). С. 175-190.

Казанская история. Под-ка текста, вступ. ст. и прим. Г. Н. Моисеевой. Под ред. чл.-корр. АН СССР В. П. Андриановой-Перетц. М. – Л.: Изд-во АН СССР, 1954.

Карпини Джованни дель Плано. История монгалов // История монгалов / Дж. дель Плано Карпини. – 3-е изд. – Путешествие в Восточные страны / Г. де Рубрук. – 3-е изд. – Книга Марко Поло. – 4-е изд. / Вступ. ст., коммент. М. Б. Горнунга. – М.: Мысль, 1988. С. 30-85.

Кушкумбаев А. К. «Ак Орда» в тюркском эпическом жыре «Ер Едiге»// Золотая Орда: история и культурное наследие. Сб. научных материалов / отв. ред. А.К. Кушкумбаев. Астана: ИП «BY-PRINT» 2015. С. 36–42.

Кушкумбаев А. К. «Алтын Орда»: об одном символе власти в империи Джучидов // Байырғы түрiк құндылыiтары – 2017. Халыiаралыi ғылыми–теориялыi және практикалыi конференциясының моiалалар жинағы. – Астана: ЕҮУ баспасы, 2017 (а). С. 356–361.

Кушкумбаев А. К. «Болат босағалы боз орданы Шәйбанѓә салды»: «Йүз Орда» или «Боз Орда» в восточных источниках // XIII Фаизхановские чтения. Наследие Золотой Орды в государственных и культурных традициях народов Евразии. Материалы Международной научно-практической конференции (С.-Петербург, 4–6 мая 2016 г.). К 750-летию образования Золотой Орды. – М.: Изд. дом «Медина», 2017 (б). С. 84–91.

Кушкумбаев А.К. Термин «Орда» в кочевых империях Центральной Азии (домонгольское время) // Золотоордынская цивилизация. 2017. № 10. С. 84–91.

Кычанов Е. И. «История династии Юань» («Юань ши») о Золотой Орде // Историография и источниковедение истории стран Азии и Африки. СПб.: Изд-во С.-Петербургского ун-та, 2000. Вып. 19. С. 146–157.

Къырымтатар халкъ агъыз яратыджылыгъы. Хрестоматия. Тертип этиджи Дж. Бекиров. – Ташкент: «Ўқитувчи», 1991.

Парунин А. В. Сведения об Ак Орде в свете устной исторической традиции // Золотая Орда: история и культурное наследие. Сб. научн. Материалов. Астана: ИП «BG-PRINT», 2005. – С. 52–61.

Поло Марко. Книга Марко Поло // История монгалов / Дж. дель Плано Карпини. – 3-е изд. – Путешествие в Восточные страны. / Г. де Рубрук. – 3-е изд. – Книга Марка Поло. – 4-е изд. / Вступ. ст., коммент. М. Б. Горнунга. – М.: Мысль, 1998. С. 192–380.

Рубрук де Гильом. Путешествие в Восточные страны // История монгалов / Дж. дель Плано Карпини. – 3-е изд. – Путешествие в Восточные страны / Г. де Рубрук. – 3-е изд. – Книга Марко Поло. – 4-е изд. / Вступ. ст., коммент. М. Б. Горнунга. – М.: Мысль, 1998. С. 88–189.

Утемиш-хаджи. Кара таварих / Транскр. И. М. Миргалеева, Э. Г. Сайфетдиновой, З. Т. Хафизова; пер. на рус. яз. И. М. Миргалеева, Э. Г. Сайфетдиновой; общая и научн. редакция И. М. Миргалеева / Серия «Язма мирас. Письменное наследие. Textual Heritage» Вып. 4. Отв. ред. выпуска И. М. Миргалеев. – Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017.

Федоров-Давыдов Г. А. Общественный строй Золотой Орды. – М., 1973.

Шильтбергер И. Путешествие по Европе, Азии и Африке с 1394 года по 1427 год. Пер. с немецкого Ф. К. Бруна. Изд., ред. и прим. академика АН Азерб. ССР З. М. Буниятова. – Баку: Изд-во «Элм», 1984.

Эдіге // Батырлар жыры. Т. V. Қырымның кырық батыры (Мұрен жыраудан жазылган мұралар). – Алматы: «Жазушы», 1989. 70–95 бб.

Эдигэ: Ногайская эпическая поэма / Под ред. Н. Х. Суюновой; Карачаево-Черкесский ин-т гум. исслед. при Правительстве КЧР. – М.: Наука, 2016.

Özyetgin A. Melek, Kemaloğ I. Altin Orda Hanliğina ait Resmi yazişmalar. Ankara: Tűrk Tarih Kurumu, 2017.

# ДРЕВНИЕ ТАТАРЫ В ЦЕНТРАЛЬНОЙ АЗИИ (VI–IX вв.)

***И.Л. Измайлов***

***Аннотация:*** *Древнейшее прошлое татар, как и других тюркских народов, можно реконструировать только на основании комплексного исследования сведений лингвистических, археологических и исторических данных. Но и подобный анализ представляет общий абрис развития тюркских народов, без детализации. Однако уже в период раннего средневековья по истории татар появляются источники, прежде всего, собственно тюркские рунические памятники, которые позволяют реконструировать военно-политическую историю татар в VI–IX вв., а также проследить их локализацию в тюркскую эпоху в Центральной Азии, связав их территорию проживания со средним и нижним течением р. Селенги и Забайкальем. В период Уйгурского каганата татары оказались встроены в его государственную систему. После гибели каганата в 840 г. уйгуры и татары рассеялись по степи, основав ряд новых государств и племенных союзов.*

***Ключевые слова:*** *тюрки, прародина, этногенез, отуз-татары, уйгуры, токуз-огузы, Тюркский каганат, Уйгурский каганат.*

**Происхождение татар: бесконечная даль истории.** Древнейшее прошлое татар, как и других тюркских народов, уходит корнями, если сказать словами известного отечественного этнолога и антрополога В. П. Алексеева, «в бесконечную даль истории», когда в период каменного века еще не существовало четкого разделения между небольшими родоплеменными группами и их языками. Это было время, когда большие территории были заняты родственными общинами охотников и собирателей. Язык каждой общины был близок и понятен соседям, но по мере удаления он менялся, и далекие друг от друга общины, хотя и являлись в прошлом родственными, часто уже плохо понимали друг друга. Все это языковое многообразие специалисты называют «лингвистической непрерывностью» и объединяют в единую алтайскую языковую семью. Языковеды считают, что тюркские, монгольские и тунгусо-маньчжурские, а также ряд других языков, имеющих определенное сходство в лексике и фонетике, восходят к единому языку-основе.

До недавнего времени считали, что Алтайская языковая семья была ответвлением еще более общей Урало-Алтайской семьи. Постепенно в процессе удаления и территориального, и исторического, общины все

более отдалялись друг от друга и становились более самостоятельными, но сохраняли целый ряд общих черт. Период распада алтайского единства разные исследователи определяют по-разному. Но в последнее время лингвисты склоняются к датировке этого события VIII–VII вв. до н.э. Согласно современным взглядам лингвистов праалтайский язык возник более VII тыс. лет назад в степной части Западной Сибири, примерно в районе от Прикаспия до Алтая. Именно в этот период от единого массива народов отделились носители тунгусо-маньчжурских языков, переселившись в Приамурье и Приморье. Позднее, около II–I тыс. до н. э., разошлись тюркские и монгольские языки (См.: [Рамстедт: 1957; Баскаков: 1981; Старостин 1991; Golden: 1992; Тенишев: 1997.]).

Первые, достаточно достоверные сведения о татарах (VI–IX вв.) породили дискуссию об их языке и культуре. Хотя сведений о них довольно мало, а все более-менее точные достаточно отрывочны, некоторые языковеды считают их тюркским (П. Пельо, К. Огель), другие – монгольским (Ж. Жэле, Е. И. Кычанов) народом. Дискуссия идет несколько десятилетий без явного успеха на окончательное решение проблемы. Не вполне понятна сама суть дискуссии, поскольку все государства и союзы были полиэтничными, а знать в значительной степени была тюркизирована. Вполне оправдан скепсис некоторых современных исследователей по поводу самой возможности достоверных этнических и языковых определений кочевого населения империй Центральной Азии [Мэн-да бэй-лу: 1975. С. 91.]. Можно лишь с большой степенью уверенности говорить о том, что до второй половины I тыс. н.э. полностью монголоязычных племен на территории современной Монголии вообще не было. Скорее всего, монголоязычные кочевники начали выдвигаться в бассейн рек Онона и Керулена довольно поздно, уже после того, как из этих мест были вытеснены уйгуры и татары, то есть не ранее X в. Очевидно, этот процесс был в значительной степени связан с военными успехами киданей и созданием Империи Ляо [Крадин, Ивлиев: 2014. С. 23–25, 33–47.].

Судя по лингвистическим данным, носители алтайского праязыка, до его распада на тюркский, монгольский и другие языки, обитали там, где росли хвойные и дикие плодовые деревья, растения с гибкими ветвями, удобными для плетения – черемуха, орешник, бобовые, дикий виноград. Зимой там выпадал снег. Ландшафт включал чащобы, где водились пушные звери, болота и заболоченные луга, равнины со стадами диких копытных, в том числе оленей и лошадей (например, для алтайского праязыка реконструируется общее слово *лошадиная грива).* Праалтайцы собирали на полях несколько видов злаков, скорее всего ячмень и просо, охотились на диких животных. Можно предполагать, что прароди-

на народов этой языковой семьи находилась в Южной Сибири на стыке смешанных лесов и Великой степи, в районе Алтая и Саян [Петрухин, Раевский: 1998. С. 59]. Вывод этот сделан на основе анализа реконструкции древнетюркского языка. (Более подробно о происхождении и ранней истории тюркских языков см.: [Сравнительно-историческая грамматика: 2006; Дыбо: 2004; 2007; Кормушин: 2004; Древние тюркские языки. Мудрак: 2009]).

Судя по данным лингвистики, собственно прототюркский этно- и глоттогенез охватывал обширную область Центральной Азии и Южной Сибири. В формировании этнокультурных, антропологических и языковых особенностей этого населения основную роль сыграли языковые и культурные взаимодействия тюркских групп с индоевропейским, а также с субстратным угро-финским, самодийским и кетоязычным населением [Новгородова: 1981. С. 207] (Данные лингвистики см.: [Сравнительно-историческая грамматика: 2006. С. 777–817.]). Понимание лингвистических процессов, основанных на языковедческих данных, дает общее понимание места носителей тюркского языка в древности, но не локализует эти контакты и не дает четкой хронологической привязки.

Свое слово в этом отношении могут и должны сказать археология и историческая текстология. Однако сложность отождествления археологических памятников с определенным этносом и даже языковой общностью, в данном случае, с пратюркским этносом, связана с решением ряда научно-методических проблем. Во-первых, понять, в какой мере возможна этническая интерпретация явлений археологии. Решение этого методического и ключевого для интерпретации этнокультурных явлений, вопроса должно дать ответ на вопрос, каким образом какие-либо памятники материальной культуры древности, отражают этнические проблемы. Пока нет оснований полагать тождество этих исторических явлений, поскольку они относятся к совершенно различным понятийным категориям, а их корреляция возможна только при выполнении целого ряда специальных исследовательских процедур и выполнения сложной и последовательной методики сближения данных разных наук [опыт подобной методики см. Измайлов: 2014: С. 138–179]. Во-вторых, весьма трудно коррелировать между собой древние и средневековые этнонимы с данными китайских источников, которые часто передают не самоназвания народов, а китайские представления о них. Так, например, иноплеменников, проживавших в Ганьсу и Тибете, китайские источники именовали жунами, а на севере, в Монголии – ди. Но эти термины были не эндоэтнонимами, а собирательными наименованиями, обозначавшими совокупность населения, проживающего за пределами государства Чжоу

и отличавшегося бытом и нравами от чжоусцев. По мере знакомства с более отдаленными областями, представления о северных соседях китайцев стали более детальными, но также довольно схематичными как, например, в «Шаньхайцзин», где упоминаются и отдаленные племена динлинов, но сведения о них носят полулегендарный характер. Можно полагать, что динлины были кочевниками, жили далеко, и китайцы их тогда плохо знали [Позднеев: 1899. С. 8]. Среди соседей иньского и чжоуского Китая в начале I тыс. до н. э. были племена, являвшиеся предками тюркских, монгольских и тибетских народов. Объединения жунов и ди были близки в этнокультурном отношении; они состояли из многих племен: шань-жуны (горные жуны), цюань-жуны (собаки-жуны), си-жуны (западные жуны), мяньжуские жуны, ицзюйские, далиские, учжиские, красные (чиди), белые (байди) и другие жуны. Очевидно, что среди этих обобщенных китайских названий скрываются и этнонимы тюркских племен.

**Древние татары: из исторического небытия на арену истории.** Судя по логике исторического процесса можно предполагать, что предки татар в III в. до н.э. – I в. н.э. обитали на севере Внутренней Монголии и Забайкалье, где входили в состав империи Хунну. Примерно в это время они стали известны китайским источникам под именем «девять племен шивэй», а именно к народу шивэй более поздние источники относили средневековых татар. Не исключено, что это объединение (девять племенных групп) являлось разнородным объединением под руководством тюркоязычных татар. Позднее, в начале I тыс. н.э., по мере ослабления державы хуннов и оттока их из степей на юг – южные хунну и на запад – европейские гунны, их земли заняли тюркские племена жужаней и тюрков. Татары же в это время, очевидно, также выдвигаются со своих исконных мест обитания в северо-восточную Монголию и Внутреннюю Монголию. Часть из них – «токуз-татары» – занимает район оз. Буир-Нур, а часть проникает далее в Ордос, очевидно, получив у китайцев название онгуты – «белые татары». К сожалению, археологические материалы не позволяют однозначно соотнести местные памятники с этими группами населения. Не исключено, что с какого-то времени дальнейшая история татар из Буир-Нура и токуз-татар начинает развиваться в разных направлениях. Как бы то ни было, во время Тюркских каганатов токуз-татары, очевидно, являлись наиболее могущественным объединением татар, которые были способны противостоять тюркам и телесским племенам. К сожалению, татары на длительное время оказались скрыты от взоров китайских дипломатов и историков, не попадая на страницы хроник и дипломатических документов, что затрудняет реконструкцию их ранней истории.




Рис. 1. Карта Центральной Азии, где отсутствуют татары. (см.: «История Востока. Т. 2. М.: Наука, 1985. Рис. 3).

Выход татар на историческую арену был вызван общей консолидацией народов Центральной Азии в связи с наступлением китайских империй Хань и Тан. Этнополитическое объединение татар сформировалось в степях Монголии после распада каганата жуаньжуаней в результате объединения группы тюркских племен в районе бассейна р. Селенги, северо-восточной Монголии и Забайкалья. Татары, очевидно, были генетически связаны с телесскими племенами, но не входили в их объединение. Скорее всего, ранние татары представляли собой союз нескольких родов, вполне возможно, что тридцати, откуда и их название – отуз-татары, хотя нельзя исключить и того, что это число имело священный характер и означало многочисленность, знатность татарских родов. В отличие от объединения теле, татары изначально не подчинялись тюркам. Но уже при первом тюркском кагане Бумыне, они скорее всего, были завоеваны и вошли в состав каганата. К этому времени относится первое упоминание татар в письменных источниках. Они названы в числе других народов, собравшихся в 552 г. на похороны кагана Бумына [КТб: 4; Перевод см.: Малов: 1951. С. 36; Поэтический перевод см.: Поэзия древних тюрков: 1993. С. 29.]. Хотя это упоминание содержится в надписи на памятнике Кюль-тегину (732 г.), т. е. было зафиксировано в камнеписьменном тексте почти через двести лет после самого этого события, точность его не вызывает особых сомнений. Тюркская историческая традиция сохра-

нила память об этом, несомненно, знаменательном событии в устной и, возможно, письменной форме. Об этом, в частности, может свидетельствовать упоминание Рима – Пурум (от «Рум», как называли Римскую и позднее Византийскую империю сначала персы, а затем арабы), чьи послы также, судя по тексту надписи, почтили память умершего кагана, что было бы совершенно излишне, если бы память об этом сохранялась только в устном фольклоре. Иными словами, уже в середине VI в. татары были знатным племенем, подчинение которого Тюркскому каганату требовало особого упоминания.

**Локализация отуз-татар в тюркское время.** Два основных сведения о расположении татар содержатся в тексте эпитафии Кюль-тегина в Большой надписи (КТб) при перечислении народов, которые оказали почтение тюркам, прислав послов для выражения соболезнования («плачущих и стонущих»). Все эти народы перечислены в определенном порядке:

«…кун тогсыкда Бокlі чоlіг il, табгач, тупут, апар, пурум, кыркыз, уч курыкан, отуз татар, кытай, татабы…

…спереди из солнечного восхода, народ степи Бёклийской, табгач, тибетцы, авары и Рим, кыргызы, уч-курыканы, отуз-татары, кытай и татабыйцы» [КТб: 4; Малов: 1951. С. 29, 36.].

Отюкенская чернь в представлениях тюрков являлась не просто Священной Землей и Водой, но и центром мироздания и организованного этнополитического пространства (О мифологии, а также о представлениях тюрков о пространстве, времени и географии см.: [Кляшторный: 1977, 1981. С. 117-138; Кляшторный: 2003. С. 109–112, 313–357.]. Текст этот таков, что, к сожалению, не дает четких пространственных ориентиров. Но вместе с тем, в нем присутствует система координат, которая выразительна, конкретна и подчинена логике, отражающей «картину мира» средневековых тюрок.

Здесь не названы только телесские племена и главное из них – уйгуры. Вполне очевидно, это связано с тем, что телесские племена были родственными для тюрков, и они считали их своим илем. Описание имеет свою логику и идет с востока по кругу, с центром в Отюкенской черни – «народ степи Бёклийской, табгач, тибетцы, авары и Рим, кыргызы, уч-курыканы, отуз-татары, кытай и татабыйцы» [КТб: 4; Малов: 1951. С. 29, 36.]. Так или иначе, все упоминаемые государства или объединения, имели в глазах тюрков статус государства – «иля», а часть их явно имела отношение к торговым предприятиям Тюркского каганата расположенным по Великому Шелковому пути.

**«Народ степи Бёклийской»** («Бөклі чөллыг іл») самый сложный для понимания термин. Он упомянут в Большой надписи Кюль-тегина

дважды. Кроме данного указания есть еще одно конкретное указание на место этого владения на ментальной и географической карте тюрков. Далее текст надписи сообщает, что тюркский каган совершил поход на эту страну – «Вперед, в сторону солнечного восхода они ходили войной до Бёклийского кагана» [КТб: 4, 8; Малов: 1951. С. 36, 37.]. Иными словами, Беклийцы имели своего кагана и располагались на востоке от тюрок. Есть основания полагать, что под этим термином имеется в виду государство Бохай [Шавкунов: 1968; Государство Бохай: 1994; Ивлиев: 2005. С. 449–475; *Дьякова:* 2014. 318 с.]. Противоборство с мохэ было политически актуально для тюрок во время Второго Тюркского каганата, что объясняет употребление титула каган в отношении их правителя. Но остается открытым вопрос – насколько политически значимыми были мохэ в середине VI в. Нельзя исключить того, что под этим термином понимались обобщенно все тунгусо-маньчжурские племена, формировавшие свои политические образования в VI–VII вв.




Рис. 2. Тюркский каганат (по материалам Издательства ДИК) с размещением перечня народов из текста надписи Кюль-тегину.

**Табгач** (Табғач) – наиболее часто упоминаемый в орхонских надписях термин. Очевидно, происхождение этого обобщенного названия

всех китайских империй у тюрков связана с народом тоба (или табгач), создавшем после завоевания власти в Северном Китае в 398г. империю Тоба Вэй (Северная Вэй) (См.: [Гумилев: 1974 С.107-156; Кляшторный, Савинов: 2005. С.48-54.]). В некоторых текстах прямо указывается на его положение в картине мира тюрков. Например, в так называемом «Онгинском камне», являвшимся поминальной эпитафией Кутлуг-кагану (691г.), сказано: «На юг, к табгачам … от этих табгачей на север» [Малов: 1959. С.7, 9, 10.]. Не подлежит сомнению, что во всех этих текстах речь идет об Империи Тан. Именно она была основным противником Тюркского каганата, в свое время победив тюрок и сделав их аристократию своим военным сословием. «Народу табгач, – в эпитафии якобы сетует Кюль-тегин, – стали они [т.е. тюрки] рабами… Тюркские правители сложили с себя свои тюркские имена и, приняв титулы правителей народа табгач, подчинились кагану народа табгач» [КТб: 7. Перевод см.: Малов: 1951. С.37; Поэтический перевод см.: Поэзия древних тюрков: 1993. С.29–30.]. С ним сражались каганы возрожденного Тюркского каганата, совершая походы и облагая его данью: «У народа табгач, дающего без ограничения столько золота, зерна и шелка была речь сладкая…» [КТм: 5; Малов: 1951. С.34.].

**Тибет** был хорошо известен тюркам, как их геополитический противник и конкурент за контроль над Восточным Туркестаном, по которому проходил Великий Шелковый путь [Малявкин: 1992. С.16–80.]. Тибет прямо упоминают тюркские тексты, располагая его на западе. Так в Малой надписи Кюль-тегина сообщается: «…немного не дошел до Тибета; назад, переправившись через реку Йенчу…» [КТм: 3; Малов: 1951. С.34.]. «Назад» в соответствии с тюркскими представлениями – «на запад».

Там же на западе, но на неопределенном расстоянии, должны были находится упомянутые далее **«Абар»** и **«Пурум»**. Несомненно, это Аварский каганат и Византийская (Ромейская) империя. Упомянуты они явно, как государства, имеющие важное значение для тюрков, как контрагенты по торговле на Великом Шелковом пути. Авары контролировали степи Северного Причерноморья, а Византия – порты на Черноморском побережье.

**Кыргызы** также были хорошо известны тюркам. Долгое время они были их самым стойким и грозным противником. Судя по комплексу историко-археологических данных, кыргызы проживали на северо-западе – в Южной Сибири, на Алтае и в Минусинской котловине. К этому времени они создали свое военно-политическое объединение и активно воевали с тюрками. По словам эпитафии тюркского военачальника и соратника

Бильге-кагана Тоньюкука: «Но больше всего был нашим врагом кыргызский сильный каган». Итогом многовекового противостояния стала двадцатилетняя война, завершившаяся тем, что в 840 г. Кыргызский каганат нанес поражение уйгурам и на короткое время установил над степями Центральной Азии свое великодержавие [Киселев: 1949. № 9. С. 314–359; Худяков: 1986. 80 с.; Савинов: 1994. 215 с.; Худяков: 1996. С. 180-195; Бутанаев, Худяков: 2000. 272 с.; Дробышев: 2010-б. № 6. С. 102–109.].

Народ **«уч-курыкан»** также упоминается в эпитафии Кюль-тегина. Первый раз в качестве участников поминовения Бумын-кагана, а в описании современных реалий начала VII в. наряду с другими народами он указывается в качестве врагов: «Курыканы … все были врагами…» [КТб: 14; Малов: 1951. С. 38.]. Не исключено, что именно курыканы описываются под названием северного племени «гулигань», упомянутого в китайской хронике «Синь Тан шу» [Бичурин: 1950. Т. 1. С. 268.]. В исторической науке существует огромная литература, посвященная курыканам, связывающая их с этногенезом якутского народа. В свете этих исследований вполне допустима локализация этого объединения в Прибайкалье и Приангарье [Окладников: 1968. Т. 1. С. 291–292; Дашибалов: 1995; Ушницкий: 2013; Этногенез и культурогенез: 2010.].

В другом месте Большой надписи Кюль-тегину, описывая его подвиги от первого лица, автор пишет, что сражался против всех народов в разных сторонах света и специально указывает, что совершил поход «налево против народа **огузов**…» [КТб: 28; Малов: 1951. С. 40.]. Ясно, что в этом контексте речь идет о походе не в Приарале, где позднее проживали огузы и сельджуки, а на север («налево») против токуз-огузов, т. е. уйгуров. Важно особое упоминание уйгуров как главных врагов на севере от тюрков, наряду с империей Тан («табгач») на юге и киданями и татабами («кытай и татаб») на востоке («вперед»), которое повторяется в надписи Тоньюкука: «…табгач, огузы, кидане – эти втроем, если соединятся… мы должны прийти на востоке к киданям, на юге к табгачам, на западе к западным (буквально «qurdanta» – курданам) и на севере к огузам» [Тон: 12–14; Малов: 1951. С. 66.]. Интересно, что в описании эпизода поминовения Бумын-кагана токуз-огузы не упомянуты. Очевидно, что тогда еще «десятипламенный народ» Восточной части Тюркского каганата включал под властью тюрков другие девять телесских племени (Следует различать эти десять племен. В данном контексте речь здесь идет не о народе «он ок будун» Западнотюркского каганата, центр которого находился в Семиречье на р. Чу. Это крыло Тюркского каганата в 603 г. отделилось от восточной части, а позднее стало даже противником второго Тюркского каганата. Как писали в эпитафии Тоньюкука: «Каган народа «десяти

стрел» был нашим врагом» ([Тон: 19; Малов: 1951 С. 66]. Скорее всего, речь идет о параллельном разделении двух крыльев Тюркского каганата с десятью племенами в каждой его части. Тогда понятно, откуда взялись названия «он ок будун» и «токуз-огуз» во главе с тюрками.). Но после поражения Тюркского каганата и бегства тюрок, девять племен «огузов» были объединены уйгурами, не желавшими уступать первенство тюркам. Важна также и их локализация на севере, в бассейне р. Селенги, где позднее был центр Уйгурского каганата. Одновременно получается, что отуз-татары в тюркском описании народов идут следом за курыканами и по общему историческому контексту, следом за уйгурами.

На востоке от тюрок и после отуз-татар автор текста описания называет другой народ – **«кытай»** (Қытан) [КТб: 4; Перевод см.: Малов: 1951. С. 36]. В тексте эпитафии Тоньюкука о китаях (киданях) говорится, что он поразил врагов тюрков «Впереди [т.е. на востоке], – киданей…» [Малов: 1951. С. 65.]. В эпитафии Кюль-тегину кидани также указываются среди побежденных врагов (КТб: 14, 28). Среди историков нет сомнений, что под китаями подразумеваются монголоязычные племена киданей, воевавших против тюрков и уйгуров, а после их поражения создавших на территории Маньчжурии, Внутренней Монголии и Восточной Монголии свою империю Великое Ляо под руководством Абаоцзи (Елюй Амбагай), объявившего себя в 907 г. каганом [Викторова: 1980; Дробышев: 2010-а. С. 108–122; Крадин, Ивлиев: 2014. С. 19–37.]. В 1125 г. империю Ляо уничтожили чжурчжэни.

Следом за киданями в тексте упомянуты **«татабы»** или «татабыйцы» («Татабы будун»). Считается, что татабы (или кумоси, кумохи, си) были родственными монголоязычным киданям племенем, проживавшим по склонам Хингана (в совр. Манчжурии). В VI в. это было сильное объединение, воевавшее с тюрками и киданями. По словам автора эпитафии Кюль-тегину: «Вперед против народа кытай и татабов, направо … сразился» [КТб: 28; Малов: 1951. С. 40.]. Позднее они были разгромлены империей Ляо и вошли в ее состав, практически растворившись среди киданей, а в дальнейшем разделили их судьбу.

Таким образом, локализация татар («отуз-татар») точно укладывается в район среднего и нижнего течения р. Селенги и Орхона, в междуречье рек Онона и Керулена. При этом нет никаких оснований прямо связывать происхождение татар с народом «шивей» и проецировать представления об этом народе поздних китайских трактатов на раннюю историю. Происхождение и историческая судьба народа, объединенного элитой татар, могла быть совершенно иной, чем представляли себе ее китайские авторы, стремившиеся связать новые исторические реалии с традиционными

представлениями о номенклатуре народов. Поэтому, проживание татар в регионе, которое позднее стали занимать монгольские и маньчжурские племена, не может свидетельствовать об их этногенетической связи. Наоборот вытеснение татар и их движение на юг и на запад свидетельствует, что они вместе с другими тюркскими народами постепенно выдавливались на запад, а на их земли выдвигались монголы, которых, в свою очередь, выдавливали тунгусо-манчжурские народы.

Как бы то ни было, но татары считались тюрками отдельным народом, имеющим высокую степень социальной организации, наряду с кыргызами, телесскими племенами, киданями, татабами.

При рассмотрении локализации татар следует иметь в виду, что за исключением, пожалуй, кыргызов, другие объединения часто меняли места проживания и перемещались на значительные расстояния. Как правило, это происходило во время распада больших империй и массовых миграций на свободные территории новых групп населения. Поэтому нет ничего удивительного, что после распада Тюркского каганата его земли заняли телесские (уйгуры, карлуки и др.) и татарские племена.

*(Продолжение следует)*

## Литература

Баскаков Н. А. Алтайская семья языков и ее изучение. М., 1981.

Бичурин Н. Я. (Иакинф). Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. 1. М., Л., 1950.

Большая надпись Моюн-Чура (Далее – МЧб. Малов С. Е. Памятники древнетюркской письменности Монголии и Киргизии. М., Л.: Изд-во АН СССР, 1959. С. 30–44.

Бутанаев В. Я., Худяков Ю. С. История енисейских кыргызов. Абакан: Изд-во Хакас. гос. ун-та, 2000. 272 с.

Викторова Л. Л. Монголы. Происхождение народа и истоки культуры. М.: Наука, 1980.

Государство Бохай (698–926 гг.) и племена Дальнего Востока России. М.: Наука, 1994.

Гумилев Л. Н. Хунны в Китае. Три века войны Китая со степными народами III–VI вв. М.: Наука, 1974.

Ивлиев А. Л. Очерк истории Бохая // Российский Дальний Восток в древности и средневековье: открытия, проблемы, гипотезы. Владивосток, 2005.

Дашибалов Б. Б. Археологические памятники курыкан и хори. Улан-Удэ: БНЦ СО РАН, 1995. 191 с.

Древние тюркские языки. Мудрак О. А. Классификация тюркских языков и диалектов: (с помощью методов глоттохронологии на основе вопросов по морфологии и исторической фонетике). М.: РГГУ, 2009. 191 с.

Дробышев Ю. И. Политика киданей в Центральной Азии // Общество и государство в Китае: XL научная конференция. М.: Ин-т востоковедения РАН, 2010 а.

Дробышев Ю. И. Кыргызы в Центральной Азии (IX в.) // Восток (Oriens). 2010 б. №6.

Дыбо А. В. Хронология тюркских языков и лингвистические контакты ранних тюрков. М.: Академия, 2004.

Дыбо А. В. Лингвистические контакты ранних тюрков. Лексический фонд. Пратюркский период. М.: Вост. лит., 2007. 222 с.

Дьякова О. В. Государство Бохай: археология, история, политика. М.: Наука - Вост. лит., 2014.

Измайлов И. Л. Археологическая культура и средневековая этническая общность: теоретические и методологические проблемы соотношения (на примере средневековой Булгарии) // Поволжская археология. 2014. № 3.

Киселев С. В. Древняя история Южной Сибири // Материалы и исследования по археологии СССР. 1949. № 9.

Кляшторный С. Г. Мифологические сюжеты в древнетюркских памятниках // Тюркологический сборник. 1977. М.: Наука, 1981.

Кляшторный С. Г. История Центральной Азии и памятники рунического письма. СПб.: Филолог. фак-т СПбГУ, 2003.

Кляшторный С. Г., Савинов Д. Г. Степные империи древней Евразии. СПб.: Филолог. фак-т СПбГУ, 2005.

Кормушин И. В. Древние тюркские языки. Абакан: Изд-во Хакасского гос. ун-та, 2004.

Крадин Н. Н., Ивлиев А.Л. История киданьской империи Ляо (907–1125). М.: Наука-Вост. лит., 2014.

Малов С. Е. Памятники древнетюркской письменности. Тексты и исследования. М., Л.: Изд-во АН СССР, 1951.

Малов С. Е. Памятники древнетюркской письменности Монголии и Киргизии. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1959.

Малявкин А. Г. Борьба Тибета с Танским государством за Кашгарию. Новосибирск: Наука, 1992.

Мэн-да бэй-лу. Пер. с китайского, введ., коммент. и прил. Н. Ц. Мункуева. М., 1975.

Новгородова Э. А. Ранний этап этногенеза народов Монголии (конец III–I тыс. до н. э.) // Этнические проблемы истории Центральной Азии в

древности (II тыс. до н.э.) Труды международного симпозиума. г. Душанбе. 17–22 октября 1977 г. М.: Наука, 1981.

Окладников А. П. Курыканы // История Сибири. Т. 1. Л.: Наука, 1968.

Петрухин А. Я., Раевский Д. С. Очерки истории народов России в древности и раннем средневековье. М.: Языки славянской культуры, 1998.

Позднеев Дм. Исторический очерк уйгуров. СПб., 1899.

Поэзия древних тюрков VI–XII веков. Научн. пер. И. В. Стеблевой. Поэт. пер. А.Преловского. М.: Раритет, 1993.

Рамстедт Г. И. Введение в алтайское языкознание. Морфология. – М., 1957.

Савинов Д. Г. Государства и культурогенез на территории Южной Сибири в эпоху раннего средневековья. Кемерово: Кемеров. гос. ун-т, 1994.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка. Под ред. Э. Р. Тенишева и А. В. Дыбо. М., Наука. 2006.

Старостин С. А. Алтайская проблема и происхождение японского языка. М., 1991.

Тенишев Э. Р. Алтайские языки // Языки мира. Тюркские языки. М.: Индрик, 1997.

Тугушева Л. Ю. Тюркские рунические письменные памятники из Монголии. М.: ИНСАН, 2008.

Ушницкий В. В. Население Байкальского региона в эпоху Средневековья (к проблему этногенеза Саха). Якутск: Изд-во ИГИиПМНС СО РАН, 2013.

Худяков Ю. С. Кыргызы на Енисее. Новосибирск: Новосиб. гос. ун-т, 1986.

Худяков Ю. С. Кыргызы в Восточном Туркестане // Кыргызы: этногенетические и этнокультурные процессы в древности и средневековье в Центральной Азии. (Материалы Межд. научн. конф., посвященной 1000-летию эпоса «Манас» 22–24 сентября 1994 г.). Бишкек: Кыргызстан, 1996.

Шавкунов Э. В. Государство Бохай и памятники его культуры в Приморье. Л.: Наука, 1968.

Этногенез и культурогенез в Байкальском регионе (средневековье). Улан-Удэ: Изд-во БНЦ СО РАН, 2010.

Golden P. B. An introduction to the history of the Turkic peoples. – Wiesbaden, 1992.

Pelliot P. Notes sur L’histoire de la Horde d’Or. Paris, Librairie d’Amérique et d’Orient, Adrien Maisonneuve, 1949.

**Төбәк тарихы буенча фәнни мәкаләләр**

**Научные публикации по краеведению**

***Ф. Ә. Бәйрәмова***

## САМАР ЯРЫМУТРАВЫНДА ТАТАР ТАРИХЫ

Самара төбәгендә гаҗәеп матур, серле һәм үзенчәлекле бер урын бар, ул урысча «Самарская Лука», дип атала, татарчасын «Самар ярымутравы», дип атыйк. Монда Идел елгасы, 200 чакрымга уйдыкланып кереп, урман-таулардан, төпсез күлләрдән, саф чишмәләрдән, йөгерек елгалардан, тирән тарлавыклардан торган ярымутрау хасил иткән. Атаклы Жигули таулары да биредә. Ярымутрауның үзен һәм Жигули тауларын галимнәр бозлык чорыннан ук калган, диләр, ниндидер могҗиза белән, бозлык бирегә хәтле килеп җиткән һәм туктаган. Шуңа күрәдер инде биредә дөньяның башка бер җирендә дә булмаган үсемлекләрне һәм кош-кортларны очратырга була, алар Кызыл китапка кертелгән һәм тыюлыкларда саклана. Ярымутрау зур түгел – төньяктан көньякка озынлыгы – 33, көнбатыштан көнчыгышка – 60 чакрым, иң тар бугазы – 2 чакрым...

Самар ярымутравында халык күп яшәми, анда нибары бер шәһәр һәм дистәдән артык авыл бар, Жигули шәһәре дә моннан 60 ел элек, Куйбышев ГЭСы төзелгәндә генә салына. Югыйсә, бу ярымутрауның гөрләп торган чаклары да булган бит! Тарих биредә мең ел элек болгар шәһәрләре, татар калалары булуын хәтерли, биредә хәзер дә бик борынгы курганнар һәм шәһәр урыннары саклана. Идел елгасы белән чорнатып алынган Самар ярымутравы безнең ерак бабаларыбыз булган скиф һәм сармат кабиләләрен дә, төрки һуннарны да, хәзәр, болгар, Алтын Урда, Казан ханлыклары чорларын да, урыс басып алуларын да, Ермак, Степан Разин, Пугачев яуларын да яхшы хәтерли...

Самар ярымутравының болгар чоры галимнәр тарафыннан азмы-күпме өйрәнелгән, әмма ул бүгенге татарларга катнашы булмаган аерым халык кебек өйрәнелә. Самар ярымутравының болгарга хәтле чоры да, аннан соңгы тарихы да татарлар белән бәйләп өйрәнелми, киресенчә, 1236-нчы елда болгарларны татарлар килеп юк иткән дә, биредә болгар да, татар да калмаган, дигән версия ныклап урнашкан. Әмма бу дөрес түгел, чөнки татарлар белән болгарлар кушылгач, Болгар шәһәре дә,

башка калалар да яңа югарылыкта үсеп, күтәрелеп китәләр. Самар ярымутравында шушы төбәкнең башкаласы булып торган Мүрмән каласы (Муромский городок) та, тарихчылар язганча, 1236-нчы елда җан тәслим кылмый, ә Алтын Урда һәм Казан ханлыклары чорында да яшәвен дәвам итә, һәм анда ТАТАРЛАР яши! Шушыны исбат итү өчен, миңа соңгы елларда Казан, Самара, Жигули шәһәрләрендә булырга, архив-китапханәләрдә эшләргә, сирәк хезмәтләр белән танышырга туры килде.

Һәм, ниһаять, мин эзләгәнемне таптым – Самарская Лука дип аталган Самар ярымутравында, Мүрмән шәһәрлегендә (Муромский городок) әле Казан ханлыгы чорында да татарлар яшәгән булып чыкты. Бу хакта XVIII гасыр урталарында ук академик Иван Лепехин язып калдырган булган. Ул 1769-нчы елның 23–24-нче маенда Валы авылы тирәсендәге хәрәбәләрне өйрәнә һәм мондый нәтиҗәгә килә:

«...Кем укреплено сие место, заподлинно сказать не можно. Старожилые из предания объявляют, что тут до взятия Казани обитали Татара, а по взятия оные место сие оставили…» [Лепехин: 1771. С. 337].

Әмма соңрак чор галимнәре «татарлар» сүзен «кешеләр» сүзе белән алыштырып яза башлаганнар. Нәтиҗәдә, Валы авылы янындагы борынгы Мүрмән каласында безнең халык Болгар дәүләте чорында гына яшәгән булып чыга. Хәтта үзебезнекеләр дә, бүгенге урыс тарихчыларына ияреп: «Коллега Палласа – Иван Лепехин писал, что люди ушли из Муромского городка только после падения Казанского ханства, в середине XVI века», – дип язалар [Галимов: 2012 а. С. 9]. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң Мүрмән каласын калдырып киткән кешеләр – ТАТАРЛАР булган бит, әмма бүгенге галимнәр моны искә алмыйлар.

Күпчелек галимнәрнең язуынча, имеш, 1236-нчы елны татар-монгол яуларыннан соң Мүрмән каласы җимерелә һәм башка торгызылмый. «..Муромский городок, разрушенный татаро-монголами в 1236 году, больше не восстановливался...» [Матвеева, Кочкина: 2005. С. 6]. Ни өчен бүгенге галимнәр академик Лепехинның татарлар турындагы сүзләренә игътибарсыз калганнар соң, ул гына да түгел, «татара»ны «люди» сүзенә алыштырганнар, яки 1236-нчы елдан соң Мүрмән каласы яңадан торгызылмаган, дип исбатларга тырышканнар? Безнең уебызча, борынгы болгарларның һәм аларның шәһәрләренең татар-монголлар тарафыннан юк ителүе барысын да канәгатьләндергән. Бу юл белән китеп, тарихчылар ике куянны атып екканнар – беренчедән, татар-монголларны болгар кабиләләрен юк итүче итеп теркәп калдырганнар, икенчедән, Самарская Лукада, Муромский городокта, татарларның хәтта Казан ханлыгы чорында да хуҗа булып яшәп ятуларын яшергәннәр. Ни өчен шулай эшләгәннәр? Чөнки Лепехинга ияреп, Казан ханлыгы чорында Самар ярыму-

травында, Мүрмән каласында татарлар яшәгәнен язсаң, аларның ни өчен юкка чыгуларын да язарга кирәк булачак.

Алай да, төбәк тарихын өйрәнүче кайбер татарлар Муромский городокта тормышның 1236-нчы елдан соң да дәвам итүен язалар. «Разрушенный во время монгольского нашествия в середине 1236 года, Муромский городок не прекратил существование, однако роли важного экономического и общественного центра, как прежде, уже не играл», – дип яза алар [Галимов: 2012 б. С. 8]. Әйткәнебезчә, автор, Лепехинга таянып, биредә кешеләрнең (татарларның – Ф. Б.) XVI гасыр урталарына кадәр яшәүләрен яза. Аннан соң биредә татарларның эзе югала...

Чыннан да, Болгар һәм Алтын Урда чорларында, Казан ханлыгы заманында гасырлар буе Самар ярымутравында, Мүрмән каласында яшәгән болгар-татарлар кая киткән соң? Бүгенге көндә Самарская Лукада бер генә татар авылы да юк бит, ә урыс, чуаш, мукшы авыллары бар. Безнең уебызча, Мүрмән каласында яшәгән татарларның бер өлешен, Казан ханлыгы җиңелгәч, басып алучы урыслар юк иткән, Самар ярымутравында башкисәр казакларның, шул исәптән, Ермак ерткычларының да бер ара яшәп алуын истә тотсак, татарларга үз милләтләрендә һәм диннәрендә исән калу мөмкин булмаган. Татарларның икенче бер өлешен көчләп чукындырганнар яки исән калу өчен, алар христиан динен алырга мәҗбүр булганнар. Бу татарлар урыс милләте составына күчеп, хәзер Самар ярымутравындагы урыс авылларында, бигрәк тә, Муромский городок янәшәсендәге Валы һәм Жигули авылларында яшиләр булса кирәк.

Гомумән, Самар ярымутравындагы шактый урыс-чуаш-мукшы авыллары элеккеге болгар-татар авыллары өстендә утыралар. «...булгарские поселения обнаружены на территории города Самары, а также в районе сел Винновка, Шелехметь, Подгоры, Валы, Жигули, Александровка, Рождественно, Новинки, Брусяны, Мордова Поляна, Торновское, Хрящевка...», – дип яза төбәк тарихын өйрәнүчеләр [Галимов: 2012 б. С. 8]). Татарларның тагы бер өлеше биредән качып исән калган, алар Идел аръягындагы кыпчак далаларына һәм коры җир буйлап, ярымутрауның дәвамы булган урман-дала зонасына, хәзерге Пенза, Мордовия, Ульяновск җирләренә таралган мишәрләр булырга мөмкин...

Әйткәнебезчә, Муромский городок хәрәбәләре бүгенге галимнәр тарафыннан өйрәнелә, әмма археологик яктан әле андагы катламнарның ун проценты да ачылмаган. Гадел галимнәр булса, биредә болгар чорыннан соң Алтын Урда һәм Казан ханлыгы заманнарында да шәһәр булганлыгын һәм анда татарлар яшәгәнен әйтерләр, дип уйлыйм. Шулай ук биредә Җәмигъ мәчет һәм башка мәчет-мәдрәсәләр урыннары да әле казып чыгарылмаган, ә алар Мүрмән каласында шактый булгандыр. Безнең бу

язманың төп максаты исә – Самар ярымутравында, шул исәптән, Мүрмән каласында да, төрки-татарларның зур борынгы тарихы булуын һәм аларның биредә XVII гасыр башларына кадәр яшәүләрен исбат итү. Без моны үзебезгә кадәр бу тирәләрне өйрәнгән галимнәрнең хезмәтләренә таянып дәлилләргә тырышырбыз.

Самар ярымутравын һәм Мүрмән каласы хәрәбәләрен өйрәнү XVIII гасыр урталарында Иван Лепехиннан башланган, соңрак бу эшне Петер Паллас дәвам иткән, XIX гасырда дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Владимир Поливанов бу якларны өйрәнүгә күп көч куйган. Ни гаҗәп, бу галимнәрнең хезмәтләрендә татар сүзе яшерелми, үзләрендә булган мәгълүматлар буенча, алар Самар ярымутравының тарихын мөмкин кадәр дөрес чагылдырырга тырышканнар. Алардан соң Самарская Луканы һәм Мүрмән каласын өйрәнгән тарихчылар бу галимнәрнең хезмәтләренә таянганнар, әмма аларның татарлар белән бәйле фикерләрен алга чыгармаганнар. Без исә XVIII–XIX гасыр рус галимнәренең Самар ярымутравында болгар-татар тарихы белән бәйле фикерләренә төп басымны ясарбыз.

Башта ук географик атамаларга ачыклык кертеп үтәсем килә. XVIII гасырның урталарында фәнни әдәбиятта «Самарская Лука», «Муромский городок», «Жигули таулары» дигән атамалар юк. Аларда Самар ярымутравы «Остров», ягъни, утрау-атау, дип аталган. Ә Муромский городок хәрәбәләре янәшәдәге Валы авылы белән бәйләп өйрәнелгән, Муром атамасы исә биредә яшәгән кабилә исеме булган, дип язалар, аның Мауремане, Мурмани, Муран вариантлары да бар, бу борынгы бортас-мишәрләрнең үзатамалары булырга да мөмкин. Дөресен әйткәндә, «Мур» тамырыннан башланган географик атамалар – Мурманск, Муром, Муромец сүзләре әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Ә татарлар Жигули тауларын – Үртүбә, дип, Иделнең аръягындагы, биредән ерак булмаган Патша курганын (Царев курган) – Сары Олы Тау, дип атыйлар, галимнәрнең әйтүенчә, анда татарларның Мамаон исемле зур патшалары күмелгән булырга тиеш. Мүрмән – Муромский городокның да Мәрҗән варианты бар, әмма бу исем дә ахырга чаклы ачыкланмаган.

Инде тагы Иван Лепехин хезмәтләренә әйләнеп кайтыйк. Ул Валы авылы янындагы борынгы хәрәбәләрне «Муромский городок» дип атамаган, ә *«Древние при селе Валах укрепления»* бүлекчәсендә бәян иткән. «Село Валы наименование свое имеет от древнего укрепленного места, – дип яза ул. – Оно находится верстах в трех между оным селом и селом Жигулихою». Лепехинның язуы буенча, бу ныгытмалар бик көчле булган, алар рәт-рәт булып, Идел елгасына кадәр барып җиткәннәр, «Волжские горы», «Яблоневые горы» дип аталган таулар да табигый ныгытмалар ролен башкарган. Лепехин фикеренчә, тау битләрен каплап киткән алма

бакчаларын биредә элек яшәүчеләр утырткан булырга тиеш. Лепехинның Казан ханлыгы чорында монда татарлар яшәгәнлеге турында фикерен без югарыда язган идек инде.

Иван Лепехин Печерский авылыннан 20 верст ераклыкта булган Кастычи авылында да булган, заманында анда татарлар яшәгәнлеген язып калдырган. *«Древнее в Кастычах укреплении»*. Село Кастычи весьма пространна, и живут в нем государственные крестьяне; а в старину сие место принадлежало Волжским нагорным Татарам. Татарское обиталища видны еще и по сие время остатки, которые состоят из каменных развалившихся стен. Числом их только три», – дип яза ул [Лепехин: 1771. С.34]. Бу авыл хәзерге галимнәрнең хезмәтләрендә искә алынмый, димәк, ул инде әкренләп юкка чыккан. Әле Лепехин килгәндә дә анда таш диварлар булгач, бу урында да татарларның кирмәннәре булган, дигән сүз.

Лепехин артыннан ук бу якларда галим Петер Паллас та була, ул да Валы авылы янындагы борынгы шәһәрлек урынын «татар кирмәне» – «татарский шанц» дип атый. «Деревня Валовка проименована по находящемуся за две версты…обширному и, как сказывают, татарскому шанцу, состоящему из трех валов со рвами, имеющему несколько верст в окружности, – дип яза ул. – В сем шанце нет никаких следов строения, однако во время пахания попадаются иногда татарские кирпичи…, может быть, находящихся в земле могил» [Паллас: 1773–1778. Ч.1. С.243].

Палласның шушы ук хезмәтендә татарлар белән бәйле фикерләре шактый. Әйтик, ул Самар ярымутравының мәҗүси чуашлар яшәгән Севрюкова авылы янында ике курган күрә һәм аларның татар каберлекләре булырга мөмкинлеген әйтә: «Может быть, что и сие два кургана ни что иное, как знаки для памяти, или старинные Татарские кладбища», – дип яза ул [Паллас: 1773–1778. Ч.1. С.279]. Ул шулай ук Самар ярымутравындагы шактый үсемлекләрнең татар атамасы белән бәйле булуына да игътибар иткән, әйтик, «Татарская дикая крапива», «Татарский клен» һәм шундый төрки-татар атамаларының еш очравын ассызыклаган.

Әмма Самар ярымутравын һәм аның белән бәйле татар тарихын иң җентекле теркәп калдыручы, мөгаен, төбәк тарихын өйрәнүче археолог Владимир Николаевич Поливановтыр. 1900-нчы елда аның «Археологическая карта Симбирской губернии» дип аталган хезмәте басылып чыга, биредә ул Сембер, Сенгил, Сызран, Буа, Алатыр, Ардат, Курмыш өязләрендәге борынгы шәһәрлек урыннарын, курганнарны, валларны, мәгарәләрне, торак урыннарын, табылдык-хәзинәләрне тасвирлый. Әлбәттә, В.Поливанов үзенең бу хезмәтендә аңа кадәр Самар ярымутравын өйрәнгән Лепехин, Паллас кебек галимнәрнең хезмәтләренә дә таяна, фәнни әйләнешкә «Муромский городок» дигән атаманы кертеп

җибәрә, әмма ул Иделгә якынрак җирдә итеп тасвирланган. Бу тирәдә ике борынгы шәһәр булган кебек тәэсир кала.

Поливанов та, Лепехин кебек үк, Валы белән Жигули авыллары янындагы борынгы шәһәрлектә Казан ханлыгы чорында татарлар яшәгәнлеген язып калдырган: «Местные старожилы по преданию передают, что на этом месте, около сел Жегулихи и Валов, до взятия Казани жили татары, которые после падения Казанского царства куда-то ушли, – дип яза ул. – На всем укрепленном пространстве между двух упомянутых городков встречаются черепки глиняной посуды, медные топорики, медные старинные деньги круглой и треугольной формы, человеческие костяки с медными и серебряными кольцами, медная посуда. А также оружие из железа – шашки, сабли и копья» [Поливанов: 1900. С. 28].

Бу – бик мөһим хәбәр, чөнки соңгы вакытта рус-татар (болгар) тарихчылары Муромский городокта болгар-монгол-татар бәрелешен иң алгы планга чыгардылар, аннан соң биредә тормыш туктаганлыгын исбатларга тырыштылар. «В 1236 году Муромский городок на Самарской Луке разделил трагическую участь других городов Волжской Булгарии, – дип яза алар. – Он был полностью разрушен и сожжен войсками Бату-хана... Вместе с древним булгарским городом были стерты с лица земли и все окрестные села. После этой трагедии Муромский городок уже не возродился. Чудом уцелевшая часть местного населения покинула Самарскую Луку и расселилась в других местах» [Наследие волжских булгар: 2013. С. 136–137].

Озак еллар буе Муромский городокта казу эшләре алып барган археолог Анна Кочкина да шул сүзләрне кабатлый, татар-монол яуларыннан соң биредә кешеләр яшәмәвен әйтә. «Со времен монгольского нашествия в районе Муромского городища никто не жил», – дип яза ул [Наследие Волжских булгар: 2013. С. 137]). Әлбәттә, Самара тарихчылары Лепехинның да, Поливановның да югарыда телгә алган хезмәтләрен белгән булырга тиешләр, әмма бу галимнәрнең Муромский городокта Казан ханлыгы чорында да ТАТАРЛАР яшәве турында фикерләрен беркайчан да телгә алмаганнар, киресенчә, монгол яуларыннан соң биредә беркем яшәмәгән, шәһәр юкка чыккан, дип баралар. Ни өчен шулай дип язалар? Бу сорау ачык кала...

Муромский городок турында фәнни хезмәтләрне укыганда, тагы бер сәерлеккә тап булдым. Әйтик, В. Поливанов Валы авылы янында бер борынгы шәһәрлек, ә Иделдән ерак түгел икенче – Муромский городок дип аталган шәһәрлек барлыгын язып калдырган. «Село Валы получила свое название от древнего укрепленнаго места, которое находится между названным селом и селом Жегулихою, – дип яза ул. – В северо-восточной стороне от села Валов тянутся Яблонные волжские горы, параллельно

с которыми идет глубокий буерак. К этому буераку примыкает городок четыреугольной формы, длиною 200 сажен и шириною около 100 сажен. Городок окружен с северо-западной и юго-восточной стороны тоже оврагами, а с южной стороны, обращенной к селу Валы, – тремя высокими валами с глубокими рвами. Из них средний вал всех выше. Валы проведены не по прямой линии, а полукругом. Овраги, с которыми соединяются валы, продолжаются далее до Волги верст на десять, где и оканчиваются также городком, названным местными жителями «Муромским». Этот городок расположен недалеко от Волги на одной из Яблоновых или Волжских гор» [Поливанов: 1900. С. 28].

Шундый озын өзек китергән өчен укучы мине гафу итсен, әмма мәсьәләгә ачыклык кертү өчен кирәк иде бу. Поливановның язуынча, Валы янында бер борынгы шәһәрлек урыны, ә Идел буенда икенчесе булган, нәкъ менә соңгысы «Муромский» дип аталган. Димәк, бүген Валы авылы янында галимнәр «Муромский» дип өйрәнә торган хәрәбәләр бөтенләй башка исемдәге шәһәрнеке булып чыга? Ә чын «Муромский»ны Идел буеннан эзләргә кирәк, бәлки Муран каберлеге яки Междуреченск шәһәр калдыклары соңрак «Муромский» дип атала башлагандыр? Ни булса да, Валы авылы янындагы борынгы болгар-татар шәһәренең чын тарихи исемен эзләп табарга кирәк әле...

Әмма сәерлекләр моның белән генә бетми. Самараның бүгенге тарихчылары, Поливановның бу хезмәтеннән мин югарыда мисалга китергән өзекне үзләренчә үзгәртеп язганнар. Ягъни, Поливановның «Муромский городок Иделдән ерак түгел урнашкан», дигән сүзләрен, «Муромский городок Валы авылыннан ерак түгел урнашкан», дип үзгәрткәннәр, бу инде күрәләтә фальсификация. «...Овраги, с которыми соединяются валы, продолжаются до Волги верст на 10, где оканчиваются также городком, названным местными жителями Муромским. Этот городок расположен недалеко от с. Валы, на одной из Яблоневых или Волжских гор», – дип яза алар [Матвеева, Кочкина: 2005. С. 18–19]. Бу урында авторлар үзләре дә аптыраганнар, «Не вполне ясно, о каком втором городке говорит В. Н. Поливанов, важно отметить, что и он в конце прошлого века видел 3 вала и рва», дип өстәп куйганнар [Матвеева, Кочкина: 2005. С. 18–19]. Әмма мондый 3 вал һәм тирән чокырлар белән һәр болгар-татар каласы чорнап алынган булу, бу авторлар өчен дәлил булып тора алмый. Поливанов бу тирәдә ике шәһәр барлыгы турында яза икән, аны ахыргача тикшереп бетерергә кирәк иде, ә йөз еллык хезмәтне үзеңчә төзәтергә кирәк түгел иде!

Поливанов бу хезмәтендә Самар ярымутравындагы күп авылларның тарихи урыннарын тасвирлаган, без исә аннан татарларга караган өле-

шләрен генә сайлап алдык. Ул Уса елгасы буендагы Муранка авылындагы каберлеккә (могильник) киң тукталган, Император Археологик комиссиясе кушуы буенча, андагы археологик казу эшләре белән үзе җитәкчелек иткән. XIV гасырда, ягъни, Алтын Урда чорында, бирелә күмелгән 700 кабернең бер өлеше мөселман-татарларныкы булып чыга. «Третья форма погребения, которую исследователь встретил у камня с татарской надписью (вследствие плохой сохранности неразобранной), заключалась в отсутствии при костях вещей» [Поливанов: 1900. С. 25]. Ягъни, киемсез һәм әйберләрсез күмелгән, кабер ташына гарәпчә-татарча язылган каберләрне татарныкы, дип исәпләгәннәр һәм дөрес эшләгәннәр. Шул ук вакытта аты белән бергә күмелгән бер җайдакның кабереннән татар акчалары да табыла, бу – ислам динен кабул итмәгән монгол яугире кабере булырга мөмкин. Башка каберләрдән дә шактый гына татар тәңкәләре табылган, «В числе монет встречаются золото-ордынские следующих ханов: Узбек-хан (Старый Сарай. 731–1330), Джанибек-хан (Новый Сарай. 747–1346), Бердибек-хан (759–1359) и Тимур-хаджа (759–1359) [Поливанов: 1900. С. 27].

1889-нчы елны Муран каберлегеннән ерак түгел гарәпчә язылган кабер ташы табыла. Автор фикеренчә, бирелә 70 дисәтинә зурлыгындагы шәһәрлек булган, ул утрау рәвешендә, Уса елгасы һәм аның култыгы арасында ясалма рәвештә ясалган. «На поверхности этой площади встречается немало черепков глиняной обожженной посуды с рисунками, железной гари, прясел, кусков кирпича, – дип яза Поливанов. – В большом числе попадаются также татарские монеты XIV в. Здесь на середине острова находилось небольшое каменное здание неопределенного назначения, с каменным полом и такими же из дикаря стенами, плотно сложенными на извести» [Поливанов: 1900. С. 27]. Поливанов бу утрау-шәһәрлектә Сарайдагы кебек шакмаклы «татар кирпече» очравын да яза, халыктан ишетүе буенча, бу тирәдә әле күптән түгел генә мәчет манарасы торганлыгын бәян итә. «В народе сохранилось предание, что около здания не так давно еще существовала каменная башня «мизгить» (т. е. мечеть), разрушенная временем, а более кладоискателями и крестьянами, увозившими готовый материал на свои нужды» [Поливанов: 1900. С. 27–28].

Галимнәрнең язуынча, бүгенге көндә Самар ярымутравында Алтын Урда чоырннан калган 50 археологик урын билгеле, аларның нибары унлабы гына өйрәнелгән. Бүген «Междуреченское городище» дип өйрәнелгән урын шундыйлар рәтеннән, ул Поливанов язган Муран шәһәрлегенә туры килә. Дөресен әйткәндә, бу тирәдәге авылларның һәм тауларның күпчелегендә борынгы курганнар һәм шәһәрлек урыннары сакланган,

әмма аларны махсус өйрәнүче юк. Тагы Поливанов хезмәтенә кайтыйк. Ул Подгоры авылы янындагы шәһәрлек урынында да Алтын Урда чоры көмеш тәңкәләре табылуы турында хәбәр итә:

«За селом Подгоры в долине, называемой «Мордовская поляна», есть признаки городка, имеющего в окружности 160 сажень, – дип яза ул. – В этом городке в 1895 году было найдено 120 татарских золото-ордынских серебряных монет XIII и XIV веков» [Поливанов: 1900. С. 30]. Поливанов шулай ук Переволок авылы янындагы тауларны һәм андагы мәгарәләрне өйрәнә һәм биредәге борынгы ныгытмаларны Татар шәһәрлеге, дип атый. «В переписных и межевых книгах по Самарскому уезду 1672 года описанное укрепленное место называлось Татарским городищем», – дип яза ул [Поливанов: 1900. С. 31]. Ә Печерский авылында исә мөселман кабер ташлары да табылган. «В самом селе Печерском при ломке фундамента одним крестьянином найден надмогильный камень с арабскою вязью», – дип яза Поливанов [Поливанов: 1900. С. 31]. Самар ярымутравындагы урыс авылларындагы йорт һәм чиркәү нигезләрен, базларны һәм келәтләрне өйрәнсәң, алардан татарларның шактый борынгы кабер ташлары табылырга мөмкин әле...

Лепехин эзләре буйлап барып, Поливанов та Костычи (Кастычи) авылында була һәм андагы татар ныгытмасын тасвирлый. «Среди села Старых Костычей на площади, где ныне стоит церковь, видны следы бывшаго здесь некогда татарского каменнаго укрепления, – дип яза ул. – Гора, на которой стоит городище, спускается к Волге отвесною стеною... Встарину место это принадлежало волжским нагорным татарам» [Поливанов: 1900. С. 33]. Поливанов бу авылдан ерак түгел татар каберлеге барлыгын да хәбәр итә: «В двух верстах от села Старых Костычей, на кургане, называемом Пустыльским Бугром, что около Пустыльского оврага, есть татарский могильник, на которым и ныне находят человечские остовы в сидячем положении и мелкую серебрянную ордынскую монету» [Поливанов: 1900. С. 34].

Бүгенге төбәк тарихын өйрәнүчеләр, узган гасыр галимнәренең хезмәтләренә таянып, Самар ярымутравында Алтын Урда ханнарының җәйге ыстаннары булган, дип тә язалар. «Некоторые исследователи (например М. Иванин, 1875) указывают, что здесь была летняя ставка ханов Золотой Орды, «паслись бесчисленные стада, и кочевало множества народу», – дип яза алар [Павлович, Ратник: 2003]. Биредә сүз М. И. Иванинның «О состоянии военного искусства у среднеазиатских народов при Тамерлане» дигән хезмәте турында бара, ул 1875-нче елда басылып чыккан булган.

Күрәсез, XVIII–XIX гасыр галимнәре Самар ярымутравында татар тарихын шактый дөрес яктырткannар, күргән-белгәннәрен яшереп кал-

дырмаганнар. Ул вакытта әле татар атамасын болгар белән күрәләтә алыштыру да булмаган, тарих ничек бар – шулай язылган. Егерменче гасырда исә, бигрәк тә, совет чорында, һәм соңгы вакытта Самар ярымутравында татар тарихы турында я бөтенләй дәшмәделәр, я бу дәһшәтле атаманы болгар белән алыштырдылар. Югыйсә, биредә Болгар һәм Алтын Урда чоры тарихи ядкәрләре, археологик истәлекләр бер тигез бит – һәр икеседә иллешәр. Самар ярымутравының татар чоры аз өйрәнелүен бүгенге галимнәр биредә ике гасыр буе тормышның ташландык хәлдә булуы белән аңлаталар:

«...Замятня, эпедимия чумы и поход Тамерлана в конце XIV в. – все это привело территорию Самарской Луки в запустение почти на два столетия, – дип яза алар. – Памятники XV–XVI вв. здесь археологом пока неизвестны. Земли Самарского края становятся пограничными между Русским государством и Великой Степью» [Древности Самарской Луки: 2011. С. 21–22].

Һәм алар өчен Самар ярымутравында яңа тарих XVI гасырның урталарыннан – Казан ханлыгы юк ителеп, аның җирләренә урыслар күчеп утыргач башлана, бу яңа тарихта татарларга инде урын юк. Биредә тарих болгар белән башлана, урыс белән бетә, уртадагы зур катлам – татар катламы өйрәнелми дә, аның турында язылмый да. Бу дөрес хәл түгел, әлбәттә. Самар ярымутравының ике гасыр буе урысларны көтеп буш ятуы да дөрес түгел, биредә тормыш булган, Казан ханлыгы чорында татарлар монда хуҗа булып, шәһәрләр төзеп яшәгән, бу хакта Лепехин да, Поливанов та язып калдырган. Казан ханлыгы юк ителгәч тә әле монда татарлык чаткылары калган булган, чөнки халык хәтле халык алай тиз генә юкка чыга алмый. Боларга әле алга таба тукталырбыз.

Кызганыч, Самар ярымутравын 1923, 1928–29-нчы елларда махсус өйрәнгән Вера Владимировна Гольмстенның язма архивы юк дәрәҗәсендә, ә ул үзе 1942-нче елда Ленинград блокадасында ачтан үлә. Ул Муромский городокны да тикшергән була һәм аны болгар чоры тарихи ядкәре буларак бәяли. «К сожалению, результаты этих исследований остались неопубликованными, – дип яза аның турында тарихчылар. – В статьях В. В. Гольмстен содержится лишь самая общая характеристика Муромского городка. Она правильно определила его культурную принажлежность болгарам и датировала памятник X–XII вв.» [Матвеева, Кочкина: 2005. С. 19].

1930–50-нче елларда Самар ярымутравы турында халык яратып укырлык фәнни-популяр китаплар язган тагы бер краевед бар, ул – М. А. Емельянов. Менә безнең кулыбызда аның ике китабы – «Жигули и круглосветка» (Куйбышев, 1938) һәм «Самарская Лука и Жигули» (Куй-

бышев, 1955) китаплары. Әлбәттә, ул да үзенә кадәр Самар ярымутравы турында язылган хезмәтләр белән танышып чыккан, шул чор идеологиясенә каршы килмәгәннәрне, шул заман күзлегеннән чыгып яктырткан. Самар ярымутравы турында, бигрәк тә, болгар-татарлар турында һәр хәбәр кадерле булганга, без аның да хезмәтләре белән җентекләп танышып чыктык һәм авторның яңарак фикерләрен укучыларга да җиткерергә булдык. Әлбәттә, аларның кайберләре бәхәсле, кайберләре фәнни дәлилләнмәгән, әмма автор теманы бик нык өйрәнгән, шуңа күрә, аның үз фикеренә хакы бар. Бигрәк тә ул Самар ярымутравының урыс басып алганнан соңгы тормышы күп нәрсәләрне ачып бирә...

Башта Емельяновның 1938-нче елда басылып чыккан китабына тукталыйк. Автор башта ук үз-үзенә каршы булган фикерләр белдерә: чуаш һәм мукшыларны Самар ярымутравына XVIII гасырда гына күчерелүләрен әйтә дә, иң борынгы тарихи ядкәрләрне, шәһәрлек һәм курганнарны чуаш һәм мукшыларныкы, дип белдерә. Әмма үзенең моңа бернинди дәлиле дә юк. Бу борынгы тарихны болгар-татарлар белән бәйләмәс өчен, автор әнә шундый уйдырмаларга да бара. Ә менә Мүрмән шәһәре турында язганда, ул инде берничек тә болгар-татарны әйләнеп үтә алмый, «Раскопки, произведенные в 1929 году, показали, что городок этот относится к типу булгарских городов XIII века», – дип яза [Емельянов: 1938. С. 78].

Емельянов ике китабында да Муромский городокның үзәгендә кремль булганлыгына ишарә ясый, биредә таш биналар барлыгын әйтә, шулай ук балчык һәм агач өйләр дә булуын яза. Болгар шәһәрен юк итүче итеп ул ачыктан-ачык татарларны күрсәтә, димәк, бу чорда инде шундый караш формалаша башлаган булган. «Муромский городок погиб около 700 лет назад, при движении татар на запад, разоривших до основания булгарского царства», дип яза ул [Емельянов: 1938. С. 78]. Югыйсә, бу автор Лепехин һәм Поливанов хезмәтләрен укыган булырга тиеш бит, алар исә хәтта Казан ханлыгы чорында да биредә татарлар яшәгәнлеген язып калдырганнар!

Валы авылының барлыкка килүен автор монахлар белән бәйли. «С 1660 года Самарская Лука переходит во владения монастыря Саввы Сторожевского, после чего начинается усиленная колонизация ее, – дип яза ул. – …Основания Валов связано с периодом пребывания на Самарском Луке монахов Саввинского монастыря, которые здесь имели свою вотчину» [Емельянов: 1938. С. 4, 79]. Күргәнегезчә, әле XVII гасыр урталарында ук Самар ярымутравы Мәскәү монастыры, ягъни, чиркәү карамагына бирелгән булган, ә алар бары тик җирле халыкларны христиан диненә кертү өчен генә юлга кузгалалар. Самар ярымутравына чуаш-мукшылар-

ның бары тик XVIII гасыр башында гына крепостнойлар буларак күчерелүләре билгеле, димәк, XVII гасыр урталарында биредә җирле халык булып татарлар торган, Мәскәү поплары аларны чукындырырга дип юлга чыккан.

Усоль елъязмасына таянып, Емельянов Валы авылына нигезне Малыклы ягыннан килүчеләр салган, ди, әмма безнең фикеребезчә, биредә инде алар килгәндә Мүрмән каласыннан күчкән татарлар яшәп яткан. Автор янәшәдәге Жигули авылына нигез 1570-нче елда салынган, дип бара, ул вакытта әле биредә чуаш-мукшыларның эзе дә булмаган, руслар да аз булган, димәк, Жигули авылының да беренчел халкы янәшәдәге Мүрмән каласыннан күчкән татарлар булырга тиеш. Мәскәүдән килгән урыс монахлары җиң сызганып менә шуларны чукындырырга тотынганнар да инде, җирле халык дин белән бергә телне дә алган, урыс чолганышында калган татарлар инде берничә буын эчендә шул милләт составына күчеп беткәннәр, чөнки башкача исән калу мөмкин булмаган...

Чуаш авылы Кармалы янындагы борынгы шәһәрлекне Емельянов болгар чорына керткән, аның элеккеге исеме Хула-ду икәнлеген әйткән, хәзер исә бу урын фәндә «Кармалинское городище» буларак билгеле. «Из доисторических памятников села заслуживает внимание городище Хула-ду, – дип яза ул. – ... Археологи относят Кармалинское городище к периоду булгарских поселений на Самарской Луки» [Емельянов: 1938. С. 109–110]. Автор шулай ук Березовка авылы янындагы Бөркет тавы түбәсендә дә болгар шәһәрлеге булганлыгын язып үтә [Емельянов: 1938. С. 157]. Ә Александровск авылында XX гасыр башында бер чүлмәк хәзинә тапканнар, анда 4 килограмм татар акчалары булган. «В 1911 году крестьян Гадалин при распашки земли нашел глиняной горшок со старинными монетами татарской чеканкой весом до четырех килограммов», – дип яза Емельянов [Емельянов: 1938. С. 170]. Хәзер кайда ул татар акчалары – билгесез, югыйсә, кайда һәм кайчан сугылганыннан чыгып, биредә татарларның кайсы чорларда яшәгәнен билгеләп булыр иде.

Емельянов хезмәтеннән Самар ярымутравының урыслар басып алган чоры турында шактый мәгълүмат табарга мөмкин. Әйтик, әле 1557-нче елда ук бирегә атаман Ляпун Филимонов отряды җибәрелә, имеш, Явыз Иван шулай итеп нугайларны сакларга тели икән! Моңа автор үзе дә ышанмый, урыс патшасы Идел буенда басып алган җирләрне сакларга теләгән, дип яза. «Конечно, русскому царю хотелось не столько оберегать ногаев, сколько закрепить за собою захваченные в Поволжье земли, – дип яза ул. – В 1614 году сюда был отправлен отряд в 500 стрельцов, с наказом построить укрепленный пункт в том месте, «где переволочатся с Волги на Усу-реку» [Емельянов: 1938. С. 121].

Шунысын да әйтергә кирәк, Самар ярымутравындагы кайбер авыллар Явыз Иван тарафыннан купец Строгоновларга бүләк ителә, алар монда тоз чыгара башлыйлар. Аннан Самар ярымутравы, кешеләре-ниләре белән бергә, Мәскәү монахлары кулына күчә, аннан – Меньшиковларга, аннан – Биронга, аннан – Давыдов-Орловларга бүләк ителә. Читтән килгән бу байлар Самар ярымутравының җелеген суыралар, аннан алырдай бар нәрсәне дә алалар, утрауны бушка эшләүче крепостнойлар белән тутыралар. «В 1710 году по приказу Петра I были переселены на Самарскую Луку из вотчины Г. Головина (Пензенского уезда) 700 крепостных крестьян», дип яза Емельянов бу хакта. [Емельянов: 1938. С. 4].

*(Дәвамы бар)*

## Әдәбият


Археологические памятники на территории города Самары. – Самара, 2005.

Бәйрәмова Фәүзия. Туран иле. – Казан, 2008.

Булгарская цивилизация на Волге. – Самара, 2011.

Вестник древней истории. № 4, 1939.

Вестник «Самарская Лука», 2008, № 1.

Галимов Шамиль. Прошлое как вера в будущее. – Самара, 2012 а .

Галимов Шамиль. Счастье жить на земле предков//Самар татарлары, 2012 б, № 1, декабрь.

Древности Самарской Луки. – Самара, 2011.

Емельянов М. А. Жигули и круглосветка. – Куйбышев, 1938.

Лепехин И. Дневные записки путешествия доктора и Академии наук адъюнкта Ивана Лепехина по разным провинциям Российского государства 1768 и 1769 году. – Санктпетербург, при Императорской Академии наук. 1771.

Матвеева Г. И., Кочкина А.Ф. Муромский городок. – Самара, 2005.

Муромский городок. – Самара, 2002.

Наследие Волжских булгар. – Казань–Самара, 2013.

Павлович И., Ратник О. Тайны и легенды волжской подземелей. – Самара, 2003.

Павлович И., Ратник О. Миражи над Жигулями. – Самара, 2002.

Паллас П. С. Путешествие по различным провинциям Российского государства. – СПб, 1773–1778. Ч.1.

Пока мы помним, мы живы. – Самара, 2013.

Поливанов В. Н. Археологическая карта Симбирской губернии. – Симбирск, 1900,

Сабирзянов Г. С. Народы Среднего Поволжья и Южного Урала в панораме веков. – Казань, 1995.

Садовников Д. Н. Сказки и предания Самарского края. – Самара, 1993 (переиздание с 1884 г.).

Самарский край в истории России. – Самара, 2004.

Самар татарлары. Журнал. 2012–2013 еллар.

Самарская хронология. Составлена А. Г. Елшиным. – Самара, 1918.

Смирнов Ю. Н. К 160-летию Самарской губернии: зачем и как она была создано? – Самара, 2011.

Царев Курган. Древности Самарского края. – Самара, 2003.

# РИВАЯТЬЛЕ, ҖЫРЛЫ-МОҢЛЫ САМАРА

*Л. Х. Мөхәммәтҗанова*

Бөек Тукай әйткәнчә, «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул». Элекке дәверләрдән туплана килгән тормыш тәҗрибәсе, зирәк акыл, тапкыр фикерләр, тәрбия алымнары, әхлак нормалары, күңел дөньясының, матурлыкның үзенчәлекле чагылышы, хәерле гамәлләрне аңлау-тоемлау рәвеше, дин, фәлсәфә, хәтер – болар бар да халыкта яши торган тиңсез хәзинәләр. Халык бар икән, димәк, аның күңел байлыгы да исән-сау, ул байлык, тарихның үзе кебек, үсеш-үзгәрештә. Галимнең бурычы – әнә шул хәрәкәтнең кабатланмас чаткыларын, әһәмиятле мизгелләрен билгеләп калу, бөртекләп җыйнау, теркәү, өйрәнү аша мөһим ачышлар ясау, халыкныкын халыкка кире кайтару.

Җирдә татарлар аяк басмаган урын юктыр да бәлки. Тарихчы галим Дамир Исхаков әйткәнчә, татарлар кебек сибелеп яшәгән башка халыкны Россиядә табып булмый. Халкыбызның бай тарихын, мәдәниятен, фольклорын төрле төбәкләрдә гомер итүче милләттәшләребез күп гасырлар буена барысы бергә бар иткән. Шуңа да рухи байлыгыбыз татарны татар итеп саклый торган бергәлектә, бөтенлектә генә бар тулылыгы белән ачыла. Ә мирасның үз вакытында тарихка теркәлеп калуы халкыбызның бөеклеген раслый, башка милләтләр янәшәсендә барлыгыбызны, дәрәҗәбезне тәэмин итә. Таралып яшәүче татар халкының тел-авыз иҗатын Татарстан районнарында гына туплау бик аз, бу җәһәттән Россиянең һәм хәтта чит илләрнең татарлар күпләп яши торган төбәкләренә дә игътибар бирү таләп ителә.

Самара өлкәсе – «Кая барсаң, шунда – татар» дигән гыйбарәне чын-чынлап аклый торган урыннарның берсе. Биредә Татарстанның татар авылларындагы кебек үк татарча иркен аралашып була торган, татарча сөйли, татарча фикерли, татарча эш-гамәл кыла, тормыш алып бара торган милләттәшләребез яши. Алар Россиянең көньяк-көнчыгышында, Урта Иделдә урнашкан Самара өлкәсендә берничә гасырлардан бирле компактлы рәвештә гомер кичерәләр, зур-зур авыллар корып яшәп яталар. Бүгенге көндә өлкәдә 126 меңнән артык (бу – барлык халыкның 4,1 % дигән сүз) милләттәшебез яши.

Бу якларда татарларның элгәрләре Идел буе Болгары, соңрак Алтын Урда составына кергән Самара тугаенда (Самарская Лука) яшәгәннәр [Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации: 2016. С. 202]. Иделнең Җигүле таулары тирәсендәге, Россиянең уникаль территорияләренең берсе саналган бу урыннарда Идел буе Болгарының мон-

гол явынача кадәрге чорына ук караган бик күп археологик истәлекләр саклана. Әйтик, Болгарның көньягында чик буе ныгытмасы ролен башкарган, шактый эре һөнәрчелек үзәге дә булган Муром шәһәрчеге; Самара өлкәсе Сызрань районы җирләрендә Алтын Урда чорына карый торган Елгаара шәһәрчеге төркиләргә мөнәсәбәтле әнә шундый һ.б. тарихи урыннары белән мәгълүм бу җирләр.

Казан алынганның соңында хәзерге Самара өлкәсенең төньяк-көнчыгыш өлешенә йомышлы татарлар күченеп утырып, Гали, Камышлы, Татар Байтуганы кебек зур авылларга нигез салганнар. Казан, Сембер өязләреннән Самара өлкәсе территориясенә хәрби хезмәт үтәүче йомышлы татарлар яисә төрле ныгытмалар, хәрби корылмалар төзүдә катнашучы ясаклы татарлар килеп урнашу XVII, XVIII гасырларда да бик актив дәвам иткән. XVIII–XIX гасырларда бирегә – Иделнең буш яткан сул як ярына – Алатыр, Касыйм, Курмыш, Пенза, Саратов, Тамбов өязләреннән татарлар агылган һәм алар бирედә төпләнеп яшәп калганнар. 1897-нче елда Самара губерниясендәге халыкның 11,2% ын татарлар тәшкил иткән [Татарская энциклопедия: 2015. С. 228]. Октябрь инкыйлабына кадәр Самара губерниясендәге татар авылларының барысында да мәчетләр эшләгән, Камышлы, Мәчәләй, Яңа Мансур, Иске Ярмәк кебек зур авылларның һәркайсында хәтта дүртәр мәчет булганлыгы мәгълүм. XX йөз башынача Самараның үзендә дә мөселман җәмгыяте яшәп килгән, Җәмигъ мәчете, мәктәп, мәдрәсәләр эшләгән, татарча уникаль «Икътисад» журналы чыгып торган.

Бу якларда татарларның күплеге Октябрь инкыйлабыннан соң да бирედә татар мохитенең саклануын һәм үсүен тәэмин иткән, милли-мәдәни тормыш әле бу чорда да күтәрелеш кичергән. Әйтик, 1930-нчы елда хәзерге Самара өлкәсе кысаларында алсак, бирედә 435, ә Самараның үзендә 3 татар мәктәбе эшләгән. 1941–56-нчы елларда Камышлыда Татар педагогика училищесы татар телле белгечләр хәзерләгән. Болар барысы да бүгенге көнгә кадәр Самара өлкәсе татарларының үзбилгеләнүенә, милли аңына тәэсир итә килгәннәр, бирედә әле дә татарча уйлый, татарча укый-яза белгән, туган телендә риваятьләр сөйли, җырлар җырлый торган буынның чагыштырмача яхшы сакланган булуы әнә шул факторлар белән тыгыз бәйле булса кирәк.

Үз милләтебез берничә гасыр элек үк тамыр җибәргән төбәк буларак, Самара татарлары галимнәрне күптәннән кызыксындыра. Әле XX йөзнең алтмышынчы елларында ук бу якларга И. Надиров, Х. Мәхмүтов, Ф. Урманчеев, Ф. Әхмәтова, Х. Гатина кебек фольклорчы галимнәр экспедицияләргә чыгып, материаллар туплап алып кайтканнар, аларны академик басмалар төзегәндә кулланганнар, Самара татарларыннан җыелган рухи энҗеләрне

милли мирасыбыз буларак бәяләгәннәр. Ярты гасырга якын вакыт аралыгыннан соң бу төбәкнең халык авыз иҗатында, телендә-сөйләмендә, халык музыка сәнгатенең яшәешендә, археографик, ташъязма һәм этнографик мирас сакланышында һ. б. нинди яңалыклар, үсеш-үзгәрешләр, табышлар һәм югалтулар булуын экспедиция нәтиҗәләре ачык күрсәтә.

2014-нче елда Самараның Похвистнево, Келәүле һәм Камышлы районы татар авылларына Татарстан Фәннәр акдемиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган комплексы экспедициядә барлыгы 8 кеше катнашты. Экспедиция составында – телче галимә, диалектолог Ф. Баязитова, профессиональ фотограф Р. Мөхәммәтшин, сәнгать белгече, филология фәннәре кандидаты Л. Шкляева, археографлар, филология фәннәре кандидатлары А. Гайнетдинов һәм С. Галимов, фольклорчылар, филология фәннәре кандидаты, экспедиция җитәкчесе И. Ямалтдинов һәм филология фәннәре докторы Л. Мөхәммәтҗанова. Һәр белгеч үз спецификасына муафыйк максатларны тормышка ашыру юнәлешендә эшләде. Самара татарларының рухи һәм матди мәдәнияте төрле яклап бик кызыклы. Биредә, авыл-авыл булып, татарның төрле этник төркемнәре вәкилләре яшәп ята: Идел буе Болгары, Алтын Урда чорларыннан алып, XXI гасыр башынача бу территорияләр казан татарларын да, төрле як мишәрләрен дә җәлеп иткән. Тел, гадәт, конфессиональ уртаклык боларның үзара аралашып, кан алмашып яшәүләрендә дә киртә тудырмаган. Самара өлкәсе территориясендә татарларның керәшен этник төркеме вәкилләре дә аерым авыллар булып, үз традицияләренә тугры тормыш итәләр.

Фольклорчы буларак, минем тарафтан төп игътибар, әлбәттә, халык авыз иҗаты үрнәкләрен барлауга юнәлтелде. Халык белән әңгәмә корулар нәтиҗәсендә авыз иҗатына хас бик күп үрнәкләр язып алынды, шушы төбәккә генә хас булган тарихи һәм мифологик риваятьләр, авыл тарихлары, уеннар, җырлар, йола фольклоры, төрле ышануларга бәйле барлыкка килгән яисә халык китаптан укып сөйләгән гыйбрәтле хикәятләр, бәетләр, мөнәҗәтләр, мәзәкләр, мәзәк хәлләр архивыбызны баетты. Ачык йөзле, сүзгә оста информантлары, куллары шифалау үзлегенә ия халык табиблары (әйтик, Яңа Мәчәләйдән Асия апа Әмирова), оста гармунчылары, гармун ясаучылары, тәмле сулары, татлы бавырсаклары, исламны хөрмәт итеп яши белә торган халкы белән күңелгә керде бу төбәк.

Язып алынган фольклор әсәрләре – ерак тарихта булып узган вакыйгаларның кайтавазы, алар аша халыкның язмышын, фаҗигасен, моңсагышын, шул ук вакытта сынауларга бирешмәү теләгенең зурлыгын, аң-белемгә омтылышының тирәнлеген, күңел көрлеген тоемлау кыен түгел. Нинди генә язмышлар бирегә китергән булуга карамастан, һәр мәсьәләгә

ныклы үз карашы формалашкан тырыш, гаярь, җор телле, ушлы Самара татарлары бүгенге көндә – милләтебезнең тулылыгын, бөтенлеген тәэмин итеп торучы шактый эре катлам. Биредә очраган һәм язып алынган авыз иҗаты әсәрләре исә – татар халык иҗатының бүгенге торышы, халкыбыз яшәешенә, бай тарихына, гореф-гадәтенә, аның бүгенге сулышына тере мисал. Рәхим итеп, Самара өлкәсе татар авылларында язып алынган кайбер фольклор материаллары белән таныша аласыз.

**Гали авылына кем нигез салган?**

*(тарихи риваять)*

Гали авылының 400 еллыгын билгеләделәр күптән түгел. Документлар буенча шулай.

Бу якларга өч кеше килә. Берсе урыс – Владимир Подольский, икенчесе чуваш – Эрзи Рысаев, ә өченчесе татар – Котлыгыш булган. Котлыгышның кайсы яктан монда күчеп килүе турында төрлечә сөйлиләр. Минемчә, ул монда хәзерге Татарстандагы Буа районыннан бер татар авылыннан килгән булырга тиеш. Арча, Балык бистәсе якларыннан килгән диючеләр дә бар. Буа районыннан килгән диләр инде күбрәк.

Боларга мең ярымышар гектар җир тигән. Котлыгыш монда өч улы белән килгән. Уллары Галигә – 27, Солтанга – 19, Якупка 16 яшь була. Солтанны патша хезмәтенә армиягә алалар. Якуп Оренбург далаларына чыгып китә. Ә Гали монда кала. Котлыгыш үзе Похвистневоның бер өлешендә ике тау арасында бер авыл төзеп урнаша. Ул авылның исеме дә Котлыгыш исеме белән аталган. Әткәй әйтә торган ые Сукайга (Сукай – авыл исеме, русчасы – Сукеево. – Л.М.) кунакка барганда: «Әнә Котлыгыш бабкайның җирләре», – дип. Шәп урыннар. Бер 60–70 еллар элек бетте Котлыгыш авылы.

Котлыгышның уртанчы улы патшага 20 ел хезмәт итеп кайта. Бик яхшы хезмәт иткән өчен алдан кайтаралар Солтанны. Тауга менеп басып, кулын сузып күрсәтә алган кадәр җир алырга рөхсәт итеп кайтара моны патша. Солтан шулай итә. Аңа 2 мең гектар җир тия. Менә шушы җирдә ул авыл төзи. Солтангол дигән авыл хәзер дә бар. Ул авылга Котлыгышның уртанчы улы Солтан нигез салган булып чыга.

Котлыгышның кече улы Якуп, 40 ел узгач, Оренбург якларыннан кабат монда әйләнеп кайта. Шушы Галидә төпләнә, монда аларның нәселләре бар.

Ә Котлыгышның олы улы Гали шушы Галигә нигез сала. Авыл аның исеме белән атала. Атасы-бабасының, үзенең дә туган җиренә кире кайтып китеп, монда кабат җиде гаиләне – туганнарын, якыннарын алып килә. Менә шулар хәзерге зират янында подвал казып, җир астында яши башлаганнар әүвәл. Ул тирәләр күл, сазлык булган. Нутрия, андатра, ба-

берлар булган. Килеп урнашып, галиләр башта шуларны тотып сатып көн иткәннәр. Тау өсте – коры. Саураш (Саураш елгасының русча исеме – Савруш. – Л. М) елгасын чыгуга ике сәгать аерма, Оренбург өлкәсе башлана. Галиләр шундагы алпавытларга бодай үстерергә ялланалар. Шуннан үз җирләрендә – Красный мост (Красный мост – Самара өлкәсендәге поселок. – Л. М.) ягына барып (анда корырак), бодай игә башлыйлар. Унар капчыкны, бер йөк итеп, Самарада беренче ачылган хлебзаводка илтә торган булганнар. 1670–80 еллар була бу. Сарык үрчетәләр, йонын саталар. Кемдер тимерче булып китә. Бабер, нутри тиресе саталар, пешереп икмәк саталар. Шулай ныгып китәләр, байыйлар.

Шуннан кушылып үскән инде Гали авылы. Без – Гали бабкайның сигезенче буыны. Бу авылда һәркем үзен Гали оныгы, аның дәвамчысы дип саный.

*(Әхмәдиева (кыз фамилиясе – Йосыпова) Асия Хәлимулла кызыннан (1958 елгы). Похвистнево районы Гали авылы).*

## Борынгы курган

*(тарихи риваять)*

Гали авылы янында биеклеге 70 метрлы курган бар. Аны Чыңгыз хан явыннан калган курган диләр. Моннан Чыңгыз хан үзенең гаскәре белән узган. Идел ягыннан килгән бер ише, бер ише – Оренбург ягыннан. Шушы тирәдә Чыңгызның бер атаклы генералы үлеп калган. Аны шунда күмеп, биек курган ясаганнар. Ул курган Гали авылы белән Ырсай авылы чигендә.

*(Әхмәдиев Рәфхат Алтынхуҗа улыннан (1957 елгы). Похвистнево районы Гали авылы).*

## Морат бабкай чишмәсе

*(тарихи риваять)*

Морат бабкай Гали авылында моннан 210 еллар элек яшәгән. Ул мулла булган, соңынан – авыл старостасы. Аны, каты куллы, кырыс кеше булганга, янсыз (җансыз, кансыз – Л. М.) дигәннәр. Халыкны тәртипкә күндереп, авылны тотып торган.

Патша хөкүмәтеннән арбалы ат белән 18 солдат килә авылны чукындырырга дип. Тау өсләп киләләр 18 обоз (18 ат йөге. – Л. М.) тәреләр төяп. Киләләр болар, хәзерге турбаза янында авылның ике йөзләп ир-аты каршы ала боларны саф-саф булып тезелеп. Кайберәүләр куркып та кала чукындыручылардан. Морат бабкай әйткән:

– Беркем дә чукынмый! Ничек йөрдек моңа кадәр мөселман булып, шулай калабыз.

Патша солдатлары һавага атарга тотыналар. Сугыш китә. 18 солдатның 11ен үтереп, тау тишегенә күмеп куялар, алып килгән йөкләрен калдырып, калган 7 се кайтып китә. «Барыгыз, кайтып сөйләгез» –, дип

озаталар аларын. (Алардан калган тәреләрне күрше чуваш авылларына барып, сатып йөрүчеләр дә булган әле.)

Шушы хәлдән соң бу эшне оештырган Морат бабкайны җәзалыйлар. Бабкайның ике күзен чокып чыгаралар да үзен таллыкка ыргыталар. Бабкай өч көн дога кылып, Аллаһыга ялварып шунда ята, өч көннән үлә. Аны шунда җирлиләр. Ул үлгәч, бу урында чишмә бәреп чыга. Чишмә Морат бабкай кабере янында, шуңа күрә бу чишмәне халык Морат бабкай чишмәсе дип йөртә. Чишмәне авыл байлары карап тора.

*(Саниева Фатыйма Габделфәт кызыннан (1953 елгы). Похвистнево районы Гали авылы).*

**Түгәрәк уен**

*(уен-йола фольклоры)*

Түгәрәккә басасың егетләр, кызлар – барың бергә. Кемдә нинди матур ерлар бар, бары да ерлана шунда. Ерлый-ерлый әйләнәләр. Шунда берәү түгәрәктән чыга да үзенә пар сайлап ала. Икесе бергә түгәрәк эчендә парлап әйләнәләр. Түгәрәктәгеләр дә әйләнә, түгәрәк эчендәгеләргә атап ер ерлана. Аннары уртадагыларның башта чыкканы кабат түгәрәккә баса, эчтә калганы үзенә икенче пар сайлый. Инде аларга ерлана:

Әйдим, әйдим, ник бармыйдыр,
Болар нинди яман алаша.
Әле күргәнемә күп түгелдер,
Болай сагындыра тамаша.
Кара урманнарны чыккан чакта
Калды камчыларым каерылып,
Камчыларым өчен үкенмим,
Калды туганнарым аерылып.

*(Кәлимуллина Мөхлисә Кәлимулла кызыннан (1939 елгы). Похвистнево районы Нугай (Нугайка) авылы).*

**Хат**

*(эпистоляр жанр үрнәге)*

Бер ирне солдатка алалар. Башкаларга карамасын, дип, хатынына болай дип хат язып җибәрә бу:

Алтын балдак кадакта
Барысына да кояш булма,
Калырсың бит азакка.

*(Зарипова Фәимә Әхмәтшәриф кызыннан (1957 елгы). Похвистнево районы Гали авылы).*

## Нугай авылы исеменең килеп чыгышы

*(тарихи-топонимик риваять)*

Монда сплошной урман булган элек. Нагайка – кыска камчы. Байлар шул камчы белән кыйнап, кешеләрне урман кистергәннәр. Шуннан Нагайка дип калган бу авылның исеме. Чын исеме шулай.

*(Алтынбаева Хания Галәветдин кызыннан (1940 елгы). Похвистнево районы Нугай авылы).*

## Кемнең җен күргәне бар?

*(мифологик хикәят)*

Күп укыган кешегә җен ияләшә ди. Миңа да ияләште бервакыт. Ахшам укыдым. Караңгы. Дисбе тартып утырам. Карасам, дисбем төймәләре арасыннан ике ялтыр күзле кап-кара нәрсә килеп чыкты. Бәләкәй генә үзе. Кит, дим, «Лә һәүлә вә лә куватә»не укып, күзенә төкерәм. Китми дә, күзен дә йоммый. Шуннан кызымны чакырдым. «Инәкәй, әйдә сызыйк», *– ди кызым.* «Аятелкөрси»не укып, икәүләп пычак белән стенаны сызып чыктык өй эче буйлап. Икенче көнне двухстволка мылтыктан аттырдык куркытыр өчен. Шуннан бетте теге җен.

*(Моратханова (кыз фам. – Галимова) Наилә Закир кызыннан (1936 елгы). Похвистнево районы Гали авылы).*

## Аш җыю тәртибе

*(йола фольклоры)*

Ашка чакыралар. Коръән ашына. Әйтик, үлгән кешенең елына. Башта ирләр килә. Анда мулла була була инде. Мулла вәгазьдән башлый. Коръән укыла, ясин, тәбарәк, багышлаулар була, сәдака өләшенә. Ирләр таралгач, хатыннар килә. Хатыннар табынында абыстай башлый. Салават әйтелә, тәхлил чыгалар, Коръән укыла, ирләр ясин чыккан булса, башкасын укый абыстай. Үзара сәдака өләшәләр хатын-кызлар да, багышлаулар була. Ирләр табынында да, хатыннар табынында да хәзрәт әйткән яки абыстай әйткән кеше белгәнен укып күрсәтү бар. Ашта мөнәҗәт әйтелми. Мөнәҗәтләрне Мәүлед кичәсендә әйтәләр. Аштан соң йорт хуҗасына рәхмәт әйтеп, багышлау укыла, алып килгән күчтәнәчләргә дә дога кылына.

*(Кәлимуллина Мөхлисә Кәлимулла кызыннан (1939 елгы). Похвистнево районы Нугай авылы).*

## Йорт анасы

*(мифологик хикәят)*

Йорт анасы бит ул кеше күзенә төрле нәрсә булып күренә. Күренмәскә дә мөмкин. Күренмәсә дә, һәр йортта бар ул. Аның турында күп сөйләргә ярамый бит. Үпкәләткәнне яратмый ул, борчый башлый. Башка

йортка күченә калсаң, аңа әйтәсең: «Әйдә, хуҗа,миннән калма, миңа ияр. Сакла мине». Шулай дип әйтергә кирәк.

*(Алтынбаев Габделкави Габделхак улыннан (1940 елгы). Похвистнево районы Нугай авылы).*

**Красный мост авылы риваяте**

Авыл Красный мост дип ник аталган? Татар авылы булса да, исеме русча гына йөри. Богорусланга китә торган юлда бер күпер булган. Кызылга буялган күпер. Красный мост авылы әле егерменче еллар ахырында гына барлыккак килгән. Ә күпер Әби патша заманында ук булган. Каторжан юлы узган шул күпер аша. Сәнәк сугышы вакытында аклар күперне яндырган. Ул күпер беткәнгә күптән инде. Авылга исеме генә калган.

*(Вакказов Газизнур Мөхәммәтнур улыннан (1938 елгы) Похвистнево районы Красный мост авылы).*

**Кодагый, хәзер таң ата**

*(мәзәк)*

Базарга барган да бер хатын, кайтышлый кодагыена кагылган. Кунарга калган. Кунакны ашарга бик кыстыйсы килми икән хуҗабикәнең.

– Хәзер таң ата, кодагый, хәзер таң ата, – дип, кунагын көттерә икән.

– Атыр, кодагый, атыр, атканчы бер ипине тартыр, – ди икән карыны ачкан кодагые моңа каршы.

*(Вакказова (Вәлиева) Хатимә Шәяхмәт кызыннан (1941 елгы Похвистнево районы Красный мост авылы).*

**Кемне сөйсә дә барыбер**

*(мәзәк)*

Бер килен кияве (ире. – Л. М.) белән яхшы тормаган. Муллага килгән киңәш сорарга.

– Татулык юк. Ирем сөйми башлады. Гел талаша. Балаларны ятим итәсем килми. Нишләргә? – ди икән.

– Мин сиңа бер дога язып бирермен. Ачма, укыма. Ирең талаша башласа, шул дога язылган кәгазеңне ал да тышка чыгып тор. Бераздан кер. – дигән моңа мулла, язу язып кулына тоттырган.

Кайтып киткән хатын муллага рәхмәт укып, сәдакасын биреп. Мулла әйткәнчә эшләгән инде. Яхшы тора башлаган болар. Өйдә татулык икән. Укыйк әле, ни язган икән мулла, дип, теге язуны ачып укыган хатын.

Аны сөйсәни миңа,
Моны сөйсәни миңа,
Биш тиен акчасын биргәч,

Кемне сөйсәни миңа! – дип язылган булган ди мулла биргән кәгазьдә.

*(Вакказова (Вәлиева) Хатимә Шәяхмәт кызыннан (1941 елгы). Похвистнево районы Красный мост авылы).*

### «Кач-кач»

*(уен, балалар фольклоры)*

Йөз чыбык чәчтереп җибәрәсең. Көтүче чәчелгән чыбыкларны җыеп бетергәнче качып бетәргә кирәк. Көтүче, чыбыкларның җыелганнарын берәрсе йөгереп килеп чәчмәсен дип саклый-саклый, йөз чыбыкны да җыеп бетерә. Чәчтерсә, кабат җыя башлый. Җыеп бетергәч, качкан кешеләрне эзләү башлана. Көтүчене болай саный идек:

Әтекәмә-сүтекәмә,
Әбел-фәбел думина,
Ике-пике раматака,
Зәйнеспис.

Кемгә «Зәйнеспис» сүзе чыга, шул көтүче була.

*(Йосыпова Рәйсә Гариф кызыннан (1932 елгы). Похвистнево районы Красный мост авылы).*

### Юктан бар итүче Аллаһ

*(мөнәҗәт)*

Үлем-яшәеш тормышны Аллаһы юктан бар итте,
Җиде кат күк, сигез җәннәтне, Җир йөзен бүләк итте.
Аллаһы – безне ярлыкаучы, яманлыктан саклаучы,
Аллаһ кушканнарны үтик тар гүрләргә ятканчы.
Аллаһыдан иң олуг әҗер, гөнаһлардан сакланыйк,
Җәннәт насыйп итәр безгә, гамәл кылсак мактанмый.
Көндәлек кылган эшебез үлчәү мизаннарында,
Игелекле саваплар басар яман эш кылынганда.
Җәһәннәм уты һәвия насыйп итмә һичкемгә.
Сират күперен үткән чакта зинһар, тайдыра күрмә.
Аллаһы хуплар юмартны, хәер-сәдака бирик.
Аллаһ бөек, тәсбих әйтик, өскә бурычлар җыймыйк.
Игелек кылып, тәүбә итсәк, кабуллыкка ирешер,
Кыямәт көнне бар мөселман хисаплашыр, күрешер.

*(Морзаханова Саимә Әхмәдулла кызыннан (1947 елгы). Похвистнево районы Гали авылы).*

### Дини риваять

Рәсүлебез Мөхәммәд с. г. в. гә бер бәндә килеп кергән. Ашарга сораган. Мөхәммәд с. г. в. әйткән:

– Иман китер, ашатырмын, – дигән. Теге бәндә иман китермәгән, борылып чыгып киткән.

Шул хәлдән соң Мөхәммәд пәйгамбәр с. г. в. гә әйтә Раббыбыз:

– И Мөхәммәд, – ди, – Мин бөтен дөньяны ризыкландырам. Бер нәрсә сорамыйм. Син бер бәндәне ашатыр өчен аның иман китерүен шарт иттең. Кешенең күңеленә иман нурын үзем генә салам, син түгел. Рәнҗешен алма бәндәнең, хәтта ул башка диндә булса да.

Шуннан Мөхәммәд с. г. в. теге бәндәне куып җитеп, өенә алып кайтып ашатып чыгара.

*(Арсланов Ильяс Хафиз улыннан (1937 елгы). Похвистнево районы Гали авылы).*

### Яңа Мансур авылы турында

*(тарихи риваять)*

Мансурда халык төрле племялардан. Выты шыңа күрә халык төрлечә сүләшә. Например, кем атя бүлбе, без атябез бәрәңге алмасы. Мансур дигән кеше булган. Иске Мансур авылы – шул Мансур килеп утырган авыл. Халыклар килгән Казан ягыннан. Мәннан бабай булган Мансурның әтисе. Ул калган Әмәнәктә. Мәннанның өч улы булган. Яңа Мансур урынында башта мукшылар яшәгән. Мукшы очы хәзер дә бар. Мансур элгәре Иске Мансурга урнаша бит инде, анда алла белә күпмедер тора. Иске Мансур – мукшы авылы. Татар урамы диләр алар Мансурлар яшәгән җирне.

Аннары Мансур Яңа Мансур җирләренә күчә. Мукшылар күченә Иске Мансурга. Бер семья гына кала. Монда инде Яңа Мансур дигән авыл төзелә. Башта ферма очына – Түбән очка урнашалар. Яңа Мансурга кабат төрле племялар килеп төпләнә.

*(Мусина Нәсимә Фәрдетдин кызыннан (1942 елгы). Похвистнево районы Яңа Мансур авылы).*

### Акыллы хатын

*(гыйбрәтле хикәят)*

Борын заманда булган бу. Бер бай кеше бер матур җирдә бакча ясаган. Җире фәкыйрә бер хатынныкы булган. Җәберләп, җирен алган булган моның бай кеше. Шул. Бер көнне бай бакчада йөргәндә бу хатын бай янына килә дә:

– Шул бакчадан бер капчык туфрак алыймчы, рөхсәт бирсәнә, – дип сорый. Ник бирмәскә, дип, бай риза була. Бай рөхсәте белән хатын бак-

чадан бер капчык туфрак тутыра да җилкәсенә күтәреп алып китмәкче була, байга әйтә:

– Шул капчык туфракны җилкәмә күтәртеп кенә җибәрсәнә, – ди. Байның гомерендә дә авыр әйбер күтәргәне булмаган инде. Алай да, мәрхәмәте килеп, күтәртеп җибәрим булмаса, дип, капчыкка тотына. Авыр капчыкны селкетә дә алмый, хәленнән килми.

– Юк, булмый, мин моны күтәрә алмыйм, авыр икән, – ди инде хатынга, нәрсә дисен. Шуннан хатын әйтә моңа:

– Ә-ә, шулаймы? Минем хакым булган шушы бакчадан бер капчык туфракны да күтәрә алмадыңмы? Бу бакчада әллә ничә мең капчык туфрак бардыр. Кыямәт көнендә аларын күтәреп Аллаһ каршына ничек барырсың соң? – ди.

Шулай акыллы итеп аңлаткан теге хатын моңа, байга сабак биргән булып чыга инде. Моны ишеткән бай:

– Мин гаепле, ал бакчаңны, – дигән, – гөнаһыннан тәүбә иткән.

(«Моны мин бер китаптан укыган идем. Иске китаптан. Гарәпчәне укырга әбием, Нәфисә апа, Шәмсекамәр апаларым өйрәтте. Кайсы китаптан бу сөйләгәннәрем – әйтә алмыйм». Хикәятне кемнән ишетүен сорагач, информант шулай дип җавап бирде. – Л. М.).

*(Булатова Шәмсегаят Миргаз кызыннан (1930 елгы). Похвистнево районы Иске Мәчәләй (Старая Мочалеевка) авылы).*

## Бавырсагың таралмасын!

*(Яңа Мәчәләй мишәрләрендә туй йоласы)*

Кыз ягында никах укытыла. Никахтан соң туйгача кияү кеше кыз йортында ята, монда аңа кияү мунчасы ягыла, кияү коймагы пешерелә. Туй көнне килен төшерү була. Туйга кыз бавырсагы пешерәбез. Килен төп йортка төшкәнче, башта бавырсагын алып китәләр, аннары – үзен. Бавырсакны пешерүнең үз тәртибе, кагыйдәләре бар. Пешереп, ширбәттә болгатып өеп куйганнан соң ике сәгать үткәч бавырсак оешмаса, таралып төшсә, гаилә дә нык булмый. Бавырсак тулысынча таркалып бетсә, бу хәл гаиләнең дә таркалачагына ишарә итә. «Бавырсагы таралган», – диләр аннары.

*(Әмирова Асия Әхмәтгали кызыннан (1956 елгы). Похвистнево районы Яңа Мәчәләй авылы).*

## Каз өмәсендә бәлеш урлау

*(йола элементы)*

Каз өмәсеннән соң кызлар йыелыштык. Бәлеш салынган. Егетләр килде. Такмак әйтеп йырлыйлар. Икесе яңа такмак өйрәнгән:

– Пешә төшә, – ди берсе. Аңа каршы икенчесе әйтә:

– Пешә төшсә, бөгелә төш.

– Бөгелә төшсәң, суы чыга.

– Суы чыкса, шу да чык.

Карасак, бәлешне чәлгәннәр (урлаганнар. – Л. М.). Бәлеш турында әйтешәләр икән болар үзара. Без такмак әйтәләр дип авыз ачып тыңлап торабыз. Ырланган бәлешне кире бирәләр иде. Бәясе – я түләгез акчагызны, диләр инде, я йырлаталар.

*(Әмирова Асия Әхмәтгали кызыннан (1956 елгы). Похвистнево районы Яңа Мәчәләй авылы).*

## Юкәле тау

*(топонимик риваять)*

Юкәле тавын Әүлия турысы дип йөртәләр. Ул тау Изгеләр тавы санала. Изге тауда әулия күмелгән дип сөйлиләр иде, шуңа «изге» диләр ул урыннарны. Тауның итәгендә элек карт ак каен үсеп утыра иде. Хәзер ул каен юк инде, картаеп, корып ауды. Солдатка киткәндә әле патша вакытында ук каен кәүсәсен чокып, егетләр исемнәрен язып калдыра торган булганнар. Шундый карт каен иде ул.

Монда элек Ярмөхәммәд исемле кешенең биләмәләре булган. Авылның исемен шуңа Ярмәк атаганнар. 1737 елда авылга рәсми нигез салынган дип барыла. Әмма чынлыкта авыл борынгырак, 500 еллап тирәсе бар аның оешуына.

*(Галимуллин Наил Нәбиулла улыннан язып алынды (1957 елгы). Камышлы районы Иске Ярмәк авылы).*

## Иске Ярмәктә солдатка озату җырлары

Сау бул, Ярмәк, сау бул, Ярмәк
Юкәле тауларың белән.
Сау бул, Ярмәк, рәхәт яшә лә
Калган яшьләрең белән.

Әткәй, әнкәй, сау булыгыз,
Еллар кайтмый улыгыз,
Бу китүдән кайталмасам,
Туганнар, сау булыгыз.

Сандугачлар килгән безгә,
Китәрләр микән көзгә?
Язгы ла Сабан туйларына
Кайтырбыз микән без дә?

Каршыбызда – Юкәле тау,
Тагын яшәрер әле.

Ходай гомерләрне бирсә,
Бергә яшәрбез әле.

*(Галимуллин Наил Нәбиулла улыннан (1957 елгы). Камышлы районы Иске Ярмәк авылы).*

**Дәүләтколда изге чишмә**

*(топонимик риваять)*

Иске Симәннән агып чыккан Камышлы елгасына тыкрык буйлап төшкәч тә Изге чишмә ага. Кыйблага таба ага, шуңа изге дигәннәр. Суы шифалы. Ул чишмә янында начар сүз әйтү түгел, начар уй уйларга да ярамый.

*(Галәлетдинова Тәлига Мәсәллим кызыннан (1932 елгы). Камышлы районы Дәүләткол авылы).*

**Әдәбият**

1. Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации. Справочник. Казань: Институт энциклопедии и регионоведения АН РТ, 2016. 335 с.

2. Татарская энциклопедия. В 6 т. Казань: Институт энциклопедии АН РТ, 2010. Т. 5: Р – С – Т. 736 с.

# ПАМЯТНИКИ ИСКЕ-КАЗАНСКОГО ИСТОРИКО-КУЛЬТУРНОГО И ПРИРОДНОГО КОМПЛЕКСА

*(Продолжение. Начало №№ 3, 4. 2018; № 1, 2019)*

***А. А. Бурханов***

## Часть 4. Памятники Иске Казани: современная окружающая природная и историко-культурная среда

***Аннотация:*** *В четвертой (заключительной) части статьи об Иске-Казанском комплексе дается детальная характеристика природной среды в бассейнах рр. Казанка (Казан су) и Урматка (Урмат су) в пределах рассматриваемой территории, истории старинной деревни Татарская Айша и экспозиции Музея «Иске Казани» в деревне Камаево, непосредственно связанных с археологическими и эпиграфическими памятниками городища Иске Казани.*

*В предыдущих частях публикации автор сделал общую характеристику всех объектов природного назначения и историко-культурного наследия в пределах Иске-Казанского комплекса, рассказал об основных итогах изучения археологических и эпиграфических памятников, проанализировал основные научные подходы по проблемам историко-культурного развития средневековой Иске Казани, а также рассказал об «святых местах» на территории Иске-Казанского музея-заповедника.*

***Ключевые слова:*** *Камаево, ИКГМЗ, территория, природа, деревня Татарская Айша, музей, коллекция, экспонаты.*

Изучая и характеризуя основные археологические и эпиграфические памятники на территории Иске-Казанского государственного историко-культурного музея-заповедника (ИКГМЗ) Министерства культуры РТ, мы не можем рассмотреть объекты историко-культурного наследия периодов средневековья без учета природно-географических условий на данной территории, так как заселение нашими предками конкретной территории в древности и средневековье, строительство сельских и городских поселений, были связаны с наличием благоприятных природных условий, прежде всего, водных, лесных и земельных ресурсов. Это ясно видно по современной природно-географической среде на территории и округе Иске-Казанского комплекса, расположению современных населенных пунктов в этом регионе в пределах бассейна рр. Казанка и Урматка.

**Природа Иске-Казанского комплекса.** В природно-географическом отношении территория ИКГМЗ является составной частью Казанского эрозионно-равнинного района темнохвойно-широколиственных лесов Вятско -Камской возвышенности Восточно-Европейской равнины [Физико-географическое районирование: 1964; 1974].

Территория заповедника тяготеет к долине, склонам и прилегающим плакорным участкам верхнего течения Казанки (68 км от ее истока) – главной водной артерии региона, делящей рассматриваемый район на две части – правобережную и левобережную, резко отличающихся друг от друга в природно-экологическом отношении. Правобережье – эта широкая – до 1,2 км, пойма, крутой уступ коренного берега, расчлененный овражной сетью и осложненный наличием осыпей, наконец, пологий склон, уходящий на север, сочленяющийся с плакорными участками равнины. Левобережье территории ИКГМЗ характеризуется сложным спектром террас, измененных в ходе хозяйственной деятельности, останцовыми поверхностями коренных пород, прорезанных долиной Урматки, техногенной морфоскульптурой (насыпи под железную и шоссейную дороги, глубокие выемки со склонами и т. п.).

Характерный элемент ландшафтно-экологического комплекса территории заповедника – эта огромная подковообразная «излучина» коренного берега Казанки, уступ которой на 50–60 м круто поднимается над поймой реки, образуя как бы обширный полукотел, обращенный к югу и юго-западу.

Важно также отметить антропогенную «перегруженность» всей экосистемы, что выражается в наличии сплошных сельскохозяйственных угодий (пашни, пастбища, сенокосы), селитебных территорий, коммуникаций (железная, шоссейные и местные дороги, ЛЭП, продуктопроводы, предприятия стройиндустрии, коллективные сады и дачи, населенные пункты, отсутствие лесов, поле – и водозащитных фитополос, защитных зон вдоль рек, наличие карьеров, отвалов и т.п.). Все это привело к глубокому нарушению всей экосистемы рассматриваемой территории: полной деградации и сведению растительных ассоциаций, отсутствию представителей фауны, загрязнению соединениями азота грунтовых вод и их выходов в виде источников, интенсивной плоскостной и овражной эрозии, отсутствию, смыву гумуса и почвы.

Почвенный покров территории ИКГМЗ пестр и связан с некогда существовавшей здесь коренной растительностью смешанных лесов и разнотравных лугов, а также с рельефом и литологией почвообразующих пород. Особое внимание, наряду с широким спектром подтипов почв, привлекают темно-серые аллювиальные черноземы, распространенные

на нижних частях левобережных склонов долины и надпойменных речных террасах [Дуглов: 1964. С. 76–78].

Климат региона умеренно континентальный с холодной зимой, теплым летом и достаточным количеством осадков.

Подавляющая часть территории занята культурной растительностью, причем доминирующая часть – это пашня, на которой выращиваются практически все основные виды сельхоз культур.

Современный растительный покров территории ИКГМЗ сформировался вследствие антропогенной трансформации потаежных хвойно-широколиственных лесов, сохранившихся в настоящее время в виде отдельных фрагментов в Высокогорском районе. Очевидно, в прошлом, до образования здесь поселений, местообитания как высокого правобережья Казанки, так и низкого левого берега, были заняты еловыми и сосново-широколиственными лесами, которые мы наблюдаем на территории близлежащих природных заповедниках и лесхозов РТ. Это ясно прослеживается на территории расположенного в Высокогорском районе Иске-Казанского лесничества. Вырубка лесных насаждений, пожары, выпас скота как в прошлом (особенно в средневековье), так и в настоящее время неизбежно привели к разрушению исходных коренных типов экосистемы. Из естественных растительных формаций сохранились луга, которые вытянуты вдоль Казанки. На крутом склоне долины, имеющем южную экспозицию, встречены степные элементы растительности, проникшие сюда с человеком. Это особенно относится к эпохе средневековья, когда из Южного Поволжья и других степных зон сюда проникали тюркоязычные номады, сменяя и обогащая этнический состав местного населения.

Сведение еловых и елово-широколиственных лесов привели к исчезновению типичных лесных видов животного мира. В настоящее время фауна представлена видами, характерными для существующих биотопов: пойменных лугов, остепененных лугов крутых склонов, поверхностных водоемов и водотоков, сельхозугодий, населенных пунктов.

Гидрографическая сеть территории ИКГМЗ богата и разнообразна. В ее состав, прежде всего, входит речная сеть (система), представляющая собой совокупность всех рек, сбрасывающих свои воды через главную реку (Волгу – Идел) в море. На рассматриваемой территории протекают 2 реки – Казанка (Казан су) и ее левый приток Урматка (Урмат су), являющиеся элементами волжской водной системы, соответственно, притоками первого и второго порядка.

Главная речная артерия региона имеет длину в 172 км, включая территорию заповедника, Казанка. Она считается средней по размерам рекой. Казанка протекает у Камаевского городища и неподалеку от Урматского

поселения и, конечно, сыграла значительную роль в поселении в этих местах людей в различные исторические периоды, развитии земледелия и скотоводства [Отчет: 1993; Бурханов: 2002. С. 12–14].

Урматка – малый левый приток Казанки, впадает в нее на территории деревни Камаево, в пределах региона территориальных интересов заповедника (на 68 км реки). Длина Урматки 14 км. Протекая по территории Урматского поселения и современных сельхозугодий, она разделяет земли памятника на 2 части.

Кроме этого, в пределах заповедника расположено несколько пойменных озер (озер-стариц), образовавшихся в процессе мигрирования русла Казанки, занимающих недоступное положение близ коренного берега долины реки.

На территории ИКГМЗ, тяготея к пойменным озерам, также расположены так называемые заболоченные земли.

Разветвленная сеть оврагов, расчленяющих правый, высокий коренной берег Казанки, является характерным элементом экосистемы территории заповедника, в весеннее время, а также на протяжении затяжных дождей, концентрирующая в себе значительную часть поверхностных вод региона, в итоге также относится к гидрографической сети территории ИКГМЗ. И наконец, в нее входят и ручьи, образуемые за счет двух источников – ханского и святого, выходящих на склоне коренного берега из известняков.

Подводя некоторые итоги рассмотрения природного ландшафта территории ИКГМЗ нужно выделить два основных этапа его формирования и развития.

Первый из них обусловлен тем, что естественный ландшафт благодаря благоприятному сочетанию рельефа, почв и растительного покрова послужил местом заложения разновременных поселений и средневекового города и крепости. Для этого существовали все природные предпосылки, в том числе своеобразный характер рельефа, позволяющий осуществлять оборонные функции поселений, наличие двух рек и множества ключей, обладающих хорошими питьевыми качествами, богатые почвенные разности и окружающие лесные массивы – все это создавало благоприятные условия для жизнеобеспечения населения данного региона.

Второй этап начинается с момента утраты естественным ландшафтом своих оборонных функций и ориентации на использовании его ресурсного потенциала. В настоящее время природно-территориальный комплекс рассматриваемой территории представлен следующими видами ландшафта: плакорный полевой, овражно-балочных систем (обнаженно-пустышные и относительно пологих склонов), пойменный лугово-пастбищный и пойменный агрикультурный и селитебный.

Помимо утилитарно-практического (ресурсного) назначения, рассматриваемый ландшафт более всего ценен с эстетических и исторических позиций. Красота лесного пейзажа, отражающая природу контактной полосы лесной и лесостепной зон, наличие естественных смотровых площадок, редкое сочетание большого спектра почвенных разностей, характерных для Республики Татарстан, дают основания для включения данного ландшафта в категорию охраняемых памятников природы. Поэтому, важным моментом в деятельности ИКГМЗ стало закрепление в законодательном порядке историко-культурных функций за данным природно-территориальным комплексом, что позволит развитию его эстетической направленности путем ограничения сельскохозяйственной деятельности и восстановления его естественно-исторических и культурных ценностей в рамках развития туризма и решения гуманитарных задач.

**Деревня Татарская Айша.** Это сельское поселение входит в охранную зону Иске-Казанского комплекса. Она расположена на левом, пологом берегу реки Казанки, в ее излучине. Севернее деревни по обеим берегам речки располагается пойменная территория, которая на правом берегу простирается до высоких холмов с крутыми склонами, защищающими селение с северной и северо-западной сторон. Почти перпендикулярно направлению реки склоны перерезаются оврагами. По дну левого берега в прошлом протекал безымянный ручей, ныне почти пересохший. По правому оврагу протекает река Ингшенка, впадающая в Казанку.

Наиболее древней частью селения является центральная прибрежная часть. Основная улица деревни, сохранившая свое направление еще с прошлых времен, тянется от моста вдоль берега р. Казанки. По мере роста населения застройка селения развивалась по направлению русла реки вдоль дороги на деревню Чурилино. Позже появилась застройка параллельно старым улицам. Наиболее поздней по времени является застройка по улице, пролегающей одним концом к кладбищу. Формирование застройки этой улицы продолжается и по сей день.

По географическому расположению, пространственно – планировочной структуре и историческим особенностям развития Татарская Айша является типичным селением казанских татар. Упоминание о нем в исторических источниках, обширное заросшее высокоствольными деревьями старинное кладбище, непосредственная близость к археологическим и культовым объектам Иске-Казанского историко-культурного и природного комплекса, свидетельствуют о многовековой истории селения [Проект зон: 1993].

О древности селения Татарская Айша говорит надгробный камень первой половины XVI в. с рельефной арабско-татарской надписью и ре-

льефным растительным орнаментом, находящийся на сельском кладбище [АК ТАССР: 1981. С. 51(193)].

В известном татарском историческом сочинении «Таварихе Болгария», написанном в начале 50-х гг. XVI в., эта деревня называется «Гайша-бикә авылы» («Деревня Гайши-бике») в честь героини «Повести о несгораемой царевне» [Хисамутдин: 1902. С. 20; Фахрутдинов: 1984. С. 155; 1986; 2000. С. 157–158; Бурханов: 1995; 1999. С. 75–76]. В ней в красочной форме рассказывается о чудесном спасении дочери хана Абдуллы – правителя Булгара. Дело в том, что когда Аксак Тимур (Тамерлан) взял город Булгар, то перебил все население. Хан Абдулла вместе со своей семьей скрылся в Судной палате. По велению Тамерлана палату обложили бревнами и подожгли. При пожаре погибла ханская семья, но чудом осталась жива его дочь-красавица, которую увидели сидящей на куполе здания. Царевну привели к Тамерлану. Прельщенный ее красотой и умом, он решил взять ее с собой вместе с братом (обстоятельства спасения этого брата – третьего сына Абдуллы-хана, в повести не сообщаются). После смерти Тамерлана они находились в услужении у его сына и как-то во время царской трапезы, Шеуне-бек (так звали ее брата) провинился, разбив дорогую посуду, и ему хотели отрубить голову. Однако он был прощен с условием – больше не появляться во дворце. Вскоре он со своей сестрой сумел уйти из плена и вернуться в родные края. Но увидев, что Булгар лежит в развалинах и что там нет жителей, они направились на север и прибыли в город Кашан. Вскоре царевна узнала, что ее братья Алтын-бек и Алим-бек живы и построили новый город на Казанке. Тогда она собралась в путь и поехала к ним. Вскоре она вышла замуж за полководца своего брата, которого звали Мулла-Хозятаз (или Софин-харака). Мулла-Хозятаз с ее братом Алтын-беком основали город Казан (сейчас остатки Иске Казани – Камаевского городища). Вскоре полководец умер и был похоронен в этих местах. Повесть указывает на иске-казанском кладбище его почитаемую могилу. Мулла-Хозятаз (в данном случае слово «мулла» применена как форма почтительного обращения, и не означает священного служителя), являясь полководцем, очевидно, сыграл большую роль в те годы, и его имя со временем не только сохранилось, но было канонизировано, он стал святым. Могила же «несгораемой царевны» – Гайши-бике, находящаяся недалеко от деревни Татарская Айша, как и могила Муллы Хозятаза (в настоящее время среди местного населения встречается другой вариант его имени – Муллы-Хаджи) считается также могилой святой и является объектом поклонения татарского населения Заказанья. О связи названия деревни с именем Гайши-бике свидетельствует также и факт лингвистического сходства.

Деревня Татарская Айша упомянута уже в Писцовой книге Казанского уезда 1602–1603 гг. [Писцовая книга: 1602–1603 гг.: 1979]. В ней, в частности, отмечено, что д. Нижняя Айша (Татарская Айша) является выселком из деревни Верхняя Айша, которая в начале XVII в. была заселена татарами и включала 2 помещичьих и 4 ясашных двора. В самой же д. Нижняя Айша в то время было два помещичьих двора: Байчюры Баишева и Едигера Шигалеева. Отмечаются также данные о землепользовании. В частности, под пашней было занято 50, перелогом – 110 и лесом поросло 140 четвертей. Существовали также два поля такой же площади, находящиеся под парами (трехпольная система земледелия). Помимо этого, указаны дубовый лес – 15 десятин, лес черный, которым владели совместно иске-казанские помещики князь Камай Смиленев и Еналей Елмаметов.

Первая планировочная схема деревни Нижняя Айша была составлена в 1793 г. В ней отмечалось, что деревня являлась владением служилых татар и включала 404 десятин пашни, 36 десятин 1483 саженей – лесу дровяного и строевого, 86 десятин 2200 сажени – дровяного леса, 10 десятин 1200 сажени – под селением, 10 десятин 770 сажени – под огородами, гуменниками, конопляниками. На р. Казанке находилась водяная мельница.

Во владении по записи за 1867 г. отмечено, что в д. Татарская Айша (по генеральному межеванию деревня зарегистрирована под №422) Мульминской волости Казанского уезда к январю 1867 г. числились 201 душа мужского пола. Указаны также крестьянские наделы (удобья) – 546,6 десятин, неудобья – 18,9 десятин. Итого – 565,5 десятин. За семьдесят четыре года пашня увеличилась на 142,6 десятин. Далее в записи на р. Казанке также отмечается мукомольная мельница, являющаяся общим владением села. Оброк за землю составлял 342 руб. 72 коп. Леса нет. Таким образом, за период с конца XVIII в. до 60-х гг. XIX в. весь лес был изведен, а земли – распаханы.

На карте Мульминской волости за 1910 г. отмечено селение Нижняя Айша с населением от 500 до 1000 человек, расположенное в двух с небольшим верстах от почтового Сибирского тракта и в трех верстах от почтовой станции Чурилино.

Ретроспективный анализ исторических планировок селения 1793 и 1983 гг., а также результаты визуального осмотра и опроса старожилов, позволили составить картину развития селения в XVIII–XX вв. [Проект зон: 1993; Бурханов: 1999. С. 74–78; 2014. С. 84–88].

Так, застройка конца XVIII в. в целом совпадает с центральной частью современной деревни. Планировочная структура отличается тра-

диционной для татарских селений нерегулярностью улиц. Особенность этого селения заключается в том, что оно не подвергалось перепланировке в конце XIX в. и его планировочная структура являлась исторически сложившейся.

Наиболее древнюю территорию представляет часть деревни, прилегающая к р. Казанке и состоящая из улицы вдоль речки и двух улиц, выходящих к ней. В этой же части размещены были практически все постройки инфраструктуры: сельская мечеть, караулка с противопожарной каланчой, торговые постройки, крупные барские усадьбы, питьевые источники и т. д. В дальнейшем планировочная структура складывалась вокруг этого исторического ядра, развиваясь вдоль существующих дорог, связывающих Татарскую Айшу с соседними деревнями.

Основу композиционной структуры поселения определяли, прежде всего, деревянная мечеть с минаретом и крупные байские жилищно-хозяйственные комплексы. По мнению старожилов, минарет мечети был снесен в 1934 г. Одновременно с этим раскатана и мечеть, которая затем была собрана вновь и использовалась в качестве школы и сельсовета. В настоящее время вход в здание клуба и библиотеки расположен на месте бывшего михраба мечети.

Торговые зоны деревни были представлены двумя магазинами. Один из них размещался на усадьбе муллы. По рассказам старожилов, торговлей занимался брат муллы, а по сообщениям известно, что усадьба муллы находилась рядом с усадьбой бая, занимавшегося торговлей и связанного узами родства с женой муллы. Второй магазин располагался в пределах усадьбы и сохранился до настоящего времени в качестве амбара-кладовой.

В деревне также была усадьба Башкорт-бая; в памяти старожилов сохранилась только его имя. Его дом до настоящего времени не сохранился. Однако, дошли территория усадьбы и обширные хозяйственные постройки, возведенные из речного камня и использовавшиеся, скорее всего, в качестве складских помещений. В том месте, где селение вплотную подходит к р. Казанке (при слиянии речки Ингшенки и Казанки, на ее правом – противоположном деревне берегу) до революции располагалась водяная мельница. В настоящее время постройки мельницы утрачены, однако ее местоположение указано старожилами и отмечено группой высоких деревьев.

На этом же правом берегу, чуть севернее, за речкой Ингшенкой бьет ключ, заключенный в сруб, являющийся основным питьевым источником. Вода из него вытекает по желобам. К источнику через речку ведет узкий дощатый мостик. Кроме этого питьевым источником служил колодец воротного типа на усадьбе муллы, расположенный напротив мечети на месте современного магазина.

Противопожарная зона д. Татарская Айша размещалась в одном из переулков недалеко от речки – это противопожарная караулка с каланчой.

Южнее мельницы – там, где р. Казанка раздваивается, образуя небольшой остров с высокой зеленью, размещен мост – основная коммуникация, связывающая Татарскую Айшу с заречными селениями. На левом берегу р. Казанки сохранились два небольших озерца, образованных, скорее всего, от старого русла реки. Пойменная территория местами заболочена.

В северо-западной части Татарской Айши размещено старинное кладбище, выделяющееся на панорамном силуэте селения в виде рощи, заросшей высокими деревьями. Оно является, по существу, опознавательным знаком местонахождения деревни с расстояния, когда застройка скрывается из виду в низине. Кладбище представляет собой огороженную территорию размером 100×150 м, вход расположен с южной стороны. В юго-западном углу, недалеко от входа, находится хозяйственная постройка для ритуальных принадлежностей.

Татарская Айша в настоящее время представляет собой типичную татарскую деревню в долине р. Казанки. Она находится в ведении Иске-Казанского Совета местного самоуправления и, как одно из древних татарских селений, включена в охранную зону ИКГМЗ Министерства культуры РТ [Бурханов: 2014. С. 84–88].

**Музей в Камаево.** Впервые годы после официального открытия музея-заповедника основным препятствием для интенсификации охраны и пропаганды памятников историко-культурного наследия в условиях ИКГМЗ являлось отсутствие специального здания музея, в котором обеспечивалось бы экспонирование и хранение археологических и этнографических находок, проведение лекций и иных мероприятий, научная обработка имеющихся коллекций и т. п. Деревянное одноэтажное здание бывшей Камаевской школы, где временно, с 1992 г. по начало 2000-х гг., размещалась дирекция и музейные фонды, не отвечало современным требованиям музейного дела.

Начатое в 1993 г. строительство музейного здания было заморожено из-за финансовых и организационных проблем. И только через 10 лет деятельности заповедника было открыто кирпичное 2-х этажное (с подвалом) здание, правда, оно было спроектировано не совсем удачно и не вполне подходит для музейного комплекса. Несмотря на это, стараниями руководства Министерства культуры РТ и коллектива ИКГМЗ музей-заповедник постепенно превратился в работающее в полную силу учреждение культуры. Наряду с внутренним оформлением здания и музейных экспозиций, стало возможным благоустройство окружающей

территории, где появилась построенное в 2010 г. при помощи спонсоров («Таттелеком») деревянная крепость.

Проблемой также является отсутствие в штате ИКГМЗ высокопрофессиональных специалистов, имеющих соответствующее историческое и музееведческое образование. Однако, она была частично решена в связи с переподготовкой некоторых сотрудников путем прохождения курсов повышения квалификации в Москве и Казани.

Основная часть музейной коллекции, состоящей из археологических и этнографических экспонатов, была собрана и сформирована в 1980-е годы группой ученых ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР и местных краеведов под руководством доктора исторических наук Р. Г. Фахрутдинова. В частности, значительная часть археологической коллекции была составлена из материалов, полученных в результате раскопок в 1940–1950-е, 1970–1980-е и 1995–1998 гг. экспедициями под руководством Н. Ф. Калинина, Р. Г. Фахрутдинова и А. А. Бурханова. Этнографические экспонаты в основном были собраны в 1986–1990-е годы по инициативе учителя-краеведа из Чепчуговской средней школы Р. М. Хазиева.

В 1994–1995 гг. в целях научной атрибутации и музейного учета была проведена полная паспортизация всех археологических и этнографических экспонатов из экспозиций и фондов ИКГМЗ (А. А. Бурханов и М. К. Завьялова).

Самостоятельные поездки сотрудников ИКГМЗ по населенным пунктам Высокогорского и Арского районов и их участие в составе комплексной историко-этнографической экспедиции ГОМ РТ (М. К. Завьялова)* в Атнинском районе в 1995 г. позволили пополнить фонды музея. В результате археологических работ Заказанской историко-археологической экспедиции (А. А. Бурханов) в 1995–1998 гг. музейные коллекции пополнились новыми уникальными находками из Урматского поселения и Камаевского I и II городищ. Пополнение Фондов музея ИКГМЗ продолжается до сих пор благодаря поддержки местных жителей районов Заказанья.

Музейная коллекция ИКГМЗ на сегодня насчитывает приблизительно 4000 археологических и этнографических экспонатов, что и позволяет представить ее в отдельных тематических экспозиционных помещениях музейного здания.

Необходимо вернуть национально-региональный компонент, малокомплектные школы, татарский язык в централизованные школы, куда вход ему закрыли. И не допустить изгнания татарского языка путем голосования родителей. Родители большинством голосов не имеют права отменить права других родителей, т. е. Конституцию РФ, конституционные гарантии страны. Русский язык обеспечивает взаимопонимание, вза-

имодействие, но он не может быть гарантом единства – он не объединил даже русскоязычных красных и белых, Пугачева и помещиков, царей. Были едины, как братья, наши отцы и деды разных национальностей в героической борьбе против фашистов, не все даже хорошо зная русский язык. И, наверняка, знают и любят русский язык те десятки, сотни тысяч, которые покидают современную Россию... Написал также о том, что совершенно неправильно утверждение О. Артеменко о том, что нерусские языки, кроме иностранного, не влияют на экономику. «Нам песня строить и жить помогает». С песней и в бой идут и на труд. Во время страды на полях всегда выступали артисты. На фронте перед бойцами выступали артисты, в том числе и татарские. А без языка не сочинишь песню…

### *Обеспечить ускоренное научно-техническое развитие страны*

В своем письме руководству страны я написал, что считаю нужным пересмотреть школьную программу и требования ЕГЭ по русскому языку для того, чтобы из-за их трудностей не допустить непринятие в институты талантливых, способных к физико-математическим предметам, школьников. И что в школах главное внимание надо уделять естественно-научным предметам. Страна наверняка нуждается в первую очередь не в филологах, специалистах по русскому языку. Проблем с русским языком нет – почти все предметы изучаются на русском языке, а это более 30 часов, поэтому все школьники будут хорошо знать русский язык в достаточный им для работы в любой отрасли.

### *Основы православной культуры*

Когда началась активная работа по внедрению в школы предмета религиозного характера (с текстами даже молитв) «Основы православной культуры» (на базе учебников О. Харитоновой и А. Бородиной), активисты *«Туган тел»* направляли руководству страны и Минобрнауки письма протеста. Мы писали, что это – нарушение Конституции страны. Писали, что дети должны получать строго научные знания о религии, чтобы их когда-нибудь не смогли обмануть такие мошенники как Грабовой, заявляющий, что он воскрешает мертвых, как это делали Христос и его ученики и что он сам Христос. В детских душах школьников не должно сложиться убеждения о правомочности принципов «Цель оправдывает средства» и «революционная целесообразность» как может быть после рассказов на уроках ОПК о Всемирном потопе: «Человеческий род испортился и развратился, достойных людей становилось все меньше. Бог решил оставить в живых только праведного Ноя и его семью». «После

потопа число людей снова стало увеличиваться и среди них опять появились нечестивцы. И пролил господь на Содом и Гоморру дождем серу и огонь, от Господа с неба, и ниспроверг города сии, и всю окрестность свою, и всех жителей городов сих, и произрастания Земли» (Ангелы нашли благочестивыми только семью Лота и вывели их заранее из города). (ОПК А. Бородина, сс. 81 и 85). Как же так – всех жителей, виновных и невиновных и невинных детей наказали, как справится с этим вопросом подросток?

Писали мы, что в школьных учебниках и так много материалов о православии, в том числе, христианских заповедей, и надо лишь дополнить учебники материалами об истории и культуре, о нравственных основах других коренных народов.

***Русский язык и родной татарский – у нас два крыла***

Русскому ребенку дано великое счастье обязательного изучения родного языка. Это хорошо. Необязательность изучения родных нерусских языков – это самый «демократический» способ уничтожения нерусских языков. Мы предлагали ввести обязательность изучения родных языков в местах компактного проживания людей одной национальности и создать для этого все возможности. Наши письма о недопустимости ликвидации национально-регионального компонента, малокомплектных школ и недопустимости ликвидации уроков по родным нерусским языкам при переводе детей в централизованные школ, об опасности перевозки детей на дальние расстояния подписывали руководители чувашской, мордовской и башкирской организаций, а протестные в связи с ликвидацией малокомплектных школ, руководитель и русской организации. Нет школы – нет села и поля зарастают бурьяном. Село – творец истинно народных песен, мелодий, традиций.

Самым крупным достижением *«Туган тел»* является создание муниципальной общеобразовательной школы *«Яктылык»* с углубленным изучением татарского языка и литературы. Это результат конструктивного взаимодействия татарской общественности с органами власти. Ремонт разрушающегося здания детсада под школу и строительство пристроя к зданию школы – также большое организационное достижение *«Туган тел»*. В самом начале нашей деятельности к нам пришла директор вечерней школы рабочей молодежи Харида Габтулзяновна Дашкина и рассказала о своей идее открытия татарской школы. Началась многолетняя совместная работа: обращения в органы власти и образования, хождение активистов по квартирам татарских семей и приглашение в татарскую школу, агитация на праздниках и через татарскую газету, через татарские

радиопередачи «Илкәем-Иделкәем» и затем «Ак бәхет» на «РАДИО-7». Прошли через этапы: воскресная школа – дневное отделение вечерней школы – отдельная школа.

На праздниках *«Нәүрүз»* и *«Сабантуй»*, в своих выступлениях со сцены, я, как руководитель *«Туган тел»*, говорил, адресуя слова руководству области и города, о необходимости татарской школы. Включение в бюджеты области и города Самары финансовых средств для ремонта и строительства – это большая заслуга руководителей *«Туган тел»* Бульхина Анвара Кашафовича и Мухаметшина Вазыйха Гатовича. Вазыйх Гатович, я и Шамиль Багаутдинов решили, что в проекте пристроя мала вместимость школы, и Мухаметшину удалось изменить уже утвержденный проект с 280 учеников на 450 и, соответственно, с 2-х этажного на 3-х этажный пристрой.

В успешной и качественной организации работ по ремонту и строительству проявились талант и упорство Вазыйха Гатовича. Он и свои средства вкладывал, тратил свое время. В течении более 3-х лет, почти каждую неделю, на оперативных совещаниях под его руководством мы решали текущие вопросы. Счастливые улыбки школьников *«Яктылык»* – всем нам награда.

В 2013 г. школа *«Яктылык»* вошла в список 100 лучших школ России. Замечательные детские коллективы школы выступают на всех наших праздниках. Татарская общественность говорит о необходимости в Самаре второй такой же школы и расширении *«Яктылык»*. Может появится и еще такая же активистка, как Харида Габтулзяновна и тогда проблема, наверное, будет решена. Но нужна постоянная упорная работа руководителей татарских организаций по данному вопросу.

### *Таң йолдызлары – Утренняя звезда*

*«Таң йолдызлары»* – прекрасный детский коллектив под руководством Халиды Валеевой во Дворце пионеров. Он начал работать еще в советское время (мы тогда с Рашидом Абдуловым сумели договориться в управлении образования или культуры о выделении ставки руководителя) и приобщил многих татарских детей к татарскому песенно-хореографическому искусству (пока Халида не ушла в декретный отпуск).

### *Радио-7. Татарские передачи «Ак бәхет»*

Замечательные, радостные 10 лет в жизни народов Самарской области связаны с радиопередачами на 11 языках на «РАДИО-7» (в основе этого радио – использование уже не нужного глушителя западных передач), этим люди обязаны Николаю Бакумову, Амине Шамсутдиновой и Шамилю Багаутдинову. Шамиль (он был его директором) и его дочь Наиля

организовывали замечательные передачи и вели на этом радио татарские передачи на *«Ак бәхет»*. Очень жаль, что власти не оценили большую роль этого радио в сохранении национальных культур и патриотическом воспитании молодых поколений и прекратили бюджетное финансирование очень нужного народу радио. По инициативе Наили при областном радио велись татарские передачи «Илкәем-Иделкәем», вела их Наиля. По ее инициативе и при помощи И.Г.Шакурова был создан Сайт «Самарские татары», он финансируется ее мужем. Советские и индийские фильмы на татарском языке шли в кинотеатре Шипка. Еще некоторые детали нашей деятельности: в кинотеатрах «Шипка» и Дворца Культуры завода «Прогресс» мы показали несколько дублированных на татарский язык индийских и советских фильмов. Перед фильмом выступали наши певцы и гармонисты. Фильмы я привозил на время в рюкзаке из Казани. Тяжелые металлические коробки резали мне поясницу. Также и с помощью дачных тележек привозил в качестве призов книги из Казани (Ш.С.Багаутдинов также этим занимался). Два фильма я привозил и в родные Камышлы. Сейчас книги из Казани привозят на своих машинах наши руководители и активисты. И все татары благодарны Татарстану за ТНВ.

***Участие молодежи. Делегаты съездов ВКТ. Активисты. спонсоры***

Молодежь активно участвовала в проводимых мероприятиях, на праздниках, в субботниках при строительстве Соборной мечети, при очистке кладбищ, при поездках в Булгары, в молодежные лагеря Татарстана.

Наши активисты и руководители татарских общественных объединений города и области избирались делегатами Всемирного конгресса татар, съездов Федеральной национально-культурной автономии татар и Форумов татарской молодежи.

Активисты «Туган тел» работают, как сказано выше, на общественных началах, отрывая свое драгоценное время и свои силы от своих важных семейных и личных дел, спонсоры вкладывают свои немалые деньги ради народа. Вкладывали большие средства руководители «Туган тел» и других общественных объединений: В.Г.Мухаметшин, А.К.Бульхин, И.Г.Шакуров, Г.И.Горланов, М.М.Халиуллов, Р.Т.Хузин, Ф.Б.Канюкаев, Д.А.Валиуллин, Г.М.Батыршин, Р.М.Латыпов и многие предприниматели. В своей родной деревне проводит «Сабантуи» Х.Х.Бикташев. В разные годы руководителями «Туган тел» (с 1989г. по 1997г. председателями Совета, а с 1997г. в соответствии с новым Уставом – президентом и с ним вместе на пару – директором) избирались Р.Абдулов, А.Надиров,

В. Мухаметшин, А. Бульхин, Ш. Багаутдинов, И. Колючев, Ф. Канюкаев, Ф. Махмутов, И. Шакуров, Д. Сайфиев.

И. Г. Шакуров с 2012 г. возглавляет «Туган тел». При нем значительно расширилось поле деятельности организации. Участие в организации и проведении в Самаре большого фольклорного праздника «Түгәрәк уен», областных сельских «Сабантуев»и 1-го и в 2019 г. 2-го на самарской земле Федерального сельского сабантуя, организация юбилея журнала «Чаян», проведение конкурсов и олимпиад по татарскому языку, конкурсов чтецов стихов, конкурсов песен-караоке, конкурсов «Татар Кызы», организация 80-летия-юбилея Гакиля Сагирова, создание журнала «Самарские татары» (редактор Данияр Сайфиев), информационного медиа-портала «Самарские татарские новости» (редактор Римма Нуретдинова), именные стипендии имении Алии Алеветдиновны (матери Ильяса Гумеровича) лучшим учащимся школы «Яктылык», участие в издание книг, в организации поездок школьников в исторические места, татарский календарь и т.д. – во все эти мероприятия он вкладывает свою душу, а также большие деньги, свои и своих родственников, единомышленников – не один миллион.

***Разные, но не чужие – областная программа помощи НКО***

Финансовую помощь оказывают также администрации области и города. Помощь области в проведении праздников началась в 1993 г. после моего и руководителя чувашской организации Валентина Калмыкова выступлений на конференции по вопросам национальной политики с участием руководителей субъектов Приволжского региона. Этой поддержки администрации недостаточно для проведения национальных праздников, мероприятий, поэтому основную долю расходов покрывают спонсоры. При проведении первых Сабантуев и почти всех Наврузов часть расходов покрывали взносы участников (для входа мы продавали недорогие билеты). В последние годы татарские организации участвуют с другими тюркскими организациями в совместном Наврузе, организуемом Домом Дружбы народов. Считаю необходимым возвращение и нашего Навруза, как очень эффективного для приобщения подрастающего поколения к родному языку и культуре, к спорту, для общения и знакомства молодежи друг с другом. Основным в программе Навруза предлагаю конкурсы – Татар кызы, Татар егете и на лучшего исполнителя татарской пляски, а может быть и несложные спортивные и акробатические номера, юмор. Продажа небольших по стоимости билетов помогла бы решать финансовые проблемы. Не смогут же все расходы взять на себя спонсоры. Только все вместе сможем сохранить самих себя, нашу идентичность.

«Туган тел» всегда был хорошим примером для других НКО и активно участвовал в строительстве новейшего гражданского общества.

Защищать Татарстан, не допустить ликвидации республик, прививать молодым поколениям любовь к нашим песням и языку – вот сложные задачи, стоящие перед нами. Все начинается с колыбельной песни на родном языке. Надо всем прийти в татарские общественные организации, не стоять в стороне. Только при активном участии, стараниях каждого удастся сохранить наш народ.

## ШКОЛА «ЯКТЫЛЫК» ГОРОДСКОГО ОКРУГА САМАРА

***Р. Р. Газизов***

Первого сентября 1997 г. в городе Самаре была торжественно открыта школа «Яктылык» с углубленным изучением татарского языка и культуры. Этого дня ждали многие, ведь в городе проживают до 50 тысяч татар. Желание знать свой язык, историю, культуру у татарского народа было всегда, но не всегда это можно было осуществить живя вдали от исторической Родины. Это стало возможным после принятия в 1991 г. закона «О языках народов РСФСР».

1 сентября 1997 г. первая в городе школа с углубленным изучением татарского языка и культуры распахнула свои двери желающим обучаться на родном языке. Но путь к этому дню был не прост. Вначале был создан татарский культурный центр «Туган тел», затем – воскресная школа. По инициативе Хариды Габтулзяновны Дашкиной (тогда директора ВСШ № 12) на базе вечерней школы № 12 вначале была открыта татарская воскресная школа, а в 1994–1995 учебном году было получено разрешение городского отдела народного образования на открытие при ней уже дневного отделения с изучением татарского языка в 7–11 классах. С каждым годом число учащихся увеличивалось. Конечно, в первые годы родители с опаской отдавали в необычную школу своих детей, так как психологически не были к этому готовы. Боялись, что уровень знаний в школе будет низок, а учащиеся после её окончания не смогут поступить в вузы. Пришлось много работать с татарским населением: беседовать, вести пропаганду через местную прессу, радио, на национальных праздниках. Постепенно желающих обучиться становилось всё больше и больше, и назрела необходимость открытия татарской школы.

В течение 8-ми лет велись письменные и устные переговоры с органами управления образованием об её открытии. И 29 апреля 1997 г. Главой города Самары была подписана Постановление № 611 «Об открытии муниципального образовательного учреждения школы «Яктылык» с углубленным изучением татарского языка и литературы в здании бывшего детского сада. В короткие сроки была проведена реконструкция детского сада. Спешно проводились ремонтные работы, комплектовались классы, оснащались мебелью, оборудованием, учебниками. Необходимо было найти в достаточном количестве учебники по татарскому языку для всех классов. Проблем было много, главное – не хватало специалистов. Нужны были не просто учителя-предметники, а специалисты со знанием род-

ного языка, любящие свой язык и преданные своему народу. Педагогу с большой буквы, Дашкиной Хариде Габтулзяновне, удалось найти таких людей.

178 детей татарской национальности первого сентября 1997 г. сели за парты. Были скомплектованы все классы с 1-го по 11-й. В школе ещё пахло свежей краской, но занятия начались своевременно.




Всё начинается со школы, а школа с учителя. Л. Н. Толстой говорил, что хорошему учителю достаточно иметь только два качества – большие знания и большое сердце. В современном мире, конечно, нужно иметь ещё многое другое, но прочные знания и любящее детей сердце обязательны. Именно такие педагоги трудятся в школе «Яктылык». Школа «Яктылык» – это прежде всего люди, которые стояли у истоков её возникновения. Это люди, которые 1 сентября 1997 г. встретили первых учеников новой школы «Яктылык». Большинство из них работают и сегодня в своей, ставшей родной, школе.

Без их знаний и таланта, упорства и трудолюбия не было бы ничего: ни успехов будущих выпускников, ни добрых традиций, ни замечательных побед – учебных, спортивных, творческих, – ни тех дорогих воспоминаний, которые каждый хранит в своём сердце.

А у школы много добрых традиций и дорогих воспоминаний. Академик Д. И. Лихачёв писал: «Человек должен жить в сфере добра. Эта сфера добра в значительной степени создаётся им самим. Она создаётся

из его добрых дел, добрых чувств, добрых воздействий на окружающую среду, памяти на добро. Добро неотделимо от нравственности, а нравственность от милосердия». Педагоги школы не только дают ученикам знания, но и стараются привить им общечеловеческие жизненные принципы гуманности, доброты, понимания и уважения к другим людям. Начиная с 2004 г. ежегодно в школе проводится благотворительная акция «Тепло сердец». Учащиеся школы заранее готовят поделки, устраивают выставки-продажи, а вырученные средства направляют нуждающимся. В разное время посильная помощь оказывалась дому ребёнка «Малютка», малообеспеченным семьям, детям-инвалидам, детям, оказавшимся в трудной жизненной ситуации, Детскому дому № 1 для сирот и детей, оставшихся без попечения родителей.

Очень важно сохранить в памяти детей то, что ещё могут рассказать им участники Великой Отечественной войны и труженики тыла. С первых дней работы школы встречи с ветеранами стали доброй традицией. Ежегодно в канун Дня Победы собираются в школе деды и прадеды учащихся школы, члены Совета ветеранов при Самарской соборной мечети.

Основная цель этих встреч – воспитание уважительного отношения школьников к подвигу фронтового поколения, воспитание гражданского самосознания, патриотизма. Ко встрече с ветеранами ребята готовят праздничный концерт. Они вместе с ветеранами исполняют песни военных лет, читают стихи и обязательно показывают задорные национальные танцы, которые никого не могут оставить равнодушными. Задолго до праздников ребята начинают готовить красивые поделки для гостей, которые вручаются в торжественной обстановке.

Восточная мудрость гласит: «Кто не знает историю прошлого, тот не поймёт сегодняшнего и не будет иметь представления о будущем». Приобщение к истории начинается со школьной скамьи. Поэтому, в самарской школе «Яктылык» с татарским культурно-национальным компонентом большое внимание уделяется изучению этнографии татарского народа, его культуры. В начале апреля 2013 г. в школе заработал этнографический музей «Мирас», воспитывающий у ребят чувство гордости за свой народ. Материал для музея собирали все вместе: педагоги, родители, учащиеся. Школьники и педагоги несколько лет подряд выезжали в этнографические экспедиции в сёла Самарской губернии и собрали неплохой краеведческий материал, оформили помещение музея, а сейчас там сами проводят экскурсии. В музее представлены такие экспозиции, как вид татарского дома, домашняя утварь, национальная вышивка, одежда, обувь и т. д.

С первых дней в школе работают профессиональные хореографы, музыкальные руководители, которые прививают детям любовь к родной песне, народным танцам, татарской культуре. Нужно сказать, что наши ребята достигли высоких результатов, без выступления коллективов школьной самодеятельности не обходится ни одно значимое мероприятие в городе. Танцевальный ансамбль «Кояшкай» – победитель Всероссийского конкурса «Орлята России», который проводился в г. Туапсе. Театр танца «Йолдыз» – обладатель Гран-при Ш Международного фестиваля музыки, искусства и фольклора «Белосток-2010» (Польша). В фестивале тогда участвовали 30 коллективов из Польши, Турции, Индии, Греции, Непала, Боснии и Герцеговины, Белоруссии, Литвы, Хорватии, Украины и России, но нашим ребятам удалось одержать победу в очень не простом конкурсе.

С марта 2010 г. ежегодно коллективы художественной самодеятельности школы дают благотворительный концерт во Дворце культуры имени Литвинова. Эти концерты проходят на высоком профессиональном уровне, при полном зале. Зрители подолгу не отпускают артистов со сцены.

Здоровье – основополагающая составляющая всей жизни и деятельности человека. Имея с рождения крепкий организм, совершенствуя свой физический, творческий потенциал, можно добиться больших успехов. Современный человек не может считаться культурным без овладения основами физической культуры, так как она является неотъемлемой частью общей культуры. Физическая культура и спорт была и остаётся одним из главных направлений оздоровительной работы в школе «Яктылык». Для занятий спортом в школе «Яктылык» имеются все условия. Большой современный спортивный зал, малый спортивный зал для занятий борьбой, оборудованное футбольное поле с искусственным покрытием. На встречу с ребятами приходят именитые гости, известнные мастера спорта, которые дают ребятам мастер-классы и с удовольствием играют с ними. Секция национальной борьбы «Көрәш» работает в школе с осени 2009 г. Здесь ребята параллельно постигают мастерство в олимпийском виде спорта – греко-римской борьбе. На тренировки к Руслану Наилевичу Юсупову с удовольствием ходят ребята разного возраста. Весной 2014 г. воспитанники Р. Н. Юсупова приняли участие в Первенстве страны по греко-римской борьбе, один из учащихся – Камиль Ахметвалиев, выиграл первенство страны, а другой – Абдекерим Шералиев, стал бронзовым призёром. В школе «Яктылык» с 2010 г. ежегодно проводятся областные турниры по национальной борьбе с участием спортсменов из Камышлинского и Похвистневского районов, Сызрани, Новокуйбышевска, Тольятти, Димитровграда и Республики Татарстан. Несмотря на се-

рьёзную конкуренцию, ученики школы «Яктылык» всегда оказываются среди победителей и призёров этих соревнований.

Добиваться достойных результатов и в учёбе, и в спорте, и в творчестве было бы невозможно без понимания всестороннего участия родителей. «Педагоги, ученики и их родители должны быть единым целым в учебно-воспитательном процессе», – считает директор школы Р. Р. Газизов. Действительно, родители школы принимают самое активное участие в решении важнейших задач школы, активно участвуют на Днях здоровья, субботниках, которые проводятся весной и осенью не только во дворе школы, но и в соседнем дворе. Завершаются эти мероприятия как правило горячим чаем и пловом.

С большим интересом и желанием родители ездят с учениками на экскурсии и выездные уроки истории в с. Ширяево. Отрадно отметить, что ряд родителей в своё время окончили школу «Яктылык».

Идёт время, меняется педагогический коллектив школы, вот уже выпускники вернулись в школу учителями, но главные ценности остаются непреложными: доброта, внимательное отношение к детям, огромная любовь к своему предмету и умение передавать знание ученикам. Педагогический коллектив школы «Яктылык» – это коллектив единомышленников, в котором гармонично сочетаются опыт ветеранов и творческий поиск молодых.

На сегодняшний день в школе состоялись более 20 выпусков. Каждый выпуск памятен по-своему. Провожая своих выросших ребят, каждый раз думаешь: «Какой был замечательный класс, как жалко, что они уходят, наверное, уже никогда не будет таких талантливых детей». Но, наступает новый учебный год, и на смену приходят другие, не менее талантливые, не менее способные ученики.

Сегодня «Яктылык» – одна из лучших школ городского округа Самара, лауреат в номинации «Школа активного гражданина», одна из «100 лучших школ России», а директор школы Р. Р. Газизов, отмечен Почётным знаком «Директор года».

Вот такая дорога длиною в 20 с лишним лет у школы.

# ПУГАЧЁВ ЯВЫ КАҺАРМАНЫ

***Э. М. Сибгатова***

***Аннотация:*** *Статья посвящена теме Пугачёвского восстания, конкретнее– организаторскому и полководческому таланту героической личности одного из его руководителей – Абзалиля Сулейманова. Назначенный старшиной Терсинской волости (ныне Агрызский район Республики Татарстан) по указу Е. И. Пугачёва, он сплотил отряд из 500 крестьян и контролировал всю территорию от города Сарапула (р. Кама) до р. Вятки. Кроме того, обнаруженные нами новые документальные факты дают возможность восстановить его родословную и отследить судьбу родных, детей в пределах от XVII до начала XIX вв.*

***Ключевые слова:*** *Сулейманов Абзялил, крепостной крестьянин, Терсинские восстания, Пугачёвское восстание, талантливый полководец, Тевкелев Кутлумухаммад Мемешевич (по крещению Алексей Иванович) (1674–1766), представители рода, генеалогия, соратники.*

*Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,*
*Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары...*

*Г. Тукай «Татар яшьләре»*

1773–1775-нче елларда Емельян Пугачёв җитәкчелегендәге халык күтәрелеше Россиядә иң зурларның берсе булган. Россия тарихына кереп калган бу вакыйгалар тарихчыларны, язучыларны, кино куючыларны әле дә дулкынландыра. Пугачёв явында катнашкан татарларны тарихчылар Газиз Гобәйдуллин һәм Сәлам Алишев өйрәнделәр, Вахит Имамовның тарихи әсәрләре басылды. Шулар арасында Әгерҗе якларында туыпүскән тарихчы-галим Раиф Мәрдәновның язмалары безнең өчен бигрәк тә кыйммәтле. Энциклопедиягә тиң хезмәт, туган авылына багышланган «Тарихта тибрәлгән Тәбәрле» китабында якташыбыз төбәгебездә булган Пугачёв восстаниесе вакыйгаларын архив материаллары буенча җентекләп өйрәнгән һәм көне-сәгате белән торгызган.

Безнең якларны айкап узган бу восстание турында үзем дә туган авылым Биектауга кагылышлы архив документлары белән танышканда моңарчы бер кая дә очрамаган тарихи фактлар таптым. Восстание җитәкчесе Габделҗәлил (мулла кушкан исеме шулай булса да, халык телендә гадиләштереп Әбҗәлил рәвешендә йөртелгән) Ә. Сөләйманов гаиләсе илле елдан артык (1745–1795-нче елларда) безнең авылда яшәгән икән,

ләбаса! 2002-нче елда нәшер ителгән «Татар энциклопедия сүзлеге»нә (547 б.) күз салсак: «Сөләйманов Әбҗәлил (Гаделҗәлил) (?–1774), 1773–75-нче еллардагы крәстияннәр кузгалышында катнашучы. Фетнәчеләргә 1773-нче елның декабрендә килеп кушыла. Е. И. Пугачёв фәрманы белән Тирсә волосте старшинасы итеп билгеләнә. Полк туплап, Әгерҗе-Тирсә төбәгендә хәрәкәт итә, сугышта җиңелеп, әсир төшә. Июнь башларында Тирсә авылында җәзага тартыла», – дип укыйбыз.

Чыннан да, крепостной крестьян Ә.Сөләйманов оста оештыручы, җитәкче, кыю гаскәр башлыгы булган. Әбҗәлил 500 артык кешелек отряд туплауга ирешә. Чынлыкта аның тырышлыгы белән хәзерге Удмуртия һәм Киров өлкәсе территорияләрендәге шактый удмурт, рус, татар һәм чирмеш авылларында патша хөкүмәтенең власте бетерелгән халәт сакланган. Дәүләт салымнары түләнмәгән, рекрут бирмәгәннәр, Пугачёвның төп армиясенә атлар, азык-төлек һәм бүтән кирәк-ярак җибәрү оештырылган. Чын-чынлап азатлык утравы булган бу! Тирсә авылы баш күтәрүчеләрнең штабы һәм хөкем урынына әверелгән. Кайда кем урлаша, кемне кем рәнҗетә – һәммәсе тикшерелә һәм гаепле җәзага тарттырыла. Г. Сөләйманов ерактагы авылларда казаклар җыеп йөргән арада безнең як халкы восстание рухын сүрелдермәгән. Вәкилләр бөтен авылларда йөреп, коралы төркемнәр оештырырга өндәп һәм ризалатып, җитәкче-старшиналар билгеләп, һәрвакыт походка әзер булып торганнар. 1744-нче елның апрелендә баш күтәрүчеләрнең төп оясын туздыру өчен Тирсәгә Казаннан майор Отто Дуве командалыгындагы гаскәр җибәрелә. Сөләймановның күбесе ук-җәя, сөңге, сәнәк, чалгы һәм күсәкләр белән генә коралланган һәм сугышырга өйрәтелмәгән тәҗрибәсез ир-егетләре, никадәр гайрәтле булсалар да, Европаның иң алдынгы армияләреннән берсе тарафыннан тар-мар ителүләре гаҗәп түгел. Әбҗәлил үзе кечкенә отряд белән Иж елгасының аръягындагы урманга кереп кача. Ләкин үз башларын саклап калырга ашыккан татар хыянәтчеләре аны дошманнар кулына тапшыралар. Кыйнап сорау алулар үткәрелгәч, Яшерен комиссиянең 26-нчы май карары буенча Казаннан килгән җәза отряды (башлыгы майор Скрипицын) тарафыннан Сөләйманов Тирсәдә асып үтерелә. Шунсы үкенечле, ун көннән соң Пугачёв үзе Әбҗәлил өчен үч ала, гаскәре белән Тирсәгә килеп җитә һәм Скрипицынны дарга астырып үтерә.

Инде хәзер Әбҗәлилнең чыннан да Биектау авылы крепостной крестьяны булганлыгын дәлилләүче документларны барлыйбыз. Биектау, алпавыт Тәфкилевның төп утары Тирсә авылыннан, 6 чакрым төньякта урнашкан татар авылы. XVII–XIX гасырларда авыл ике исемле булып йөртелә: Ишкәшүр-Юр һәм Биектау. Беренче исеме елга исеменә бәйле. Авыл кешеләренең күпчелеге крепостной крестьяннар. Әбҗәлил Сөләй-

мановның Биектау авылында яшәгәнлеге турындагы беренче мәгълүмат 1745-нче елга кагыла. 1745-нче елгы «Книга переписная... «Зюрейской дороги Казанского уезда брегадира Алексея Тефкелева деревне Юре по речке Ушкошер крестьянья татара», документының «Переведённые» дигән өлешендә: «...Возвращённые из бегов, написанной в прежнюю перепись в Казанском уезде Арской дороги в деревне Казыльяре: Сулейман Дюсеев (64 года). У него дети после переписи рождённые: Абдюка (27 лет), Абдулкарим (21 год), Абдулзялиль (18 лет). У Абдюкая дети: Ярмухамметь (4 года), Абдулрахим (полугоду)». [РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Ед. хр. 1141. Л. 458 об-460 об.]. Димәк, XVII гасырда Әбҗәлил нәселе вәкилләре бабасы Дүсәй (Дусмөхәммәт) һәм 1681 елда туган әтисе Сөләйман булганнар.

Сөләймановлар крепостнойлыктан котыласы килеп, Тирсә морзаларына каршы беренче баш күтәрүдә (1742–44-нче еллар) катнашып качып китеп аларны безнең авылга мәҗбүриләп кайтарганнар булса кирәк Бу турыда да «Татар энциклопедия сүзлеге» ндә «Тирсә крестьяннары кузгалышлары» (574 б.) дип кертелгән мәгълүмат бар: «Казан губернасы Тирсә волосте крәстияннәренең крепостной тәртипләргә каршы баш күтәрүләре. 1нче кузгалыш 1742–44-нче елларда була. Сәбәбе: элекке дәүләт крестьяннәрен алпавыт Котлыгъмөхәммәд Тәфкилевкә крепостнойлыкка бирү. Кузгалышта Чишмә, Нажар, Тирсә, Балтач, Мордвинкино авыллары халкы катнаша. Башлап йөрүчеләре – бертуганнар К., М. һәм И. Заһитовлар, И. Каметов, А. Арсланов, Б. Рахманкулов һ. б. Фетнә гаскәр көче белән бастырыла; 2нче кузгалыш 1764–67-нче елларда була. Крепостнойлыктан азат итү фәрманы чыккан икән, дигән хәбәр таралудан башлана. Тирсә волостеның күпчелек авыллары хәрәкәткә кушыла. Җитәкчеләре – М. Минкин, К. Кадермәтев, Т. Кривов, Я. Ермаков, Г. Әмирев, Г. Минкин, И. Исениев һ. б. 1767-нче елда волостька секунд-майор Г. Широков җитәкчелегендә бер батальон солдат җибәрелә һәм фетнә хәрби көч кулланып бастырыла. Җитәкчеләре җәзага тартыла».

Гомүмән, Тирсә авылы Россия күләмендә йогынтылы кешеләрнең (мәсәлән, алпавыт Котлыгмөхәммәт Тәфкилев патша Пётр I якын фикердәше) төп утары буларак билгеле. Крепостнойлык татарларда бик сирәк очрый. Ә нәкъ Тирсә тирәсендәге җиде авыл крестьяннары (Тирсә, Тоба, Нажар, Чишмә, Мордывый, Биектау һәм Балтач) XVI гасырда башта морза Багыш Яушев аннан Тәфкилевларның крепостнойлары булганнар. Алпавытлар рус хөкүмәтенең ышанычлы затлары булганга, төрле башбаштаклыкларны аз кылмаганнар. Крепостной крестьяннарны атнаның 5–6 көнен алпавытка эшләтеп, туктаусыз салымнар түләтеп, рекрутка алып, авылдан авылга күчереп, һәм башка бик-бик күп төрле

җәзалар биреп бимазалаганнар. Өйләнү, кияүгә чыгу да алпавыт рөхсәте белән генә башкарылган. Гасырлар буе дәвам иткән мондый киеренкелек халыкны чыгырдан чыгарган. Шуңа күрә, баш күтәрүләр, низаглар, ыгы-зыгылар безнең төбәктә еш булып торган.

1745-нче елгы документта Әбҗәлил 18 яшьлек егет. Димәк, аның туган елы – 1727. Бу да бик кирәкле факт, чөнки «Татар энциклопедия сүзлеге» ндә аның туган елы билгеләнмәгән. Биектау авылы тарихына кагылышлы 1769-нчы елгы архив документында. «Секунд-майора Осипа Тевкелева в деревне Биктове по речке Ушкашур» крепостной крестьяннар исемлегендә [РГАДА. Ф. 1306. Оп. 2. Ед. хр. 1701. Л. 130–134] Әбҗәлил Сөләйманов һәм ике абыйсы Габдекәй, Габделкәрим хуҗалыклары теркәлгән. Әбҗәлил Сөләймановка 43 яшь. Ул ике хатынлы. Беренчесе – Зөләйха Юлдашева Чишмә авылыннан крепостной крестьян кызы, 37 яшьлек. Икенчесе – Фатыйма Сәфәрова Тирсә авылыннан крепостной крестьян кызы, 32 яшьлек. Аларның дүрт уллары –Габдерәшит, Габдрафыйк, Ибраһим, Габделхалик, ике кызлары – Йөземҗамал, Мөхәллимә үсеп киләләр. Күргәнебезчә, «крепостной» дигәч тә әле ул «хәерче» дигән сүз түгел. Тормыш-көнкүреше нык. Ә нинди сәбәпләр аркасында нибары 4 елдан соң Әбҗәлил Сөләйманов Пугачёв восстаниесенә кушылырга дигән карар кыла?! Җавабы күз алдында. Ике күченү – бер пожарга тиң, ди халык. Тәфкилевның крестьяннарны кол итеп, үз биләмәләрендә авылдан-авылга күчереп йөртүләре сәбәп түгелме? Моннан тыш, Әбҗәлилне бу адымга көннән-көн көчәя барган милли изү, дини хөрлек һәм үз ил-җирләреңә хуҗа булу теләге көннән-көн уйландыра, ныгый бара, ахрысы.

Казан архивыннан алынган «1795-го году июня... дня Вятского наместничества Елабужской округи вотчины госпожи вдовы секунд-майорши Дарьи Алексеевны Тевкелевой Терсинкой волости деревни Юр по речке Ушкашур крепостные её крестьяня...» ревизская сказка документын барлыйбыз [НА РТ. Ф. 3. Оп. 2. Ед. хр. 442. Л. 160–174]. Батыр, тырыш нәселнең тамырын чабасы балталар инде кайралган булган икән шул. Исемлекне барлаганда җәзаланган ир-атлар, җафаланган тол хатыннар, ятим балалар язмышлары күз алдына килеп баса. 26 яшендә 1785-нче елны Әбҗәлилнең өлкән улы Габдерәшит вафат булган. Вафат кына микән соң, чөнки документта «у Абдряшита жена Барчин Баширова по умертвии мужа своего вышла по желанию её и по закону мохаметанскому в замужество за деверя родного Абдулхалика», – диелгән. Татарлар арасында әтиләре үлгәч балалар ятим булмасыннар өчен тол хатынны иренең бертуганына кияүгә бирү гадәти күренеш була. Аларның уртак балалары – кызлары Бәдигөлҗамалга 6 яшь, уллары Габделганига 4 яшь,

алар Әбҗәлилнең оныклары. Пугачев күтәрелешеннән соң инде 10 еллап вакыт үзган, әмма «по умертвии» дигән сүз күңелгә шик сала, төрмә газаплары күздә тотыламы, җәзалап үтерелгәнне аңлатамы бу? Әбҗәлилнең кызы Мөхәллимәне кияүгә Уфа өязе Бәләбәй ягындагы Ахун авылына Фазылсаттар Фазлыевка биргәннәр, ә Җәмилә күрше Мордыбый авылы Биккенә Бикмәмәтовта кияүдә. Әбҗәлилнең икенче улы Габдрафыйкка 31 яшь, ул хатыны Фазыла, кызы Гөлбану белән авылда яши. Әбҗәлилнең өченчы улы Ибраһимны 1782-нче елда Уфага солдат хезмәтенә җибәргәннәр. Бу билгеләнеш бик серле булып кала, чөнки безнең тирәдән рекрутка Вяткага алганнар. Әмма алпавыт Тәфкилевларның туган ягы Уфа губернасында булганлыктан һәм аларның җаваплы вазыйфалар үтәгәнлекләрен, сүзләре үтемле булганнарын искә алсак, бу да аңлашыла. 25 ел солдат хезмәтеннән соң исән-сау калдымы, туганнары белән очраша алдымы икән ул егет!?

Сөләймановлар хуҗалыгында өч тол хатын язмышлары... Салиха, Гөлеш, Зөләйха. Әбҗәлилнең абыйсы Габделкәрим вафат, ә улы Габделмәҗит гаиләсенең язмышы тагын да фаҗигалы: 15 яшьлек оныгы Габделваһаб тома ятим. Әнкәсе Гөлеш 25 яшендә, ә әтисе Габделмәҗитнең аннан да иртә үлүе аның восстаниечеләр сафында булуына ишәра. Гомүмән әйткәндә, 1795-нче елгы документтагы 35 кешедән торган Сөләймановлар нәселенең бер генә кешесе дә Биектауның алдагы 1834-нче елгы ревизская сказкасында теркәлмәгән. Көчле, булдыклы нәсел кешеләрен авылдан алып китеп, кайсын кая таратканнардыр.

Тагын бер бәхәсле сорауга тукталасы килә, ул да булса Әбҗәлил Сөләймановка старшиналык указында ул Тоба авылы кешесе диелгән. Күрәсең, ул тумышы белән шул авылдан булгандыр, ә без барлаган 50 ел дәвамындагы документларда аның гаиләсенең яшәү урыны Биектауда. Димәк, Әбҗәлилнең иң гайрәтле, шәп еллары һәм шәхес булып формалашуы Биектау авылы белән бәйле. Авылдашлары арасында дуслары күп булган һәм алар бергәләп көрәшкәннәр.

Төрле чыганакларда безнең авылдан восстаниедә катнашкан тагын ике кеше күрсәтелгән. Беренчесе – Бохармөхәммәт Хөсәенов (кыскартылган тәхәллүсе – Бохармәт Усай). Аның турында Р. Мәрданов һәм И. Һадиевның Әгерҗе районы тарихына багышланган китапларда телгә алына [Мәрданов, Һадиев: 2003. 51 б.]. Пугачевлылар белән бергә көрәшкә өндәүчеләрнең икенчесе – Сөбханкол Мусин. Аның турыда Мәскәү архивыннан табылган «О казаках, татарах...и других замешанных в Пугачевском бунте 1773–1775 гг.» документы ачыклык кертә. 1774 елның 7 июнендә Казан губернаторы фон Брантның Екатерина патшабикәгә җибәргән рапортында Тирсә волостенең 25 котыртучы-

сы арасында Биектаудан Сөбханкол Мусин: «...был возмутитель и в толпе против команды и ездил с Обзалимом в другие уезды сам своею охотою. Остригши волосы по-казачьи явился мая 11 дня 1774 году», – диелгән [РГАДА.Ф. 6. Оп. 1. Ед. хр. 467. Часть 9. Л. 40, 43]. (Сүз ике кеше турында бара). Бәхеткә каршы, алар икесе дә кырыс хөкемгә тартылмаганнар күрәсең, чөнки 1834-нче елгы ревизская сказкада исән-сау Биектауда яшиләр. Бүгенге көндә авылда бу ике көрәшченең нәсел дәвамчылары да бар. Әмма укучыда авылдан берничә кеше генә восстаниедә катнашкан дигән ялгыш фикер тумасын, чөнки анда катнашкан дистә, меңләгән крестьяннарның һәммәсенең исемнәре архивларда язылмаган.

Әлбәттә, бүгенге көндә авыл халкы арасында Пугачев восстаниесе турында хатирәләр сакланмаган. Беренчедән, вакыт бик күп узган булса, икенчедән, халык бик каты җәзаларга дучар булган. Бу түрыда Раиф Мәрдәнов: «... безнең як авыллары ике мәртәбә – ягъни, беренчесе Г. Сөләйманов отряды тар-мар ителгәч һәм икенчесе – Пугачев күтәрелеше тулаем бастырылганнан соң җәзага тартылганнар... Һәр баш күтәрүдә катнашкан авыллардагы өченче кешене асканнар, олы юл трактлар өстендәге авылларда дар агачларын юл буена ясарга әмер бирелгән. Восстаниегә иярүчеләрне дар агачы янында камчы белән суктырырга боерылган. Бу җәза чаралары кайбер урыннарда восстаниедән соң 10 ел үткәч тә кешеләргә дәһшәт һәм шом салып торган», – дип язды. Шулай да авыл уртасында бу канкойгыч вакыйгаларның телсез шаһите – таш күпер бүген дә исән. Имеш, Екатерина II бу күперләрне төзеп бетергәч, Пермь һәм Екатеринбург аша Себергә барасы булган, тик Пугачёв күтәрелеше аркасында сәфәре тормышка ашмый калган, диләр.

Бәйсезлек һәм бәхет өчен көрәштә җаннарын фида кылган милләтебез каһарманнары каршында тирән хөрмәт белән баш имичә мөмкин түгел. Киләчәк буын бабаларыбызның батырлыгын кадерләп саклар, җентекләп өйрәнер һәм батырлар исемлеген тагын да тулыландырыр дип ышанып каламын.

**Әдәбият**

1. Алишев С. Каһарман бабайлар. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1976. – 160 б.

2. Байсарлы И. «Яраланган кошчык – бөркет ул. //Мәйдан. 2008. – №6. – 35–39 бб.

Байсарлы И. Әгерҗе Пугачлары //Мәйдан. 2008. – № 6. – 40–43 бб.

Вахитов И. Тирсә авылы //Мәйдан. 2008. – № 6. – 46–50 бб.

Имамов В. Сәет батыр: тарихи повесть; Татарлар Пугачев явында: әдәби эпизодлар белән баетылган тарихи очерк. – Яр Чаллы: «КАМАЗ» газета-китап нәшр., 1994. – 495 б.

Мәрданов Р. Ф. Тарихта тибрәлгән Тәбәрле. Казан: «Тамга» нәшрияты, 2011. – 771 б.

Мәрданов Р., Һадиев И. Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре («Татар эпиграфикасы» сериясе; 1-нче китап). Казан: «Тамга» нәшр., 2008. – 148 б.

Мәрдәнов Р., Һадиев И. Әгерҗе төбәге тарихы. Казан: «Тамга» нәшр., 2003. – 174 б.

Национальный архив Республики Татарстан (НА РТ). Ф. 3. Оп. 2. Ед. хр. 447 «б».

Российский государственный архив древних актов (РГАДА). Ф 350. Оп. 2. Ед. 1141. Ф 6. Оп. 1. Ед. 467; Ф. 1306. Оп. 2. Ед. 1701.

Татар энциклопедик сүзлеге. Казан: Тат. энцикл. институты ТР ФА. 2002. – 703 б.

# КЫЯМ ҖӘГЪФӘРЕВ: АВТОБИОГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘР

*(Дәвамы. Башын карагыз: № 2, 3, 4, 2018; 1, 2019)*

***Дамир Таҗи***

## РАНГАЗАРДА

Талип мулла беренче көннән алып авылның уртасына Фәртдин бай тарафыннан салынган бер бүлмәле, кечкенә һәм ямьсез мәчеткә барып, халыкка имам торып, көндәлек бишвакыт намазны укыта. Бик пөхтә киенгән, мишәр шивәсе белән сөйләгән яшь мулланы мәчеткә йөрүчеләр ошатып кала. Талип мәдрәсәдә яшәгән вакытта ук мулла була калсам дип яхшы киемнәр: пальто, тун, толып, итек, читек-кәвеш, бүрек, чалма шикелле нәрсәләрне алып куйган иде. Ул беренче айларда Рангазарның түбән очында яшәүче игенче Габделфәттах бай йортында фатир тора.

Мортаза хаҗи белән өйләнү турында да гәп кора. Хаҗи абзыйның:

– Соң мулла Талип, синең үзеңнең расходларың өчен хәер садакалардан килгән сәрмаяң бераз бармы? – дип, соравына, 250 сум акчасы барлыгын әйтеп, йорт-җир алыр өчен калдырган тагын 200 сумын аңа да әйтмәгән була. Шул мәслихәт вакытында Яхшыбай Мортаза хаҗие Талип муллага күп мәслихәтләр бирү белән бергә, күршедәге Югары Әхмәт авылының Шәйхелислам ахунның (автор искәрмәсе: ул Хәбибрахман улы Хәлфин, күренекле татар меценатлары Хәлфиннәр нәселе) Сәҗидә исемле кызын мактап (1879 елгы), Яхья мулла һәм Шәйхелислам хәзрәтләр белән шул мәсьәләне сөйләшеп куйганлыкларын әйтә һәм Сәҗидә туташны Талип муллага димләмәкчеләрен әйтеп бирә. Әмма моның өчен Талипка иң әвәле Югары Әхмәт авылына барып, булачак бабасы Шәйхелислам хәзрәт белән танышып, шул имканияттән файдаланып Сәҗидә туташны читтән булса да күреп килү зарурлыгын әйтә. Вәгъдәләшкән көннәрнең берсендә Мортаза хаҗи яхшы канатлы тарантаска пар кара атларны кушып Рангазарга килә, аннан мелла Талипны арбасына утыртып, Югары Әхмәт авылына кыз күзләргә һәм кызның атасы Шәйхелислам хәзрәт белән танышып, сәфәр уңышлы чыкса, егеткә кыз ошап калса, никахны озакка сузмаска уйлыйлар.

Шәйхелислам хәзрәт кунакларны үз өендә яхшы каршы алып инде күптән әзерләнгән өстәлгә ашка утырта. Кунаклар ашыкмыйлар, озак сөйләшеп утыралар. Талип сүзгә бик оста, мишәр акценты белән картларның күңелен күтәрерлек хикәяләр сөйли. Шул арада Сәҗидә туташ та

Талип мулланы чаршау аркылы берничә мәртәбә карап китә. Аның сөйләгән сүзләрен колак салып тыңлап тора, үзе дә булачак кияүгә күренү өчен ишек алдына чыккалый, нindидер балаларга кычкырып дәшкәли. Бу көнне Талип белән Саҗидә очрашып сөйләшмәсәләр дә, ерактан бер-берсенең буй сынын күреп, тышкы кыяфәтләрен, тавышларын ишетеп ике яшь йөрәк бик канәгать калалар.

Талип мулла Әхмәттән иҗаби җавап алып кайтканнан соң бөтенләй тынычлыгын югалта. Аның кырык эше кырылып ята. Барысына да ничек өлгерергә. Рангазарда ул әле яңа кеше, мәслихәт итәрдәй, эчке серләрен сөйләрдәй бер кеше дә юк. Төрле уйлар белән башы каткан Талип Кармышка, үзенең туган авылына, анда әнисе Гамбәр карчык, абыйсы Фәттахлар белән сөйләшеп алмакчы итә. Өй хуҗасы Габделфәттахның җирән биясен чыбык арбага җигеп, ялгыз гына 120 чакрымнар ераклыктагы Кармышка юлга чыга. Бер атналар чамасы Кармышта торып, бөтен кардәш-ыруглар белән күрешеп сөйләшкәннән соң, әнисе Гамбәр карчык белән энесе Борһанны булачак туй мәҗлесенә баш кода булып бару турында килешеп, үзе белән бергә, аңа көндәлек тормышында ярдәм итеп торырга сеңелесе Вәсиләне Рангазарга алып килә. Вәсилә буйга җиткән, әле тормышка чыкмаган кыз бала. Габделфәттахның вакытлыча биргән фатирдагы өй эшләренә, туй хәзерлекләренә әнисе килгәнче Вәсилә булыша. Рангазар белән Югары Әхмәт авылы арасындагы алыш-биреш, барды-килде мәшәкатьләр көчәеп, бүләкләр, туй алды бирделәре тиз-тиз алмашына торган булып, ике авыл арасындагы 9 чакрым аралык, күптән инде яшь йөрәкләрнең күңел якынлыгына әйләнгән һәм һәр ике як туйларга әзерләнә торган булып калалар. Шәйхелислам ахунның туйларны башлап җибәрү өчен куйган аерым бер шарты була. Бу шарт буенча Талип мулланың Саҗидә туташка өйләнүе өчен муллалык итү турында бирелә торган указны кулына алган булырга тиеш, указ килмәстән торып, Саҗидә туташ белән никах укылмый. Указ белән туй бер-берсенә бәйләп куелган була. Указ килү вакыты гел тоткарланып килә, туй да кичектерелә. Указ көтеп утырулар үзе бер газапка әйләнә. Моннан тыш Талип мулла яшь кәләшне кеше өенә алып кайту яхшы эш түгел дип, мәчет картлары, куштаннар, мәхәллә байлары белән сөйләшеп, мәчеткә якын күрше булып урнашкан Габдулла Арсланов һәм Шаһвәли Шаһиевларның хуҗалыкларыннан 20 метр киңлектә ишекалды кисеп, 200 сумга бәһасен билгеләп, сатып ала. Шаһвәли карт ягындагы җирдә зур булып шомырт, сәрби, тирәк кебек агачлар үсеп утыра. Габдулла карт ягыннан алынган җир урамның бу рәтенә утырган кешеләрнең ишек алды планнары бик киң, буе бик озын булып, 200–250 метрларга сузылган. Шул көннәрдә Карамалы базарына чыгып, анда фәүкылгадә Мортаза хаҗи

белән очрашып, авыл уртасыннан план алганын һәм инде матурырак бер өй кирәклеген әйтә. Мортаза хаҗи Талип мулланы тәбрик итеп, үзенең Мокай боярыннан алган имениясендә зур, 10 аршинлы, 7 тәрәзәле нарат өй һәм бер агач келәтне сезгә бүләк һәм садака иттем, минем саулыгыма ходага дога кыласыз дип сөендерә. Базарда эшләр беткәч Мортаза хаҗи мулланы үзе белән бергә Мокай бояры имениясенә алып китә һәм бояр яшәгән вакытта староста яшәгән, түбәсе такта белән ябылган өйне, башы кабык белән ябылган агач келәтне күрсәтеп, имениядәге приказчикка, Талип мулла өмә белән килгәндә шул ике каралтыны сүтеп, йөкләп биреп җибәрергә боера. Талип мулла хаҗига күп рәхмәтләр әйтеп, озын итеп дога кыла. Бөтен мәхәллә белән өмә оештырып корылмаларны яңа сатып алган планга төшерәләр. Эшне тагын да тиз тоту өчен Талип мулла авылның балта остасы Садыйк картны чакырып, өйне, келәтне матурайту һәм урам якка «урыс капка» ясар өчен 30 сум алтын акча түли. Садыйк карт үзе белән бергә ике кеше алып килеп зур агач өйнең түр башын ишек алды якка каратып, бер метр биеклектәге фундаментка күтәреп, шомырт агачлары астыннан кереп китү өчен тактадан өй алды ясап, аңа ике яктан керә торган, ирләр һәм хатыннар өчен аерым итеп ике баскыч ясап куялар. Агач келәтне дә күтәрәләр. Урам буена яңа тактадан койма ясап, койма өстенә калын такта салып, ул тактага 10 см. (100 мм) кадак кагып чыгалар. Кадаклар үткен очы белән югары карап торалар. Бу хәл Рангазар халкы өчен зур яңалык була. «Урыс капка» өч баганалы булып, җигүле арба һәм җәяүлеләр өчен хезмәт итә. Корылыштан калган такталардан кечкенә капканың уң ягына бер күзле бәдрәфханә әмәлләп куялар. Талип мулла бу эшләрнең шул кадәр тиз барып чыгуына үзе дә хәйран кала. Сеңелесе Вәсилә белән яңа өйгә кереп тә урнашалар.

1898 елның июль башлары, халык уракка төшкән җәйге кызу бер вакытта Талипны волостька чакырталар. Становой пристав:

– Вот мулла ваш указ, с вас положена магарич! – ди, Уфа губернаторы раслап җибәргән указны мулланың кулына тапшыра, аны тәбрикли. Ул замандагы гадәт буенча мулла становойның кулына зур сурәтле акчалардан төртеп, аның белән булган танышлыкны дуслыкка әйләндереп, «знаком будем, гости заезжай», – дип куя. Инде туйны туктатып торган сәбәпләр дә хәл ителә. Карамалы базарына чыгып Бәркәтә һәм Елховой якларыннан килгән якташлары аркылы Кармышка әнисе Гамбәр карчык белән энесе Борһанны туйга чакырып озын хат юллый. Эшләр барысы да әйбәт барса да, Талипның күңелен гел нәрсәдер борчып тора, моны ул хәтта үзенә дә аңлата алмый. Булачак бабасы Шәйхелислам хәзрәт Әхмәт авылында гына түгел, шул төбәктәге муллалар, мәчетләр өстеннән нәзарәт алып бара торган ахун да, аның абруе бөтен өязгә таралган,

өстәвенә зур бай, шуның белән бергә аңа килә торган кунаклары, дус ишләре ифрат дәрәҗәле, исеме халык алдында мәшһүр байлар, имамнар икәнен уйлап, Талип мулланың эчен ниндидер «шайтан» кимереп бөтен тынычлыгын боза. Үзенең бик фәкыйрь гаиләдән булып төрле аңлашылмаучанлыклар килеп чыкмасын иде дип кайгыра. Кичекмәстән үзенең хафалануларын Мортаза хаҗига җиткерә:

– Мортаза абзый! Минем ишетүем буенча туй мәҗлесе без сөйләшкәнчә кечкенә булмаска ошый. Әйтүләренә караганда күрше тирәдәге зур байлар һәммәсе туйга чакырылган, алар барысы да туй мәҗлесенә киләчәкләр имеш, дип ишеттем. Минем башкода булып баручыларым бик гади кешеләр, андагы зур һәм могтәбәр гаиләләр алдында адәм көлкесе булып калуыбыз бик мөмкин. Хөрмәтле Мортаза абзый, безнең яктан башкода булып гаиләгез белән икәү баруыгызны һәм никах мәҗлесенең башында торуыгызны үтенеп сорыйбыз. Мортаза хаҗи моны кире кагып болай ди.

– Беләсезме, туй мәҗлесләре сез әйткәнчә зур булмаячак. Аны кечкенә ясарга вәгъдәләштек. Монда сез куркырлык яки шикләнерлек бер ни дә юк. Анагыз белән энегезне, әлбәттә, туйга башкодалар итеп җибәрүгез шарт. Алар да бармаса кем барырга тиеш соң? Мин димче кода булып, көненә генә барып килергә уйлап торабыз әле. Туй кебек тантана һәр ел булып тормый, үз гомереңдә туй бер мәртәбә килә ул, шундый туйдан энигезне калдырсагыз бик килешеп җитмәс. Сез әйткән фәкыйрьлек мәсьәләсенә килгәндә фикерегез бөтенләй дөрес түгел. Ахун сезнең матди әхвалегезне яхшы белә. Сез үзегезне, без фәкыйр, теге-бу дип кимсетмәгез! Бабагыз Шәйхелислам белүенчә дә, минемчә дә, сез бик байсыз. Тайсуган мәдрәсәсенең иң укымышлы галимнәреннәнсез. Гыйлем зур байлык ул. Әгәр дә ахун кызын байларга яки бай балаларына бирәм дигән булса, аңа кияү була торган кешеләр күп иде. Яучылар ничә еллардан бирле аларның бусагасын таптады. Хәзрәт берсенә дә риза булмады. Ул динле кешене ярата. Минем бердәнбер улым Гыйльфанны да сез укыттыгыз бит... Мортаза хаҗи Талип мулланы икенче каттагы агач өйдән беренче каттагы кызыл кирпечләрдән төзелгән магазинга ияртеп алып керә һәм кулыгызга акча төшкәч, үзегез белеп китерерсез дип туй өчен кирәк булган күп әйберләр бирә. Талип мулла да кесәсендәге алтын белән 100 сумны түләп, калганын бурычка алып торачагын әйтә. Мулланың кәефләре тагын күтәрелеп китә.

Гамбәр карчык, Вәсилә, Борһан туганнары ничә көннәрдән бирле янып пешеп туйга әзерләнәләр. Талип мулланың туып үскән, мишәрләрдән торган Кармыш авылы белән, тормыш итәр өчен беренче мәртәбә ул аяк баскан Рангазар авылы тарих үтеп, күпме гомер кичер-

гән булсалар, әле шул вакытка кадәр һич бер мәртәбә очрашканы булмый. Бу ике авыл арасы 120 чакрымнар булып, берсе шәректә, башкорт иленә якын, икенчесе гарептә булып, Иске Болгар таифәләреннән хасил тапкан авыллар була. Моңарчы бу ике авыл арасында бернинди дә элемтә яки бәйлнеш булмаган. Кармыш кешеләре һичбер вакыт Рангазар дигән авыл барлыгы турында, шулай ук Рангазар халкы кайдадыр Чистай тирәсендә Кармыш дигән авылның барлыгын ишеткәннәре дә булмый. Бу ике авыл халкы арасында кайбер аермалыклар булып, ул кием киюдә, аш-су әзерләүдә, сөйләшүдә ачык күренә. Рангазар халкы әвәлдә башкорт таифәсеннән булып соңгы гасырларда татарлар тәэсире нәтиҗәсендә утырак тормышка үтеп, татарларның телен үзләштереп, аннан дингә өйрәнеп, башкорттан татарлашып бара торган кавем, шул сәбәпле үзләренә хас «минзәлә шивәсе»ндә сөйләшүче, Минзәләне «миндәлә» дип әйтүче беркатлы, садә һәм надан кешеләрдән торса, Кармыш халкы һәм ул тирәдәге авыллар иске Болгар дәүләтенең калдыклары булып, мишәр таифәләрен үз эченә алып, сөйләгәндә «каф» авазын «кәф» авазына әйләндереп үтә каты тел белән сөйли торган булалар. Үз гомерендә Кармыштан беренче мәртәбә ерак сәфәргә чыгып Рангазарга килгән Гамбәр карчыкка һәм Борһанга башкортларның сөйләшүләре, көн күрүләре, тормышлары, өй-җай тотышлары бик сәер, кызык булып күренә. Алар өчен Рангазарда кояш та башка яктан чыга кебек тоела. Шулай җирле тормышны өйрәнеп ятканда Югары Әхмәттән Шәйхелислам хәзрәт туйга чакырып хат җибәрә.

Кармыштан җигеп килгән чыбык арба бик өшәнгән булып, бер якка нык кыйшайган, шуңа карамастан Аллага тапшырып шул өтек арбада туйга баралар. Туй күчтәнәчләрен бер зур тартмага тутырып, арба артына ныгытып бәйлиләр. Фатир хуҗасы Габделфәттахның җирән алашасын җигеп, шуңа тагын бер алаша кушып, ат башына аның улы сары чәчле, калын иренле, һәр вакыт көлеп тора торган Габделхакны утыртып, хатта күрсәтелгән көнне Гамбәр абыстай белән Борһанетдин кода Югары Әхмәт авылына туйга кузгалалар. Кадерле кодаларны утырткан арба иртә белән Рангазар урамыннан Әлмәт авылына таба карап каты чабып чыгып киткән булса да, авылдан чыгу белән атларны үз ихтыярларына куеп, әкрен генә, ашыкмыйча, ана-бала мишәрчә сөйләшеп, «я хода, алда ниләр күрәсебез бар икән» дигән шикелле, арбага чумып утырган кечкенә Гамбәр карчык туктаусыз догалар укып, эчтән нәрсәдер пышылдап бара. Гамбәр карчык гәүдәгә бик кечкенә булып, төс-башы да матурлардан булмый. Йөз битләре картлык һәм авыр тормыштан җыерчыклар белән капланып, алда булачак туй мәшәкатьләреннән катып, туңып калган кешенекен хәтерләтә иде. Гамбәр карчык:

– Бәбкәм, чаукам, атларны бик куалама, ашыгып эш булмас. Хода кушмаса баштагы чәч тә селкенми диләр. Сабыр иткән морадына җиткән, чырагым дип, кучер булып барган Габделхакны үгетли. Гамбәр карчык алда буласы күңелсез вакыйгаларны күңеле белән сизә иде. Әлмәт авылын үтеп, Әхмәт авылы тауларын төшә башлаганда, кодаларның күз алдында киң кырлар, иген басулары, Минзәлә суының яссы болыннары, ерактагы кара тун кигән урманнар күренгәч, карчык бөтенләй каушап калды, үзе дә белмәстән: – Вәлкадәри хәйре сиһи вә шәрриһи мин лиллаһи тәгалә, дип яшьләргә дога кыла.

Әхмәт авылы бер мәхәлләле кечкенә авыл булганга күрә кодаларга авыл эченнән озак барырга туры килми. Шәйхелислам ахунның зур һәм биек итеп эшләнгән буялы капкалары астыннан узганда, үзләрен бик кечкенә, мескен итеп сизәләр...

Зур ишек алдына килеп кергәч, анда кайнап торган туй хәрәкәтләре, көймәле арбалар, читтән карап хәйран калырлык үтә киткән зур айгырлар, арслан кебек ыжгырып торган симез атлар, кабарган песи койрыгы төсле озын мыеклы дәһшәтле кучерлар җәһәннәм оясы булып күренә. Мондый мәхшәрне үз гомерендә беренче мәртәбә күргән яшь кучер аптырап калып, кодаларны кайда туктатырга белмәстән, атларын утын лапасы янына, коелар артына алып барып туктата. Иртәнге намаздан бирле күз алмастан баш кодаларны көтеп торган кунаклар, сәгать уннарга көчкә килеп кергән бу гаҗәеп мәзәк һәм кыек арбаны күреп, аннан төшкән бик гади кешеләрне күреп хәйран калалар.

Кызыл, зәңгәр бояларга буялган ике катлы зур өйнең киң ишегеннән чыккан олы корсаклы, кызыл юан муенлы, башына тубал чаклы чуар чалма ураган хәзрәтне һәм башка ишаннарны күргән яшь кода Борһанетдин куркуыннан нишләргә белмәстән «ләхәуле валәкуаәте иллаһи...», дип дога укып җибәрә. Хатын кызлар ишеге ягыннан кодагыйны каршы алырга дип чыккан симез абыстайлар, байбикәләр, морзабикәләр муеннарына аскан хисапсыз күп көмеш-алтын тәңкәләрен чыңлатып киләләр, атлас, ефәк, кашмир күлмәкләр, кыйммәтле бәрхеттән тегелгән камзулларны, матур хәситәләрне, күкрәкчәләрне, энҗеле калфаклар кигән хатыннарны күргәч, арбадан төшә алмастан маташып яткан Гамбәр карчык бик тонык тавыш белән «исәнмесез» дип кенә әйтә алды. Бернинди дә зиннәтле киемнәр кимәгән, муенына шалтыравыклар асмаган, гади генә кигән кечкенә мишәр карчыгын күргән байбичәләрнең күбесе кул биреп күрешмәстән, борыннарын күтәреп үз юлларына борылып китәләр. Бу күренешләрне читтән күзәтеп торган йорт хуҗабикәсе, кодагый абыстай, башта нәрсә булганын төшенә алмастан, аз гына зиһенен җыя алмыйча еларга да, көләргә дә белмәстән «әстәгефирулла» дип куйды. Туйга кил-

гән башкодагый мишәр карчыгын күреп, аның тышкы килеш-килбәтен тиз генә үз фикеренчә үлчәп алып, башка бай хатыннар алдында үзенең тәкәбберлегенә тап төште дип уйлый, бик каты үртәлә. Бу адәм мәсхәрәсе өчен ире Мортаза хаҗины буып үтерердәй булып гарьләнеп, акырып елаудан үзен чак кына туктатып кала. Нәрсә дияргә сүз таба алмыйча:

– Чистай хәерчеләре килдемени, дип кычкыра. – И ходаем, кешеләр алдында бу хурлыкка ничек итеп түзим, бөтенләй Чистай хәерчеләре икәннәр бит! Валлаhи дип әйтәм!... – дия дә, аскы өйнең ишеген каты ябып кешеләр күзеннән югала. Арба янында байтак вакытлар буталып, адашып калган карчык, кеше күплектән кем бар, кем юклыгын да искәрмәгән хәлдә хатын-кызларга ияреп өйгә кереп китә. Ә хуҗабикә абыстай үзе уйлап чыгарган газаплы тойгылар белән көрәшеп, бер буылып, бер кызарып-бүртенеп туй эшләренә каршы төшәргә сәбәп эзли башлый. Ул үзенең морза кызы булып үскәнлегенә, бөтен илгә мәшһүр ахун хәзрәтнең остазбикәсе булып, миллионер Шакир Хәлфиннарның кодалары, Кәүҗияк авылы Габдрахман хаҗиларга баҗа булулары белән фәхерләнеп, борынын күкләргә чөеп мактанып йөргән байбичә икәнлеген уйлап бөтен бәйрәм кәйфиятләре челпәрәмә килә.

Башкода булып килгән Борһан арбадан төшкәч, уйламаган һәм көтмәгән бу хәлләрдән соң кабаланып торганнан соң, үзе белән салкын гына, теләр-теләмәс, чирканып күрешкән байлар, сәүдәгәрләр, муллалар һәм монтагайлар арасында, бүреләр арасына төшкән сарык бәрәне шикелле нишләргә дә белмичә аптырап вөҗданы сызлана. Аңа кемдер көзге кебек ялтырап торган җиз комганны кулына китереп тоттырып бакча ягындагы яшел буяулы бәдрәфкә ишәрәли. Бу без күзле халыктан югалырга сәбәп чыкканына сөенгән Борһан, солдат адымнары белән эре-эре атлап, бәдрәфкә кереп усал күзләрдән котыла. Бәдрәфтә һич бер нинди эше булмаса да, сары комганга таянып, күп уйланып кала, бирелгән форсаттан файдаланып, ул бераз тынычланмакчы була: өнемме бу, көнемме бу? – ди. Нинди шайтан безне монда алып килде дип килгәненә үкенеп бетә алмый. Бәдрәфтән чыгып әнә шул халык ташкынына ничек кушылрга дип торганда колагына кыңгырау тавышлары килеп ирешә. Борһан урыныннан торып, такта ярыгыннан ишек алдындагы маҗараларны күзәтә. Киң итеп ачылган зур капкадан тузаннар туздырып тагын кунаклар килеп керәләр. Боларның икесе көймәле арбага өчәр ат җиккән кунаклар, соңрак калып килеп кергәне канатлы тарантаска ике ат кушкан. Болар килеп кергәч, ишек алды ат-арба, чабып йөрүче кешеләр белән тулып китә. Борһан да шул ыгы-зыгы вакытында бу «күзәтү пунктын» ташлап чыга, базарда йөргән алып сатар кебек халык арасына кереп югала.

Яңа килгән кунакларның берсе Каран авылының есаул Габдулла кантон булып Шәйхелислам хәзрәткә баҗа, икенчесе, тройка белән килгәне Яңа Әлмәт Ибраһим становой Мортаза хаҗи Мусиннарның кияүләре, өченче арбада Яхшыбай авылы Мортаза хаҗи үзе булып чыга. Бу кунаклар килеп төшкәч ишек алды мәхшәргә ошап, кайнап тора. Сабантуендагы кебек чабып, йөгереп йөрүчеләрнең саны хисапсыз, гөж киләләр. Байларны түбәнчелек белән каршы алалар. Борһан адашкан кеше сыман, мишәрчәләп:

– Бачый, канча кунак? Булган эшләр булды. Бай белән бай булып булмас, морза белән морза булып булмас. Бака үгез булам дип кабарган-кабарган да, бер заман шартлаган икән. Тауга карап тау булып булмый шул. Мелла Талип абзый бик югары үрләгән икән, я хода, ахыры хәерле булсын, дип үз тәкъдиренә иязләшә башлый.

Бераз вакыт үткәннән соң кунакларны, кодаларны өйгә керергә тәкълиф итәләр. Шулар белән аралашып башкода Борһан да сары буяуга матур итеп осталар тарафыннан буялган киң агач баскычлардан икенче кат өйгә, анда зур кызыл келәмнәр җәелгән залга узалар. Татарның гореф гадәте буенча келәмнәр өстенә зур алка ясап чәй-аш урыны әзерләнгән була. Кунакларны ахун үзе каршы алып тора. Кемгә кайда утырырга, кунакларның дәрәҗәсенә карап урын күрсәтә. Кунаклар да бөтен залны идәннән иңләп, күрсәтелгән урыннарга түгәрәк булып утырышалар. Соңыннан бик озак итеп кул күтәреп дога кылалар. Һәр кем үзенең янындагы кунаклар белән исәнлек-саулык, мал-туар, белеш-танышларның, күрше тирәнең, мәхәллә-куйның аманлыгын сорашканчы табынга чәй дә килеп җитә. Кыйммәтле фарфор чынаякларга гүзәл итеп төшерелгән чәчәкләр белән бизәлгән чәйнектән кара бөртекле чәйне куе итеп ясап биргәч, аның тәмле хуш исенә кәефе килгән Габдулла кантон озын бер вакыйганы калын, мәгърур тавыш белән ашыкмастан сөйләргә керешә. Ирләр ягы шулай хозурланып чәйгә утырганда хатыннар ягы да, ашау-эчү табынына җыелган булалар. Шул якта озынчарак итеп ясалган залның идәненә чуар хәтфә келәм өстенә хәзерләнгән табын әтрафына җеп булып утырган хатын-кыз кунаклар, кодагыйлар, кодачалар, бикә-бичәләр, абыстайлар Гамбәр карчыкны сырып алып, аның мишәрчә шивәдә сөйләвеннән кызык табып, бер-берсенә күз кысышып, аңа юри төрле сораулар биреп сөйләштереп карыйлар. Юан вә симез байбикәләр арасында кечкенә генә гәүдәле, чандыр, тутлы һәм кояшта янып каралган йөзле кодагый карчык козгыннар арасына ялгышып кереп калган чәүкә баласы төсле, түрнең бер читендә бөкерәеп кенә утырган була. Акыллы Гамбәр карчык бу байбичәләрнең күңелендә ни ятканын бик тиз төшенеп, боларның үзләренә карата кануный җавап кайтарырга, шулай ук үзе-

нең адәмчелек намусын саклап калу өчен алдан ук уйлап куйган була. Гамбәр карчык мантыйклы итеп сөйләп китә:

– Балам һич хафа булмыйсыз. Дөньядагы барча эшләр ходайдан, аның тәкъдире икәнен төшенгән кеше белсен! Ходай һәр кемгә үз насыйбын үзенә карап биргән, берәүләрне бай, дәүләтле, икенчеләрен фәкыйрь, ярлы итеп яраткан. Берәүләрне надан, икенчеләрен галим, күңелләренә Ислам нурын биреп яраткан чаукам! Тәкъдирдән качып булмый күгәрченнәрем! Бер ил бервакытта да икенчесенә ошамас. Менә мин дә чаукам, сезнең илне күреп хәйран калып утырам. Сез бөтереп икенче икән лә. Бер Аллага мең шөкер булсын. Балалар үстердем. Менә киявегез булачак Талибетдинне ятим хәлем белән тырышып укыттым. Ходайга мең шөкер, хәлфә булды, имам булды. Ходайдан кеше булсын дип теләдем, дин башлыгы булып халкыбызга дин өйрәтсен дидем. Ходай теләгемне буш куймады. Кайбер гадәтләребез үзгә булса да, динебез бер бит, әлхәмдүлила!...

Шулай ике зал да тәмләп чәй эчеп утырганда Шәйхелислам хәзрәтнең остазбикәсе карт абыстай ирләр залы белән хатын-кызлар утырган өй арасындагы кечерәк бер бүлмәдә ишек аркылы сүз тыңлап йөргән Саҗидә кызын түбән өйгә төшереп җибәреп, хатыннар ягындагы ишекне ябып, ирләр ягындагы залдан хәзрәтне бармак белән чакырып ала. Хәзрәт бүлмәгә керү белән абыстай төкерекләрен чәчеп зәһәр сүзләрен сиптерә башлый:

– Адәм көлкесе иттең! Кунаклар алдында, кардәш-ыруг алдында оятлы булдык. Бөтен ил алдында мәсхәрәгә калдык. Фәрештә кебек бердәнбер кызымны таяклы Чистай хәерчеләренә биреп, мине дә, кызымны да утка ташладың. Синең башыңда чалма зур булган белән, чалма астында акылың булмагач, нигә аны киеп, ир булып йөрергә? Валлаһи дип әйтәм, касәм эчәм, Хәйдар морза кызы булмастан үлеп китим, әйткән сүзем сүз. Бәркәтә хәерчеләренә (Кармыш авылыннан ерак булмаган зур мишәр авылы) кызымны бирмим. Бу кылган эшләреңә мин дә, кызым Саҗидә дә риза түгел. Үзең яхшылап, бер генә тапкыр күзеңне ачып карасана. Кодаңның килеш килбәтен күр. Бәрәңге бакчасына куя торган карачкымени? Карачкы да аннан яхшырак була бит. Карт чегән хатынына ошаган анасын күр. Нинди бите белән кодагый булып килгән? Аның сүзләрен тыңлап, оятыңннан гарьләнеп үләрсең. Чәлдер-челдер килеп, чуаш хатыны төсле сөйләшеп утыра. Бәбкәм дә, чаукам, күркәм дә бак, имеш. Ниндидер шайтан теле. Чаукасы да корсын, бәбкәсе дә корсын. Кызымны аларга бирмим дә, туй да кылмам. Кызыма кияү табылмый калмас. Авызын җәеп утырган Яхья хәзрәтне, корсагын киереп утырган Мортаза хаҗины әйтер идем. Аларга кияү бик кирәк булса үзләренең кызларын

бирсеннәр әнә. Әллә кайдан килеп чыккан килмешәк Чистай хәерчесенә кызыңны биреп җибәр имеш...

Хатынының гадәтен яхшы белгән һәм зур сабырлык белән бу сүзләрне ишетеп торган хәзрәт, бер сүз дә әйтмичә бик озак итеп абыстайга карап тора. Абыстайның нәрсәләр әйтәчәген һәм ничек итеп әйтәчәген алдан белгән хәзрәт, хатынының тузынуын беренче тапкыр гына күрмәгәнгә «сыер дулавы – туплауга кадәр генә» дигән халык мәкаленә ишарә кылып, хатынының күзенә нәфрәт белән туры карап тора. Абыстай елан күзенә карап сихерләнгән куян кебек тынычлана төшә. Мәгарәдән шуышып чыккан агулы елан кебек хәзрәт пышылдап-чышылдап сөйләп китә:

– Сүзең шул гынамы? Мин үземнең нәрсә эшләгәнемне яхшы беләм. Саҗидә кызымны син яратмый торган кодага киленлеккә яки сиңа охшамаган кодагыйга хезмәткә дип бирәчәгем юк. Мин бердән бер кызымны үзем яраткан яшь галим, яхшы укыган, зур гыйлеме бар, дөньяның ачысын, төчесен нык татыган, акыллы һәм тәүфикълы вөҗданлы бер яшь муллага бирәм. Мулла Талип минем күңелемә бик ошады. Мин Саҗидәдән сорадым, ул аңа кияүгә барырга риза булды. Кияү килгәндә үзең дә өйдә идең, үз күзең белән күрдең, бу эшне үзең дә мәгъкул дип таптың. Эш беткәч, нигә буран куптарасың. Сиңа кода, кодагыйлар турында шундый ямьсез сүзләр әйтү оят түгелме? Фәкыйрьлектән көләргә ярамый, без бүген бай, Аллага шөкер итик, бәлки иртәгә шайтаннан да ярлырак булырбыз. Мөселман өчен иң зур байлык иман. Мулла Талип бер башы – ялгыз кеше. Саҗидә дә ялгыз. Икесен яхшы ният, яхшы сүзләр белән кушып куйса, яман булмас. Мин Саҗидәне мулла Талипның кем икәнен, яхшы белгәнем өчен бирәм. Киләчәктә бәхетле яшәүләренә дә акылым җитә. Бүген мәдрәсәдән яңа гына чыккан фәкыйрь шәкерт икәнен яхшы төшенәм. Аш табынында утырган могътәбар кунаклар, байлар, хаҗилар, муллалар кияү Талипның кем икәнлеген синнән миннән яхшырак беләләр. Син димче булган кодаларны җүләр кешеләр дип уйлыйсыңмени? Талип мулла янына Рангазарга барып килгәнемне үзең беләсең. Аның шәкерт чагында сатып алган китапларын күреп исең китәр. Шул кешене акылсыз дип кем әйтә ала? Син кызыңны бай баласына бирмәкчеме соң? Нәрсә гарьләндеңме, кимсендеңме? Әйдә алай булгач Саҗидәне Нөркәй Гали Зәйнетдиновлар малае Габдрахманга бирик. Атасы бай, зур кибетләре бар, тегермәннәр тота. Сиңа да ефәк күлмәкләр, мамык шәлләр, бикасәм камзуллар, кашмир яулыклар бүләк итәр. Алай булгач кызыңны шуңарга сатыйк. Үзең ишетеп торасың, Габдрахманның Минзәлә фәхешханәсеннән кайтып кергәне юк, айлар буена шунда эчеп, пычыранып ята. Нәрсә сөйләгәнеңне беләсеңме ахмак хатын. Әнә Шакир байлардан гыйбрәт ал.

Алар Казаннан чемоданнарына алтын тутырып килмәделәр. Килгәндә бәләкәй арба тартып килгәннәр, авылдан-авылга җәяүләп, кабык арба тартып, кырыктартмачы булганнар. Авылларга барып каптырма, энә, сәдәф сатып баеганнар. Фәхешлек, бозыклык өчен мәдрәсә бетерү кирәк түгел. Кызыңның бара торган җире Габдрахманнар түгел, Саҗидә бик әйбәт җиргә бара: абыстай, мәдрәсә, мәктәп, китап, халык, мулла Талип. Чиләгенә күрә капкачы. Син эч пошырып күп лыгырдап йөрмә. Кодаларга яхшы бул!

Хәзрәт белән абыстай арасындагы бу кыска чәкәләшү туйны бозылудан саклап кала. Моны ишек ярыгыннан тыңлап торган Саҗидәнең өстеннән йөк төшкәндәй була. Ул әтисенең тирән мәгънәле нотыгыннан тәэсирләнеп кала, булачак гомер юлдашы мулла Талипның анасы Гамбәр карчыкның сүзләрен дикъкать белән тыңлап тора. Аның сүзләреннән шул көннәрдә дөрләп янган йөрәк утына җиңеллек, юату өчен илаһи нәсихәтләр ишетәсе килә. Сүзгә оста Гамбәр карчык муллаларны да уздырып сөйли:

– Балам без бай булмадык. Хезмәтне сөеп эшләвебез аркасында икмәккә дә ач булмадык. Бал-май гына ашап тормасак та, шул тапкан икмәгебезне тәмле итеп ашый белдек, чарагым! Ходай бер кешегә дә байлыкны тигез итеп бүлеп бирмәгән бит күгәрченем. Берәүләр бай булып, байлыкны кая куярга белмәгәндә, үзләре бер кисәк нан табалмый, бер капарга аптырап йөри. Берәүләргә байлык насыйп кылган булса, берәүләргә уку-белем насыйп әйләгән. Икенчеләренә чибәр кыз биргән булса, башкаларына тәүфикълы угыл биргән кабәм. Ходаның ихтыяры киң, аңа мең-мең тапкыр шәрәфләр булсын! Картайган көнемдә ятим үскән улым Талибетдиннең бер мөселман иленә килеп имам булуына, хак динебезнең юлбашчысы булуына шатланып бетә алмыйм. Зур кешенең ямьле кызына углым Талибетдин белән никах булуына куанычым эчемә сыймый.

Мәҗлес кызганнан-кыза бара. Өйнең нәкъ урта түренә тезләрне ике якка киң җибәреп карт абыстайның атасы Хәйдәр мулла, аның уң ягында Нөркәй авылыныкы Мөхәммәдҗан ишан, тагын Яхья мулла җәелеп, бүселгән борчак чүмәләсе кебек таралып утырганнар. Алардан сулда Теләнче Тамак миллионер Шакир Хәлфин белән Яхшыбайдан Мортаза хаҗи. Менә шул йоннары кабарган ата күркәләрдәй утыручылар арасында яшь әтәч кебек Борһан кода кысылып калган. Ул куллары, терсәкләре белән дә кыймылдый алмый. Саҗидә туташ озак кына Борһан кодага карап тора. Аның ашамастан утыруына рәнҗи. Шул вакыт ишек һәм тәрәзә арасына куелган гөлләр эченнән гур-гур килгән Мисыр күгәрченен бүлмәгә очыртып җибәрәләр. Халык бар да хәйран булып тын кала. Ул да

булмый дивардагы ике ташлы сәгать унбер тапкыр «кук-ку, кук-ку» дип кычкыра. Мортаза хаҗи гаепле кыяфәт белән сүз ала:

– Хөрмәтле кодалар, кардәшләр! Безнең киявебез мелла Талип һәм Шәйхелислам хәзрәт белән үзара сөйләшүдә, шулай ук аклашу мәҗлесендә дә, әлеге туй турында без башкачарак сөйләшкән идек. Туй кечкенә булыр дип уйладык. Кунак төшемне күп чакырып, дус-ишләр, кардәш ыруглар белән сөйләшеп, очрашып утырулар бик күңелле һәм муафыйк нәрсә, әлбәттә. Хәзрәткә һәм килгән кунакларга һиммәтләре, кылган илтифатлары өчен мелла Талип исеменнән һәммәгезгә күп рәхмәтләр әйтергә рөхсәт итәсез. Әгәр дә туй тантанасының шундый зур булачагын алдындан белгәнебездә мондый уңайсыз әхвалләр күренмәс иде, бәлкем? Бу мәҗлестә безнең тарафтан булган кайбер кимчелекләрне гафу итүегезне сорыйбыз. Мин Талип меллага бераз ялганчы булып та калдым. Аңа туйның кечкенә булачагын, кунакларның да күп булмаганын хәбәр иткән идем... Мортаза хаҗиның кем тегермәненә су койганын төшенеп утырган баш кода Борһан уңайсызланыбырак булса да сүзгә кушылырга мәҗбүр була.

– Хөрмәтле кодалар, газиз кунаклар! Безне гафу итүегезне үтенеп сорыйбыз. Безнең шундый зур мәҗлесләрдә булганыбыз юк, безнең кимчелекләр күп. Гафу итегез инде. Талип абзый белән туй хакында башкача сөйләшкән идек, монда бакчи, башкачарак килеп чыкты. Безгә ошаган фәкыйрь гаиләләрнең зур гаиләләргә аралашуы, гадәт кагыйдәләргә туры килеп җитмәс. Безнең наданлыгыбыз, фәкыйрьлегебез көчле булды. Моның үзенә күрә сәбәбе бар. Безнең дә бер Җәгъфәр дигән укымышы вә диндар, олы абруйлы бабабыз булган. Патшабикә Елизавета Петровна заманнарында татарларны көчләп чукындыруга каршы эшләгәне һәм керәшеннәргә җиназа намазы, балаларына мөселман исемнәре кушкан өчен хөкүмәт тарафыннан каторгага Себергә җибәрелеп, шунда шәһит кикән. Аның балаларына укырга рөхсәт ителмәгән. Бабаларыбыз да, үзебез дә надан калганбыз. Мин алты ел Кавказда, Тимерхан шура крепостенда действительнида хезмәт иттем. Зәкитдин исемле туганыбызны солдатта Болак буе казармаларының берсендә урыс офицерлары кыйнап үтерделәр. Кимчелекләребез бардыр, гафу итүегезне сорыйбыз... Борһан элекегедән дә кечерәк булып ике хаҗи түшкәсе арасында тагын күренмәслек дәрәҗәдә кысылып калды.

Табын башына куелган зур ак самавыр башындагы яшел фарфор чәйнектән куе кара чәйне матур буяулы чашкыларга тиз-тиз коеп, чаган агач кашык белән куе каймак-сөтне салып, өстеннән пар чыгарып кайнап торган самавырдан су өстәп, кунаклар кулына чәй ясап биреп торалар. Кунаклар ләззәтләнеп бал-май, баурсак кабып ашыкмыйча гына чәй эчәләр. Кунакларның куллары әле бер якка, әле икенче якка йөреп торалар.

Шәйхелислам хәзрәт әйтелгән фикерләргә нәтиҗә ясап, йомшак кына, картая төшкән тавыш белән сүз ала.

– Чыннан да туй кечкенә булыр дип уйлашкан идек. Бу хакта уңайсызлану, кимсенүгә яки күңел төшерергә бернинди сәбәп юк. Бу голәма мәҗлесендә барыбыз да «мәхкәмәи шәркыят»не яхшы белеп, байлык, фәкыйрьлек, югарылык, түбәнлек нәрсә икәнен Ислам назарыннан чыгып хөкем итәргә кирәктер җәмәгать. Без мәсьәләгә байлыктан чыгып карамыйбыз, бәлки гыйлем-белем назарыннан карыйбыз. Фани дөньяда гыйлемнән зур байлык бармы? Яки наданлыктан да зур фәкыйрьлек бармы? Мулла Талип заманыбызның атаклы мөдәррисе Зәки хәзрәт мәдрәсәсен тәмамлап, гыйлем тәхсил иткән кеше. Тәварих, тәфсир, хәдис, мантыйк, фәлсәфә кебек дәресләрне алган яшь галим икәнен яхшы беләбез. Аннан соң, Уфада Диния назараты каршында мөфтиләр-казыйлар алдында мәвафәкыятле имтихан тоткан вә указын кулына алган, тормыш карау өчен пешеп җиткән кеше дип төшенәбез. Аның әхлагы, кешеләргә булган хуш мөгамәләсе, рухи сәвиясе безгә мәгълүм. Борһан кода әфәнде күңелегез борчылмасын, вөҗданыгыз кыйналмасын. Талип мулланың фәкыйрь яки бай булуы безнең өчен һич әһәмияте юк. Аның булдыклы, иманлы булуын исәпкә алып үзебезнең гаиләгә кардәш иттек. Ахырын бер ходай белә, хәерле кылсын. Күп еллардан бирле Рангазарга назар салып киләбез. Рангазар халкы җиргә, суга бай булса да, халкы ярлы, үзләренең мул җирләреннән яхшы файдаланмыйлар. Тирә-юньдәге урысларга җирләрен сатып, ләгънәт аракы харамны эчеп, сугышып, сүгешеп, нәҗесләнеп йөриләр. Мөселманнар өстенә кара дагъ төшерәләр. Кайда карасаң җәнҗалның, сугышның башы шулар. Сабантуемы, җыенмы, туйлармы, сугышучылар, кычкыручылар шулардан чыга. Зәйни хәзрәтне ут төртеп яндырдылар, Хәсән мулланы башын түбән итеп коега салдылар. Мәдрәсә юк, мәктәп юк. Наданлык, каралык хәттин ашкан. Һәр ел кеше үтерәләр, судлашуның туктаганы юк. Муллалары, мәзиннәре, картлары, яшьләре бары да бер калыптан чыккан. Мәчетләре терәү белән генә тора, булмаса әллә кайчан ауган булыр иде. Менә шул золмәттә калган Рангазар халкына мәктәпләр ачып, мәдрәсәләр торгызып, мәчетләрен тәртипкә салып халыкка хезмәт кылыр дип уйлыйбыз. Моны һәр кем эшли алмый. Мулла Талипның Рангазар халкына иҗаби тәэсир үткәзә алуына һәм аңа тапшырылан бөек дини, иҗтимагый вазыйфаларны тулаем үти алуына без нык ышанганыбыз өчен рөхсәт иткәнбез...

Кунаклар тын калып, инде сүзне кем алыр икән дип көтәләр. Яхья хәзрәт дустын мактап, иртәнге кытыршылыкларны йомшартып туйның мохитын матурайтып җибәрә...

Өйләнгәннән соң Талипның хуҗалыгы үсә. Саҗидә абыстай үзе белән бергә бер ат, бер сыер, берничә баш сарыклар алып килә. Иш янына куш дигәндәй мулланың үзе алган кара биясе, бер кара сыеры, сарыклары кушылгач, инде хуҗалыгы күзгә күренеп тора. Ике ат, ике сыер, 10–15 баш сарыкларга ия була. Бер ел чәчү матдәте белән 12 дисәтинә җир сатып алып, көзге уҗым чәчүгән үз кулы кышка чәчеп калдыра. Йортның зураюын, ишек алдында эшнең күбәюен күреп, ул үз якташларыннан булган Елховой авылының Бәдретдин исемле ятим егетне сөйләшеп, бер ел хезмәт итү шарты белән өйгә хезмәтче алып килә. Ләкин 1899 ел авыл хуҗалыгы өчен бик авыр килә. Яз башыннан ук яңгырлар булмый, һәммә җирләр, үләннәр, гөлләр, игеннәр дә корып китә. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй ваба зәхмәте тарала. Халык ачлыктан интегә, авырый, үлүчеләр арта. Шуның өстенә салкын декабрь айларында утардан кереп кара бия белән бер сыерны урлап китәләр. Аларның эзе дә, тиресе дә табылмый. Шул елны якташ мишәр Бәдретдин хезмәтче 25 пот арыш, бер тимер сабанны һәм кара биянең яхшы збруйларын арзан бәягә сатып, бер төнне үзе дә югалып качып китә. Талип моны сизмәстән кала. Берничә көннәр үткәч Елховойга эзләп барса да, ул анда кайтмаган була. Бәлки Рангазар угырылары белән бергә Урал ягына чыгып сызган булалар.

*(Дәвамы бар)*

# ЭСТОНСКАЯ ЖЕНА ТАТАРСКОГО СОЛДАТА ИЗ ПЕНЗЕНСКОЙ ГУБЕРНИИ, XVIII ВЕК

***И.Д. Биккинин***

***Аннотация:*** *На основе архивных данных автор проанализировал события 1781 г., когда солдат-татарин Бахтей Алешин привез из службы в свою деревню Лопуховку жену-эстонку – Анну Юрьеву из деревни Мягиле, расположенную около г. Пайде. В результате доноса в дела семейные далее вмешались правоохранительные органы, что привело к уголовному делу и распаду молодой семьи.*

***Ключевые слова:*** *Анна Юрьева, Бахтей Алешин, Лопуховка, Пайде, доношение, расправа, эстонка, христиане, рекрут.*

В Центральном государственном архиве Республики Мордовия хранится любопытное дело 1781–82 гг. по возврату эстонки («чухонской дочери») Анны Юрьевой (Ерьевой) в ее родную деревню Мягиля, находившуюся рядом с городом Пайде (ныне Эстония) [ЦГАРМ. Ф. 107. Оп. 1. Ед. 40. Л. 1–22.].

Дело начато 10 ноября 1781 г., завершено 24 января 1782 г. Полное название документа – «Дело по доношению города Пайды деревни Мягиля чухонской дочери Анны Юрьевой в растлении ее ис татар солдатом Бахтеем Алешиным и в увозе ее с собой в деревню Лопуховку».

Город Пайде существует в Эстонии по сей день – это центр провинции Ярвамаа. Деревня Мягиля, как сообщили эстонские коллеги, это нынешнее село Mäeküla, в старину называлось Mehheküll. Находится в 8 км на восток от Пайде.

А вот татарская деревня Лопуховка уже опустела – все её жители выехали. В старину у нее было и второе название – д. Борки. Она находилась в Краснослободском районе Республики Мордовия, снята с учета 27.07.1988. Деревня располагалась на Чукальском овраге. По данным 7 ревизии (1816), здесь жили 167 человек, 93 мужчины и 74 женщины. Насчитывалось 27 дворов. В «Списке населенных мест Пензенской губернии» (1869) Лопуховка – деревня казенная, из 31 двора (Краснослободского уезда).

Первый документ дела – «Доношение», написанное русским писарем (копиистом) от имени Анны Юрьевой:

«Всепресветлейшая Державнейшая Великая Государыня Императрица Екатерина Алексеевна, Самодержица Всероссийская, Государыня Всемилостивейшая

Доносит г. Пайды деревни Мягиля чухонская дочь девка Анна Юрьева, а почему мое прошение, тому следуют пункты:

1. Имелся быть в нашем г. Пайде ис татар салдат Бахтей Алешин, которой с вымыслу напоя меня до пьяну и усильно растлил, и обесщестил меня и после онаго, признав свое винность, уверивши, чтоб взять меня взамужество за себя и подговоря оным, привез в деревню Лопуховку в дом свой, где с великаго поста (февраль–март 1781 г. – Прим. автора) по август месяц и жительство имела.

2. А прошедшаго августа, а которого числа не упомню, в деревню Лопуховку, в бытность же мою в доме у него салдата Алешина, наехав Краснослободской капитан исправник Степан Барисов, взяв меня и объявил в Краснослободской нижней земской суд к допросу, где я и в допросе показала тож что я, Анна, подлинно чухонская дочь государственная, а не господская, обругана и сманена оным Алешиным.

3. И по учиненном Краснослободском нижнем земском суде определение – велено меня именованную отослать к отдаче по-прежнему в наше жительство в город Пайду к городническим делам, а с тем салдатом Алешиным за обругание и бещестие, и за подгавор его меня ко взятью взамужество в силу Вашего императорского величества государственных законов с ним ничего не учинено, и я ничему не удовольствована.

И дабы высочайшим Вашего императорского величества Указом повелено было сие мое доношение Краснослободской нижней расправе принять и в силу Вашего императорского величества всевысочайше изданного с управления губерниев учреждения 229 и 231 и 233 статей то дело ис Краснослободскаго нижнего земскаго суда изстребовать в Краснослободскую нижнюю расправу и в оной расправе вновь переследовать, а показанного салдата Алешина сыскать и за подговор и о взятию меня за себя взамужество, и за учиненные им противные поступки учинить с ним как Вашего императорского величества Указы повелевают и меня в чем подлежит удовольствовать.

Всемилостивейшая Государыня, прошу Вашего императорского величества о сем моем доношении решение учинить ноября дня 1781 г. к поданию надлежит в Краснослободской нижней расправе. Доношение писал оной же расправы капеист Иван Кочетков».

Под пунктами идет запись: «К сему доношению Краснослободскаго уезднаго казначейства капеист Василей Травницкий вместо вышеписанной чухонки Анны Юрьевой по ея прошению руку приложил». Указана дата: 10 ноября 1781 г.

Далее идут разнообразные судебные, полицейские и административные документы, из которых понятно, что солдата Бахтея Алешина (по архивным документам его звали Бахтеяр Адельшин) так и не поймали.



Татарская супружеская пара из деревни Борок, Лопуховка тож, Краснослободского уезда Пензенской губернии. Фото находится в Национальной библиотеке Франции. Есть пометки: *Baron de Baye, 1897. Пензенская губерния, татары, Лопуховка.*

Как можно понять по этим документам, Анна и Бахтей приехали из Пайде в Лопуховку примерно в феврале-марте 1781 г., а в августе того же года капитан-исправник Степан Борисов забрал Анну из дома Бахтея и отвез в Краснослободский нижний земской суд на допрос. Во времена

Екатерины II капитан-исправников избирало местное дворянство – сроком на три года. Суд, в составе самого капитан-исправника Борисова и двух заседателей, вынес решение о том, что Анну следует отправить по прежнему месту жительства, в город Пайде, и там передать местному городничему для принятия решения о ее наказании.

Из этих бумаг непонятно, кто донес властям о том, что Бахтей Алешин привез себе жену-христианку – возможно, его односельчане – из тех, кто рассчитывал выдать свою дочь за Бахтея.

Также непонятно, почему Анну не отправили в Пайде сразу же, в августе 1781 г., когда были хорошие условия для проезда тогдашним транспортом на конной тяге – на каретах, повозках, таратайках, экипажах, тарантасах и т. д. Вместо этого Анну определили для прокормления судье Краснослободской нижней расправы прапорщику Воронцову. Возможно, Анна долго сопротивлялась написанию жалобы на Бахтея, которого никак не могли поймать.

И только 10 ноября появляется доношение от имени самой Анны, где она якобы требует передать ее дело из нижнего земского суда в нижнюю расправу (расправа – это тоже суд) и провести новое следствие, чтобы подвергнуть наказанию солдата Бахтея Алешина.

В переписке между двумя краснослободскими судами обильно цитируется глава 14 Генерального регламента (о порядке корреспонденции между ведомствами – коллегиями); артикул 167 главы 20 «Артикула воинского» (от 26 апреля 1715 г.): «Ежели кто женской пол, старую или молодую, замужнюю или холостую, в неприятельской или дружеской земли изнасилствует, и освидетелствуется, и оному голову отсечь, или вечно на галеру послать, по силе дела».

Но чаще всего повторяется часть статьи 24 главы 22 «Соборного Уложения» (1649 г.): «А будет кого бусурман какими-нибудь мерами насильством или обманом русскаго человека к своей бусурманской вере принудит, и по своей бусурманской вере обрежет, а сыщется про то допряма, и того бусурмана по сыску казнить, зжечь огнем безо всякого милосердия».

Очевидно, что если бы Бахтея поймали, его могли бы сжечь или отсечь ему голову, ведь в доношении Анны речь идет не о том, что она приехала с Бахтеем по доброй воле. Нет, речь идет о том, что Бахтей якобы споил ее, изнасиловал («усильно растлил»), обесчестил и привез обманом в свой дом. По таким показаниям Бахтею грозило отсечение головы, по «Артикулу воинскому».

Также ему по «Соборному уложению» грозило сожжение. Видимо, хотя Анна и не была «русским человеком», а «чухонкой» (эстонкой), мусульман наказывали смертью не только за принуждение «к своей бусур-

манской вере» русских христиан, а любых христиан Российской империи.

Несомненно, если бы на Бахтея не донесли, Анна со временем стала бы неотличимой от местных татарских крестьянок, – ни по одежде, ни по языку, ни по религии. Она бы говорила по-татарски, и так же читала бы намаз, как и все ее односельчанки.

Также несомненно, что Анну заставили оговорить Бахтея, ведь вряд ли без страстной любви эта эстонка уехала бы так далеко из родной деревни Мягиле рядом с городом Пайде – оттуда до Лопуховки 1600 километров. Ведь только дорога в татарскую деревню отняла у влюбленных около месяца. Анна могла заявить на Бахтея в любом городе, через который они проезжали. Личность солдата Бахтея Алешина и состав его семьи были уверенно определены при ознакомлении с 4-й ревизской сказкой 1782 г. по деревне Борок (Лопуховка тож) [ЦГАРМ. Ф. 26. Оп. 1. Ед. 12. Л. 619–620]. Во всей ревизской сказке Лопуховки отмечены только два рекрута – Бахтеяр Аделшин, 1757 г. р., и Акбулат Акмеев, 1742 г. р. Обоих забрали в армию в 1774 г., когда Бахтеяру было 17, а Акбулату – уже 32 года. По этой ревизии нет мужчин с именем Бахтей Алешин, а Бахтеяр только один, с прозванием по отечеству Аделшин. Алешиных нет совсем. По совокупности данных можно сделать единственно возможное предположение – при записи в рекруты Бахтеяр Аделшин был записан как Бахтей Алешин. Когда ему было 24 года, то есть после того, как он отслужил 7 лет, он был отпущен из армии домой. Отец семейства – Аделша – видимо, умер ранее 1763 г., так как в ревизии его нет. Есть жена Аделши, мать Бахтеяра – Гюльсюм Масимова дочь (1703–1770), родом из деревни Акашево. Также имеется четыре старших братьев Бахтеяра – Мурсалим (1721–1765), Байбек (1724), Курмай (1739), Сеит-Газа (1751) – Аделшины дети. Есть две сестры Бахтеяра – Фатьма (1748), выдана замуж в деревню Байкеево; Фамья (1756), выдана замуж в д. Кадышево. Отмечены семьи братьев Бахтеяра – их жены взяты из дд. Байкеево, Енгуразово, Дашкино, Кадышево, их сыновья также поженились на татарках из тех же деревень.

Неудивительно, что капитан-исправник Степан Борисов так и не смог сыскать солдата Бахтея Алешина (он же Бахтеяр Аделшин) – при таком количестве родственников в разных татарских селах двух уездов ему было где прятаться. Он прятался от суда и неминуемой казни за то, что влюбился в эстонку Анну, для властей прежде всего христианку, и осмелился привезти ее к себе домой как жену.

Пока неизвестно, добралась ли Анна к себе домой в деревню Мягиле, и как сложилась у нее дальнейшая жизнь. Ее родственников сейчас ищут эстонские краеведы из Пайде. Согласно ревизской сказке 1811 г. по

Лопуховке, из родственников Бахтея в деревне осталась только семья его брата Сеит-Газы Аделшина. Видимо, остальные его братья с семьями переселились в другие населенные пункты до 1795 г.

Возможно, сам Бахтей не стал рисковать головой и ушел к казахам – от Лопуховки до казахских степей всего лишь 600 км. Так поступали многие молодые татары, пытающиеся спастись от смертной казни или каторги. Впрочем, бывалый солдат мог также бежать и на Северный Кавказ, к кумыкам, балкарам, карачаевцам, чеченцам.

## Источники и литература

Центральный государственный архив Республики Мордовия (ЦГАРМ). Ф. 26. Оп. 1. Ед. 12.

Центральный государственный архив Республики Мордовия (ЦГАРМ). Ф. 107. Оп. 1. Ед. 40.

И. К. Инжеватов. Топонимический словарь Мордовской АССР. Саранск: Мордов. кн. изд-во, 1987. – 264 с.

## Мирасыбызның төбәк тарихына кагылышлысы

## Наше историко-краеведческое наследие

*Ф. З. Яхин*

# «МӘЛИКӘ КИТАБЫ» ТАРИХЫ

*(Ахры. Башы, № 1, 2, 3, 4(2018); 1, 2019)*

## XIII

«Мәликә китабы» гади, халык әдәбияты әсәре булса да, аның эчтәлегендә халкыбызның дини һәм дөньяви яшәеш хакыйкатьләрен эзләү юлында тышкы һәм эчке көрәшләренең үзенчәлекләре чагылыш тапкан, аның тарихи, мәдәни, иҗтимагый әһәмияткә ия олуг ядкәр икәнлеген танымый мөмкин түгел. Күп очракта шулай килеп чыга: беренче укуда гадәти, хәтта беркатлы, хикмәтсез тоелган язмалар, әгәр дә мәгънәсенә төшенү юлларын, кысып кына булсын, ача алмасак, эче тулы хәбәр, эче тулы хакыйкать, тарих һәм мәдәният гәүһәрләре икәнен күрмичә һәм белмичә дә калабыз. Укыганны аңлаудагы чикләнгәнлек фикердә тарлыктан килә, әлбәттә. Аздан күпне аңлар һәм аңлый белү өчен дә мәгълүматлы булу шарт. Гуманитар белемнәрнең хасияте менә шунда. Һәр белем өлкәсе гаҗәеп киң һәм тирән. Шуның эченнән кирәкле мәгълүматларны алу һәм ала белү зур көч, тырышлык, эзләнүләр таләп итә. Хәер, эзләнүчән галимнәрнең дә төрле нәтиҗәләргә килүләре бер дә сер түгел. Кайсын да хаксыз, хаталы дип булмый кайчакта. Әмма хакыйкать барыбер дә ике төрле түгел, ул тик берәү генә.

Хәтта ислам дине дигәч тә, аны бертөрле, һәммә мөселман кавемнәрендә дә аермаларсыз дип күзалларга һич тә ярамый. Пәйгамбәрнең вафатыннан соң ук, 633-нче елда башланып киткән дини юлны җуймый саклау азмы галимнәрнең һәм изгеләрнең гомерлек эшенә әверелгән? Бу өлкәдә туган бәхәсләр, инкарь һәм гаугалар, йөзгә-йөз килүләр азмы күңелсез хәлләргә китергән? Һәм хәзер дә хәбәрсезләрне андый вәсвәсәләр туктаусыз саташтырып тора. Дини юлны җуймый саклау тарихи үсеш дәвамында иң катлаулы, авыр, мәшәкатьле, икеләнүле эшләрнең берсе булып чыга. Яңа фикерләрсез үсеш мөмкин түгел. Иске карашлар бары бетүгә илтә. Бөтен хикмәт тә менә шунда – яки без үсәргә, яшәргә тиешбез, яки бетәргә, туктарга. Яңалыкка, яңа фикергә каршы

көрәшүнең мәгънәсе юк. Аны аңларга, кабул итә белергә, һәм тормышта файдаларын күрүдән дә хәерлесе табылмас. Иске үлде, бетте дип бит сыпыру да урынсыз. Һәр яңа искене алыштырып килә, дигән караш та дөрес түгел. Яңалык искенең куәтен һәм көчен арттыру очраклары да бар дип белүебез – хакыйкатькә якынаюыбыз. Яңаны сынап, аңлап кабул итү һәрвакытта да мөмкин түгел. Бу мәгънәләрне аңлаганчы кешелек ничәмә гасырларны кичә барган. Бүген көндә дә аларга төшенә алдык, димибез.

Дин юлын исламда «мәзһәб» дип йөртәләр. Ул суфилар юлы, ягъни тарикатьтән аерылып тора. Мәзһәб – хакыйкатьне танып белү, төшенү принципларын бирә, тарикать – хакыйкатькә ирешү ысулларына кертә. Аерма бары тик белү-төшенүдә һәм мәгънәләрне аңлар хәлгә ирешүдә генә кебек. Әмма төшенүсез ирешү – юк, төшенү ирешүне таләп итми. Шунлыктан суфичылык – мәзһәбнең дәвамы, нигезе түгел. Боларны ачык аңлау «Мәликә китабы»ның эчтәлеген ачыкларга мөмкинлек бирә. Әсәр суфичылыкка кадәрге чорда язылган, бу фактта шик була да алмый. Суфилык белән суфичылыкның аермасын тарикать төшенчәсе формалашып җитүгә бәйле аңларга кирәк. Бу тәртиптә мәсьәләгә караш тудыру безне фикерләүдә буталудан саклаячак.

Ислам тарихында динне сәхабәләрдән аларның балалары, ягъни гайре-сәхабәләр (сәхабәләрне белүчеләр), ә алардан – табигыйннар, аннары табигыйннардан, үз чиратларында, гайре – табигыйннар өйрәнеп калган да, шуннан соң хаталанулар башланган, шул заманнарда, ягъни VIII гасырда дин галимнәре мәйданга чыгып, йола һәм гадәтләрне тәртипкә керткәннәр дип аңлатыла. Баштарак мәзһәбләр сәяси мәгънәгә ия булган. Әбу-Бәкер, беренче хәлиф, ислам дине шәригатен үз аңлавында төзегән, Гомәр хәлиф чорында шәригать аның карашлары кысасыннан чыкмаган һ.б. Хәлифләр үз сәясәтләрен алга сөрүләре сәбәпле, алар яшәгән заманнарда дин юллары да сәяси төс алган. Бу сәясәт Коръәнне аңлау-аңлату, шәригать кануннарын төзү һәм алар нигезендә идарә итү принципларын да үзенә буйсындырган. Моңа каршы гыйльми-гакыйдә, ягъни хакыйкать булучы Аллаһы тәгаләне танып белү принциплары куелган. Сәясәт һәм гыйлем юлы үзара каршылыкта торып, дин галимнәрен хәлифләрнең җәфалаулары, хәтта үлемгә хөкем итүләре кебек күренешләрне дә мәйданга чыгарган. Һәр идарәче дини төркем бүген дә ничек үз сәясәтен алга чыгарып, дини аңлауларны һәм аңлатуларны сәясәтләренә буйсындырса, вакыйга-күренешләр элек тә шул рәвештәрәк барган. Хәтта галимнәр арасында да төркемчелек алга чыгып, аларның да диндә, шәригатьне аңлатуда сәясәт корулары һич кенә дә сер түгел. Анысы да электән шулай килгән. Сәясәт – киң, гомуми күренеш, ә гыйлем – берәмлек, шул диңгез эчендә энҗе бөртеге сыман. Әмма диңгезсез энҗе бөртеге ничек тумый

һәм үсми, сәясәт дәрьясыннан башка, аңардан аерым гына иҗтимагый гыйлемнәр дә яши алмый.

Сәяси һәм гыйльми-игътикади мәзһәбләрнең саны тарихта төгәл мәгълүм түгел. Әмма ачык билгелеләре дә җитәрлек. Диндә сәяси һәм гыйльми хәрәкәтләрне, асылларына карап, әһле-сөннәт һәм әһле-бидгатькә аералар [Mehmet Yilmaz. S. 197]. Сөннәт ул – Пәйгамбәр һәм аның сәхабәләре өйрәткәнчә динне тану юлын саклау, аңа сәләфийә, әшгарийә, матуридийә, ә әһле-бидгатькә, ягъни шигый мәзһәбенә галәвилек (шигыйлык), хавариҗа, җәбрийә, мөгътазилә, мөрҗийә, мөшәббиһә һ.б. керә [Шунда ук]. Сөнниләр ничек шигыйларны бозыклар, ягъни әһле-бидгать буларак атаса, алар да, үз якларыннан хаклы булуларына инанган хәлдә, сөнниләрне ялгышучылар, дөрес юлдан тайпылучылар буларак беләләр. Әһле-сөннәт мәзһәбе юнәлешләре игътикад ягыннан, ягъни иман, хакыйкатьне төшенүдә, һәм гамәли, ягъни фикһе, мөгамәлә, гыйбадәт мәсьәләләрендә үзара шактый охшашлар һәм аерымлылар. Гамәли мәзһәбләр дүртәү, алар: хәнәфилек, шәфигыйлык, мәликилек һәм ханбәлилек [Шунда ук].

«Мәликә китабы» гамәли мәсьәләләрне бик аз куерта, ул аларга хәтта бөтенләй дә керми, диярлек. Әмма аның бу яктан халыкның үз гореф-гадәтләренә таянуы фәнни-текстологик анализдан ачык күренә. Бу фактлар үзләре генә дә «Мәликә китабы» язылган дәвердә гамәли мәзһәбләргә тиешенчә игътибар бирелмәгәнлеге хакында сөйли. Әмма әсәрнең әһле-сөннәт юлында язылганлыгында һичбер төрле шик юк. Без андагы кайбер фикерләрне матуридийәгә караганлыгын инде берничә тапкырлар искәреп узган идек. Инде мәсьәләне ачыграк тикшерү зарур.

Матуридийә кәлам фәлсәфәсе, игътикад мәсьәләләрендә әшгарийә һәм сәләфийәнең юнәлешләре белән янәшә тора. Шул ук вакытта алар арасында аермалар да җитәрлек. «Игътикад» дигәндә – иман, ягъни Аллаһы тәгаләнең хакыйкатьләрен танып-белү мөмкинлекләре фәлсәфәсе күздә тотыла. Сәләфийә мәзһәбе Коръәнне, Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләрен, Пәйгамбәрнең өйрәтмәләрен ишетеп калган сәхабәләрнең ислам дини хакыйкатьләрен аңлау һәм аңлатуларына таяна. Әмма вакыйга сәбәпләренә һәм вакыт-урын төрлелегенә бәйле рәвештә сәхабәләр дә бер үк сүзләрне һәм хәбәрләрне төрлечә кабул иткәннәр. Монда тәрбиянең, аң-белем дәрәҗәсенең, гореф-гадәтләрнең, шулай ук кешеләрнең табигате, фикерләүгә һәвәслеге, хәтере һәм шулар кебек башка төрле үзенчәлекләре дә үз рольләрен башкаралар. Шунлыктан сәләфийәдә сүздән гамәл өстен куела һәм һәрбер хәбәрнең эш-гамәл белән дәлилләнгән булуы таләп ителә. Алар – әлбәттә рационалистлар. Зиһен һәм акылга таянуда бик сак эш итәләр. Акылның гаҗизлеге, вакыйга-күренешләр-

не, сүз һәм мәгънәләрне дөрес аңламау һәм аңлатмавы очраклары һәм шуның аркасында гөнаһка бату куркынычы сәләфийә мәзһәбендә аеруча катгый искәртелә. Алар хакыйкатьнең күрсәткече буларак сүзне түгел, бәлки гамәлне саныйлар. Тормышка ашарлык һәм мөмкин, чынбарлыкта урыны булган һәммә нәрсәне хакыйкать итеп күзаллыйлар. Илаһият хакыйкатьләрен аңның аңлата алуы һәм аңлавы мәсьәләсен шик астына алып, алар практик тормыш күрсәткечләре белән генә чикләнәләр. Бу исә Илаһият хакыйкатьләрен аң ярдәмендә танып-белү аша бәндәләренең тормыштагы хаталарны төзәтүләрен, тормышны үзгәртеп кору мөмкинлеген инкарь итүгә китерә. Аларның аң-белем көченә игътибарсызлыклары, консервативлыгы, кадимилекне яклаулары иҗтимагый фикер үсешен тоткарлауга китерә. Сәләфийә мәзһәбенең шушы асыл үзенчәлекләре сәхабәләрнең Пәйгамбәребезгә һәм аның заманына чиксез мәхәббәтләре белән сугарылган изге бер юл икәнлеген дә аңларга тиешбез. Шушы сыйфатлары өчен аларны ярату һәм аларга соклану – урынлы. Әмма чикләнгән булуларын да онытырга ярамый.

Сәләфийә мәзһәбе тәэсире халкыбызга да көчле һәм даими булды. Шушы тәэсирнең күркәм ягы шунда – без үзебезнең халкыбызга гына хас борынгы йолаларыбызны ислам тәгълиматы заманнарына да өммәт идеаллары һәм гореф-гадәтләре рәвешенә күчерә алган милләтләрдән булдык. Шушы рәвешле ислам дине безнең үз динебезгә әверелде, ят, гарәптән кергән, гарәпчә булган гореф-гадәтләр шул сәбәпләр белән миллиләште, җан рәхәтебезгә әйләнде. «Мәликә китабы»нда бәян ителгән карашларның төп күпчелеге, берәмтекләп тукталып үткәнебезчә, борынгы бабаларыбыздан килгән иделәр. Аларны ислам идеологиясе кысаларында яңартып җибәрергә сәләфийә мәзһәбе карашлары мөмкинлек бирә. Сөнни мәзһәбенең бер канаты сәләфийә булу сәбәпле ул шулай иде. Әгәр дә тарихи яктан карасак, ислам дине халкыбызның рухына, дөньяны аңлавына, карашларына кискен каршылык итсә иде, ул вакытта мөселманлыгыбыз да мәйдан алмас иде. Халкыбыз ислам шәригате кысаларында «үз милли шәригатен» тудыра алган икән, аны өйрәнергә, төшенергә, күрергә, аңлата алырга да тиешбез. Сөнни мәзһәбе гореф-гадәтләргә таянуны инкарь итми. Тарихны яңа биттән, яңа халык һәм яңа кыяфәт белән башлап китү мөмкин түгел. Безгә сәләфийәт ислам дине белән килеп, Алтын Урда чорында, бигрәк тә XIV гасырда ныгып урнаша. Сәләфийәтнең бу чорда иң атаклы галиме Сәгъдетдин Тафтазани (1322–1390), укытучысы Котбетдин Әр-Рази (1365 нче елда вафат) белән бергә Идел буенда Сарай шәһәрендә яши. Ул Үзбәк ханның (1283–1341, 1313 нче елдан хан) өченче улы Җанибәк ханның (1342–1357 нче елларда идарә итә) укытучысы һәм галиме була, Сарай шәһәрендә каләм, геометрия,

мантыйк, гарәп теле һәм поэтика мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр яза. Аның бигрәк тә кәлам фәлсәфәсенә багышланган рисаләсе озак еллар буена зур мәртәбәләр казана, аны бөек галим һәм философ буларак таныта. С. Тафтазаниның матуридийәгә карата хөрмәте дә хезмәтләрендә сиземләнә. Аңардан чыгып кына Тафтазанины әшгарийәгә каршы булган дип әйтерлек урын юк. Хикмәте шунда, рационализмга, акылга сыешлы һәм гамәл белән раслап булырлык хакыйкатьләрне генә танучы сәләфийә юлыннан матуридийә дә һәм әшгарийә дә кискен аерылмыйлар, янәшә баралар. Алар өйрәткәнчә, Аллаһы тәгаләнең хакыйкатьләре бәндәләренең аң белән танып-белүеннән ирекле, шунлыктан иман – тел белән әйтелгәндә – дөрес, кешенең акылы һәм күңеле Аллаһының барлыгын һәм Мөхәммәднең Аның илчесе булуын факт рәвешендә, дәлилсез кабул итәргә тиешле. Хакыйкатьне кабул итәр өчен аң дәлилгә таяна. Матуридийә дәлил һәм фикерне бердәй күрә, фикер бар икән, аны дәлил буларак кабул итә, чөнки дәлил белән фикерне үзара бәйләнештә дип таный. Фикер кемдә дә дөрес күзаллау тудыра. Әмма дөреслек ул – хакыйкатьнең үзе түгел. Матуридийәдә бу фәлсәфә әшгарийәдә һәм хәләфийәдәге кебек үк. Алар Коръәннең аңлау өчен авыр урыннарын Ахирәт көнендә чишеләсенә ышана, Аллаһының шәфкате, Аллаһының казасы, бәндәләрнең үзләрен тотышлары, фигыль һәм эш-гамәлләре мәсьәләләрен төшендерүдә Пәйгамбәребез һәм сәхабәләрнең юлларын ачыклау, эзләү, барлау ягыннан зур тырышлыклар күрсәтәләр. Матуридийә мәзһәбе тырышлыкны бәндәнең ихтыяры буларак аңлый һәм аңлата, әшгарийә һәм сәләфийә мәзһәбләреннән аермалы буларак, матуридийә мәзһәбе рационализмы, бигрәк тә рациональлекне югары куя, гамәлгә сыешлыны акылга сыешлы итеп, акылга сыешлыны гамәлгә ярашлы дип таный. Бәндәләрнең олы гөнаһлары аларны иманнан аера дип танучы мөгътазиләгә якынаеп, матуридийә ихтыярга өстенлек бирүнең хатага илтүен төшендерә. Болар «Мәликә китабы»нда да нәкъ шулай бәян ителәләр, кешенең өстенлеге табигатеннән өстен чыга алуында икәнлеге әсәрдә кат-кат белдерелә, матуридийәнең дә әхлак һәм әдәп кагыйдәләрен аңлатуының асылын шушы үзенчәлек билгели. Аңга һәм акылга, сәләфийәдән аермалы буларак, матуридийә зур урын бирә һәм хакыйкатьне танып-белүдә аңның ролен таный. Бу исә кешенең гамәленә генә түгел, аңына да таяну мәсьәләсен алга чыгару дигән сүз. Әшгарийә мәзһәбе бәндәнең ихтыярын яратылган, Аллаһы тәгалә тарафыннан бар кылынган дип саный, ягъни Аллаһы тәгалә тарафыннан бирелгән язмыш белән бердәй аңлата, матуридийә исә яратылмаганлыгын, бәлки кешенең үз тырышлыгы икәнлеген төшендерә. Матуридийә Илаһи хакыйкатьләрнең акыл белән, аң тарафыннан танылып-беленүен ачыклый, иманның ныклыгын акылга бәйли, Аллаһы-

ның берлеген һәм барлыгын аң белән, акыл ярдәмендә танып булуын раслый. Бу яклары белән матуридийә мәзһәбе сәләфийә һәм әшгарийәдән кискен аерылып тора. Акылга, аңга танып-белүдә төп урынны бирү һәм моның өчен тырышлык-ихтыярның кирәклеген төшендерүе белән ул аң-белем идеалын өстен чыгара. Әшгарийәләр һәм сәләфийәләр Аллаһының барлыгын, ни-бар хакыйкатьләрнең һәммәсен бәндәләренә дин белдерер дип аңлаталар. Бу исә танып-белү кешенең теләге белән түгел, Аллаһы тәгаләнең рөхсәте, Аның ярдәме, насыйбыннан дигән сүз. Әшгарийә мәзһәбе кайгы-хәсрәтне акылга беленмәс, ягъни хис-тойгылар – күңел эше, аңның куәте нәтиҗәсе түгел дип баралар. Матуридийә исә кайгы-хәсрәт, һәммә төрле хисләр акылга-аңга беленеп торуын таный.

«Мәликә китабы» бу мәсьәләләрне ачыктан-ачык язмый, ул аларны сорау-җавап хикмәтләренә яшерә. Бу исә әсәрнең мәгънәләре берничә катламлы булуы хакында сөйли. Язма халык әдәбияты форматы, аңлашылганча, авторга фәлсәфи-дини хакыйкатьләрне үз аңлавынча теркәргә мөмкинлек тудыра.

Сөнни мәзһәбенең нигезендә әшгарийә фәлсәфәсе ята. Сәләфийә дә, матуридийә дә – аның икесе ике канатын тәшкил итәләр. Әшгарилар, мәсәлән, пәйгамбәрлек өчен ир кеше булуны таләп итмиләр, ә матуридийә пәйгамбәрләр бары тик ир кешеләр арасыннан гына дип аңлатып бара. Мондый тәмам ачык карашларны «Мәликә китабы» бөтенләй кузгатмый, чөнки алар аның эчтәлеген ачык белдерер һәм әсәрнең бәддога төшүенә сәбәпче дә булыр иделәр. Матуридийә юнәлеше, сөнни мәзһәбенә карасa да, күп кенә яклары белән шигыйларның мөгътазилә юнәлешенә якын тора. Хәлиф Әл-Кадыйрның 1017 нче елгы махсус рескриптыннан соң моңа кадәрге кайбер фәлсәфи карашлары белән мөгътазилә юнәлешләренә якын торган, әмма үзенең аерымлыгын да саклаган һәм әшгарийә белән күп очракларда бер эзгә төшкән матуридийәнең дә эзәрлекләнүен төшенүе авыр түгел. Һәм менә 1041 нче елда хәлиф тарафыннан «Иман шарты» нәшер ителә һәм мөселман халыкларына таратыла. Менә шушы шартларда ислам дини фәлсәфәсе суфилыкка таба борыла һәм аның кысаларында үсәргә юллар эзли башлый. Аның нәтиҗәсендә суфичылык тарикатьләре формалашуга юл ала. «Мәликә китабы»нда суфичылык хакында суфилык хакында сүзләр кузгатылып та, әмма эчтәлегендә суфичылык тәэсиренең булмавы, дини карашларда матуридийә фәлсәфәсенә дә таянуы аның XI гасырның икенче яртысында иҗат ителүен ачык күрсәтә. Дөрес, аның халык тарафыннан еш күчерелеп, халык әдәбияты әсәре буларак яшәвен, телендә дә төрле чорларга хас тел үзенчәлекләре теркәлеп калуын, шул сәбәпле гыйбарәләрендә азмы-күпме үзгәрешләр барлыкка килергә мөмкинлеген истән чыгарырга

ярамый. Эчтәлеге белән ул халыкчан да, дини дә, фәлсәфи дә, мәгънәләргә дә бай.

Әсәрнең авторына килгәндә, Габделхәлим Төркестани икәнлегендә һичбер шик калырга тиеш түгел. Ни өчен? Сәбәбе – гади. Моның шулай икән аңлар өчен халык иҗатына, бигрәк тә дастаннарга игътибар итәргә кирәк. Аларда вакыйгаларны сөйләүче герой бар. Ул үзен әсәрдә хәтта берничә тапкыр атый, тормыш фактларын күреп торган, аларда катнашкан кеше буларак сурәтли, урыны белән геройларның берсе сыйфатында әсәрендә катнашып китә. Башка акын-җыраулар да дастанны халык алдында башкарганда һаман да аның исеменнән сөйлиләр. Безнең халыкта кабул ителгән кагыйдә бар: дастанның сүзен төшереп калдырырга ярамый, чөнки шул сәбәп аркасында гомереӊ кыскара. Ул ырым-ышану халык иҗаты әсәрләрен очраклы үзгәртелүләрдән саклаган. Бу кагыйдә язма әдәбиятка да сак мөнәсәбәтне тудырган. Шунлыктан әдәби текстларга авторыннан гайреләрнең төзәтмәләр кертүе бары тик аңлатма-искәрмәләр характерында юл читендә, хашияләрдә генә мөмкин булган. Әмма бу әле тарихи әһәмияткә ия әсәрләрне очраклы кыскартылулардан, җөмләләре, хәтта сәхифәләре төшеп калудан саклаган дигән сүз түгел. Кульязма китап та кешеләр язмышы белән яшәгән, орышларга алып барылган, укылган, янган, туракланган, ертылган, тузган. Ул хәл «Мәликә китабы»н да читләп үтмәгән. Аның кыскартылган урыннары автор үзгәртүе – редакциясенә карамый, күчерүчеләрнең саксызлыгыннан килгән.

Әсәрнең авторын билгеләгәндә дә эчтәлегенә хас фактик үзенчәлекләрне исәпкә алырга кирәк. Аның Габделхәлим Төркестани булуын Әбу-Габдулла Мөхәммәт ибне Исмәгыйль әт-Тәрази (1018 нче елда вафат санала) фәлсәфәсенең әсәрдә төп урыннарның берсен алуы ачык дәлилли. Моның өчен ел хисабына, тәнасух-реинкарнация идеяләренә бәйле фикерләренә, иман-гакыйдә мәсьәләсенә карашларына күз салу да җитә. Мөхәммәт Тәразины «Имам Һади» кушаматы белән атап йөрткәннәр, «Әнүштәкин», «Нәштәкин Дәрази», «Дәрази» дигән исемнәре дә булган. Аның Тәраз шәһәреннән булуын туган җиренә бәйле алган нисби исеме (Тәрази) күрсәтеп тора. Борынгы Тәраз шәһәре хәзерге Казахстан һәм Кыргызстан мәмләкәтләре арасында чик буенда, Талас елгасы ярына урнашкан. Аның борынгы диварлары һәм биналары хәзер дә исән. Гарәп гаскәрләре аны 893-нче елда яулый һәм халкы ислам динен ала. VIII–X гасырларда бу шәһәр Карлук ханлыгының иң алдынгы калаларыннан берсенә әверелә. 999-нчы елда аны Караханилар ханлыгы буйсындыра. 1220-нче елда Тәраз шәһәре монголларның көчле явына каршы тора, әмма басып алына һәм җимерелә. Монгол империясе чорында Чыгтай ханлыгы составына кертелә.

Шулай итеп, Мөхәммәт Тәрази чыгышы белән Карлук ханлыгыннан булган. Аның идеяләре «Мәликә китабы»нда урын алуы әсәрнең авторы белән бәйләнеше барлыгына ишарә итә. Әсәр авторы – Мәликәнең сорауларына җавап бирүче Габделхәлим Төркестани булуына да шик калмый. Автор-герой берлегенә борынгы әдәбияттан «Мәликә китабы» иң яхшы мисал. Әмма шунысы бар, X гасырда Төркестан шәһәре – Шауһәр, ә XII йөздә – Яссы исемнәре белән йөртелгән. Моның чыннан да шулай икәнлеген Әхмәт Яссәвинең (1091–1166), аның әтисе Ибраһим Яссының нисби исемнәренә бәйле дәлилләргә була. Әмма шунысы да бар, Ә.Яссәви үзе исә хикмәтләрендә Төркестан шәһәреннән булуын яза. Димәк, Шауһәр (Шаулы-шәһәр) дә, Яссы да зур бер Төркестан шәһәрен хасил итүче шәһәрчекләрнең исемнәре генә, һич кенә дә каланың үзе түгел. Чөнки Төркестан, шәһәр буларак, 639-нчы елга караган сөгъдийә документларында, «Туркланд» исеме белән скандинавия сагаларында искә алына. «Төркестани» нисби исеменнән дә Ә.Яссәви хәбәрдар булмый калмагандыр бит? Шуңа да үзенә «Яссы» имзасын алгандыр дияргә кала. Димәк, Габделхәлим Төркестани исемле шәхеснең XI гасырда яшәгән булуын фактлар нигезендә раслый алабыз.

Хезмәтебездә «Мәликә китабы»н татар халкының борынгы әдәби ядкәре буларак карадык. Тарихи яктан хакыйкатькә хилаф итмик дисәк, әсәр кыпчак халкыннан бүгенге көнгә килеп ирешкән мирас рәвешендә бәяләнергә тиешле. Бу әсәр бүгенге көнгә кадәр татар халкының рухи тәрбиясендә үз ролен башкарып килгән. Анда искә алынган хәбәрләр һәм тормыш хакыйкатьләре, дөньяга караш, дини-фәлсәфи күзаллаулар – алар һәммәсе дә, хәтта әшгарийә, матуридийә белән бергә Мөхәммәт Тәрази карашлары системасы да милли-дини аңыбызда, дөньяны күзаллауларыбызда һаман да яшәүләрен дәвам итәләр.

*(Тәмам)*
*(2013/2017)*

**Әдәбият**

Mehmet Yilmaz. Edebiyatimizda islami kaynakli Sőzlűk: Ansiklopedik Sőzlűk. Istanbul: Milliyat, 1991.

## Төбәк тарихына караган тарихи чыганаклар

## Исторические источники по краеведению

*Нефтяная деятельность Надыра Уразметова нашла отражение в ряде документов, а также в некоторых исторических трудах, издававшихся в России (в частности, в работе Петра-Симона Палласа, побывавшего на территории Надыровской волости в октябе 1768 г.). Ниже приводится один документ, связанный с изысканиями Надыра Уразметова*

### Описание нефтяных мест в дачах Надыра Уразметева геодезии ученика Павла Зубринского. 1756 года августа 21.

[ГАСвО. Ф. 115. Оп. 1. Д. 6. Л. 36 – 38].

*Описание учиненное по силе данного от 21 числа августа сего 1756 года наказа из Оренбургского горного началства в Оренбургской губернии в Уфимском уезде по Соке реке отисканным бывшим старшиною Надыром Уразметевым нефтяным местам и протчему.*

| Знаки дневныя | Числа | румбы | Часы осьмухи | Расстояние сажень | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 28 | | | | Месяц сентябрь<br>Прибыв на назначенное под завод место и где построен анбар, а оной анбар построен подле речки Камышлы по течению по левую сторону. По показанию отставного старшины Надыра Уразметева оной анбар построен на собственных их землях и от оного анбара поидено по инструменту со описанием от назначенного под завод места и от построенного анбара до имеющихся нефтяных мест в каком оные расстоянии состоят и от оного анбара вперед мер степью |
| | | МЕ | 7 | 300 | |
| | | | 7 2/8 | 1110 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 7 | 300 | |
| | | | 6 6/8 | 1050 | До речки называемой по татарски Зириклы, а по руски Елховки и перешли оную по течению на левую сторону, а оная речка впала в речку Большей Байтуган вниз с правой стороны и от оной речки вперед меры |
| | | | | 360 | |
| | | | 6 2/8 | 180 | |
| | | | 7 3/8 | 115 | До ключика, в котором нефть имеется; которой написан течет из лесу Чоктемиру, токмо оной ключ течет у степного места, а лес Чоктемир от оного ключа за речкою Большим Байтуганом по течению по левую сторону и во оном ключе имеется нефтяной признак, а довольствия никаковаго не имеется, кроме признаку, а оной ключ впал в речку Большей Байтуган вниз с правой стороны растоянием до устья оного ключа, где впал в вышеписанную речку Байтуган 150 сажень |
| | | | 1 2/8 | 150 | До речки Большаго Байтугану, оная впала в реку Сок вниз с правой стороны, а по левую сторону оной речки Байтугану лес называемой Чоктемир и от оной речки возвратились к вышеписанному анбару и от оного анбару вперед меры, а до устья речки Байтугану, где впала в реку Сок растоянием з 10 верст на SE 10 часов 4 осьмухи |
| ð | 29 | SE | 10 3/8 | 85 | До ключика и перешли оной по течению на левую сторону, а оной ключ впал в речку Камышлы по течению с левой стороны и от оного ключа вперед меры |
| | | | | 455 | До ключика и перешли оной по течению на левую сторону, а оной ключ впал в вышеписанную речку Камышлы с левой стороны и от оного ключа вперед меры |
| | | SE | 10 3/8 | 450 | |
| | | | 10 6/8 | 750 | |
| | | | 11 | 450 | |
| | | | 10 7/8 | 1590 | |
| | | | 10 3/8 | 810 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 10 2/8 | 480 | До деревни татарской называемой Камышлы, а оная стоит над речкою вышеписанной Камышлы по течению по левую сторону и от оной деревни вперед меры |
| ϰ | 30 | SE | 8 | 170 | До речки вышеписанной Камышлы и перешли оную по течению на правую сторону, а оная речка впала в реку Сок вниз с правой стороны растоянием до устья оной речки с 1 версту и от оной речки по дороге |
| | | | | 100 | |
| | | | 6 4/8 | 450 | |
| | | | 9 2/8 | 150 | До реки Соку и перешли оную по течению на левую сторону, а вышеписанная дорога осталась вправе, а подле реки Соку по правую сторону горы и от оной реки Соку вперед меры |
| | | | | 1530 | До ключика и перешли оной по течению на левую сторону, а оной ключ впал в реку Сок вниз с левой стороны и от оного ключика вперед меры |
| | | | | 300 | До озерка, а оное подле реки Соку по левую сторону вперед под оное озерко по левую сторону, а озерко и река Сок вправе |
| | | | | 180 | в конце сей меры вышеписанное озерко кончилось и осталось вправе и от оного озерка вперед меры |
| | | | 8 4/8 | 1530 | До ключика и перешли оной по течению на левую сторону, а оной ключ впал в реку Сок вниз с левой стороны и от оного ключика вперед меры |
| | | | | 630 | |
| | | | 8 6/8 | 1560 | До ключика, а оной впал в реку Сок с левой стороны и от оного ключика усмотрен румб МЕ 11 часов на деревню Ермакову, а оная стоит над ключиком близ реки Соку по левую сторону от сего растояния до помянутой деревни две версты триста пятьдесят сажень и от вышеписанного ключика вперед меры |
| ♂ | 1 | SE | 8 4/8 | 2930 | |
| | | | 8 6/8 | 1080 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 9 1/8 | 600 | До логу сухого и перешли оной на правую сторону, а оной впал в реку Сургут, оная ж и Кукорты, вниз с правой стороны растоянием до оной реки Сургуту в лево з 2 версты и от оного логу вперед меры |
| | | | | 1860 | До ключика и перешли оной по течению на правую сторону, а оной ключ впал в вышеписанную реку Сургут вниз с правой стороны и от оного ключа вперед меры |
| | | | | 1300 | |
| | | | 9 | 1200 | До вершины малых реки Сургута и перешли оную по течению на правую сторону и оныя вершины от сего растояния сошлись з большими вершинами влеве з 2 версты и от оных вершин вперед меры |
| | | | | 1500 | При конце сего растояния влево до реки Сургута з 2 версты |
| | | | 9 2/8 | 600 | До речки Кайраклы и перешли оную по течению на правую сторону, а оная речка впала в реку Сургут вниз с правой стороны растоянием до устья с 3 версты на SE 12 часов до вершины с версты на ME 11 часов 4 осьмухи над оной речкой деревня чювашская называемая Микушкина растоянием вправо до оной деревни с 6 верст и от оной речки вперед меры |
| | | | | 1680 | |
| | | | 9 3/8 | 600 | До горы называемой Молошной, а оная лежит влеве до реки Сургута и идено подле оную по правую сторону, а оная гора влеве и от оной вперед меры |
| | | | | 700 | До речки называемой по руски Молошной, а по татарски Аирен и перешли оную по течению на правую сторону, а оная речка впала в реку Сургут вниз с правой стороны растоянием до устья з 2 версты на ME 1 час, а до вершины с 7 верст на вершину румб ME 12 часов и от оной речки вперед меры |
| | | | | 1380 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| ♀ | 2 | SE | 9 3/8 | 870 | До речки Карамалы на которую просили позволения отставной старшина Надыр Уразметев к построению нефтяного завода, токмо на оной речке никаковаго строения не имеется, а оная речка впала из лесу называемого Шакмамая и не дойдя устьем до реки Сургута с одну с половиною версту и течением пресеклась, а лог впал в реку Сургут вниз с правой стороны и перешли оную по течению на правую сторону, а лес называемой Шакмамай начался вправе сначала сего растояния и от оной речки вперед меры подле лес Шакмамай по левую сторону вправе лес, а влеве степь |
| | | SE | 9 3/8 | 540 | До ключика и перешли оной по течению на правую сторону, а оной ключ впал в реку Сургут вниз с правой стороны и от оного ключа вперед меры |
| | | | | 1680 | |
| | | | 4 | 960 | |
| | | | 5 4/8 | 750 | До речки Карамалы и перешли оную по течению на правую сторону, а оная речка впала в реку Сургут вниз с правой стороны. На устье оной речки усмотрен румб SE 10 часов 4 осьмухи растоянием до устья 4 версты, на вершину усмотрен румб ME 11 часов растоянием с 4 версты и от оной речки вперед подле лес |
| | | | | 400 | |
| | | | 7 7/8 | 950 | |
| | | | 4 7/8 | 60 | До ключика, а оной впал в реку Сургут вниз с правой стороны и перешли оной по течению на правую сторону и от оного ключа вперет меры, а река Сургут осталась влеве |
| | | | | 550 | |
| | | | 3/8 | 250 | |
| | | ME | 11 | 1770 | |
| | | | 10 6/8 | 950 | |
| | | | 10 | 250 | При конце сего растояния лес Шакмамай вправе и оной кончился вперед степью |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 11 2/8 | 800 | До речки Ольховки и перешли оную по течению на правую сторону, а оная речка впала в реку Шумбут вниз с левой стороны и от оной речки вперед меры |
| | | | | 2190 | До деревни чюваша Якова Янгильдина, а оная стоит над рекою Шумбутом по течению по левую сторону и перешли оную реку Шумбут по течению на правую сторону, а оная река Шумбут впала в реку Сургут вниз с правой стороны. От сего растоянием усмотрен румб на устье вышеписанной реки Шумбута SE 7 часов 5 осьмух растоянием до устья оной реки Шумбута, где впала в реку Кукорты с 9 верст и от оной реки вперед меры |
| | | SE | 6 3/8 | 1020 | До горы Сартеата, оная ж исжареной бугор, и от оной вперед меры, а гора осталась вправе |
| | | | 4 3/8 | 970 | |
| | | | 4/8 | 80 | До озерка называемого нефтяного, токмо во оном нефти никакого признаку не имеется, а подле оное ж имеется другое озерко ж, токмо во оном вода белая, а нефти также не имеется и от оных возвратились в вышеписанную деревню Якова Янгильдина и от оной деревни вперед меры |
| 4 | 3 | ME | 3 4/8 | 540 | |
| | | | 3 7/8 | 240 | |
| | | | 3 6/8 | 300 | |
| | | | 5 7/8 | 330 | |
| | | | 6 6/8 | 180 | До деревни новокрещеных чюваш Тойтолы Иштулина сына, а оная стоит над речкой Башкиркой, а оная речка Башкирка впала в реку Шумбут по течению с левой стороны до устья оной речки, где впала в реку Шумбут от вышеписанной деревни с одну с половиною версту, а до вершины з две версты и перешли оную по течению на правую сторону и от оной деревни вперед меры |
| | | | | 140 | |
| | | | 11 3/8 | 540 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 11 | 850 | До речки Камышлы и перешли оную по течению на правую сторону, а оная речка впала в реку Шумбут вниз с левой стороны растоянием до устья с одну версту, а до вершины оной же речки с пять верст. На вершину усмотрен румб МЕ 8 часов 4 осьмухи и от речки вперед меры |
| | | | | 1350 | |
| | | | 10 | 1750 | |
| | | | 10 4/8 | 330 | До ключика и перешли оной по течению на правую сторону, а оной впал в реку Шумбут вниз с левой стороны и от оного ключа вперед меры |
| | | | | 2050 | До вершины реки Шумбута и оная кончилась |
| | | | | 350 | |
| | | SE | 1 5/8 | 330 | |
| | | ME | 10 2/8 | 1350 | |
| | | | 9 7/8 | 1120 | До деревни чюваш новокрещеных называемой Сапаровой, а оная стоит над каменным ключем, а оной ключ впал в реку Сок вниз с левой стороны растоянием до устья оного ключа с 5 верст на SE 1 час и от оной деревни вперед меры |
| ♀ | 4 | ME | 9 | 1200 | До ключика и перешли оной по течению на правую сторону, а оной ключ впал в реку Сок вниз с левой стороны и от оного ключа вперед меры |
| | | | | 600 | |
| | | | 9 6/8 | 200 | До реки Соку и перешли оную по течению на правую сторону и от оной вперед меры |
| | | | 12 | 600 | С начала сего растояние влеве подле реку Сок началось болото и простирается оное ниже устья речки Игар з 2 версты вперед подле оное болото |
| | | | 11 3/8 | 1000 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | SE | 5 2/8 | 70 | До речки Игаря и перешли оную по течению на правую сторону, а оная речка впала в реку Сок вниз с правой стороны растоянием до устья з 2½ версты на SE 10 часов, а до вершины на ME 9 часов 4 осьмухи с пятнатцать верст и от оной речки вперед меры |
| | | | | 100 | При конце сего растояния болото кончилось и осталось влеве и от оного болота вперед горами |
| | | | | 740 | |
| | | | 5 6/8 | 630 | До логу сухого, а оной впал в реку Сок вниз с правой стороны и от оного логу вперед меры |
| | | | | 270 | |
| | | | 6 4/8 | 570 | |
| | | | 7 3/8 | 780 | |
| | | | 7 5/8 | 270 | |
| | | | 8 5/8 | 360 | До речки Большей Усаклы и перешли оную по течению на правую сторону, а оная речка впала в реку Сок вниз с правой стороны растоянием до устья на ME 1 час 4 осьмухи с одну с половиною версту, а до вершины с восемь верст и от оной речки вперед меры |
| | | | | 180 | До речки малой Усаклы и перешли оную по течению на правую сторону, а оная впала в реку Сок вниз с правой стороны и от оной речки вперед меры |
| | | | 8 7/8 | 960 | |
| | | | 9 1/8 | 750 | |
| | | | 9 | 150 | До озерка называемого нефтяного, которое подле реки Соку по течению по правую сторону между речек выше Суршлы, а ниже Усаклы впадающих в Сок реку с право стороны, токмо во оном озерке нефти не имеется, а имеется подле оного в выкопанных маленких ямках, да и то толко один признак самое малое число и от оного озерка вперед меры |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | SE | 1 3/8 | 150 | |
| | | | 5 5/8 | 150 | |
| | | | 8 2/8 | 150 | |
| | | | 7 4/8 | 1400 | |
| | | | 8 | 270 | |
| | | | 10 4/8 | 450 | До речки Суршлы Большей и пойдено вперед подле оную по течению по левую сторону и против сего ж растояния с правой стороны в вышеписанную речку Большей Суршлы впала речка Малая Суршлы и от сего растояния вперед меры |
| | | ME | 5 6/8 | 350 | До реки Соку и до устья вышеписанной речки Суршлы, где впала в реку Сок вниз с правой стороны |

*Гөлназ Шәйхи*

## ПОЛЬША ТАТАРЛАРЫ

*Татар дөньясы бик бай. Без халкыбыз, узган юлыбыз, тарихыбыз, мәдәниятебез, әдәбиятыбыз, шәхесләребез белән хаклы рәвештә горурлана алабыз. Хәзер тасвирланачак сәфәрдән соң мин кабат нәкъ шул хисне кичердем. Әйдәгез, бергәләп Польшада гомер итүче татарларыбыз белән очрашырга, аралашырга сәяхәткә кузгалабыз. Баштан ук шуны җиткереп куясым килә, безнең барлык аралашуыбыз поляк һәм рус телендә барды. Әмма бу җирлектә гомер итүче татарларыбыз туган телне онытса да, ислам диненә тугры калган. Алар балага исем кушу, никах укыту, Ураза, Корбан гаете бәйрәмнәрен, мәет юуу, күмү кебек дини йолаларны саклаганнар.*

### Беренче көн

Сәфәребез маҗарадан башланды. Беренчедән, очкычыбыз Варшавага бер сәгатькә соңарып килде һәм Белостокка бара торган автобуска без өлгермәдек. Икенчедән, күчтәнәчләр салган багажым Казаннан Варшавага минем белән бергә килмәгән – адашып калган булып чыкты. Аны Мәскәүгә озатканнар. Юл йөргәндә төрле хәлләргә юлыгасың, бу беренче генә тапкыр булмаганга, күңелне төшермәдек, сәфәребезне дәвам иттек. Белосток шәһәренә ничек тә барып җитәргә кирәк, чөнки анда безне Мария Хазбиевич һәм аның гаиләсе көтә. Ә икенче көнне татар авылларына юл алырга исәп. Автобуска билет алып утырып китү, тел белмәсәк тә, әллә ни авыр булмады. Автобусы да уңайлы булып чыкты, WI-FI эшли. Рәхәтләнеп Интернетка кереп аралашып барырга була.

Варшавадан Белостокка кадәр безне яңгыр озата килде. Әмма күңелдә төшенкелек юк, Казандагы 30–35 градус эсселектән соң, мондагы 15 градуслы җылылыкта бераз хәл дә алдык кебек. Яңгырлы тәрәзә аша тирә-юньне күзәтеп барам. Юллары начар түгел. Шуңа да игътибар иттем, һәр торак пункттагы йорт түбәләрендә ләкләкләр өчен махус оялар куйганнар, алар үзләре ясаган оялар да күп. Түбәдә ләкләк булса, җир йөзендә тынычлыкка юрала бит. Амин, шулай булсын. Матур уйлар уй-

лап барып, 300 чакрымга якын юл узуыбыз сизелми дә калган... Без – Белостокта. Мария Хазбеевич безне үз туганнарыдай якын итеп каршы алды. Аның белән мин быел апрель аенда Чехиянең Брно шәһәрендә Европа татарлары Альянсының утырышы барышында танышкан идем. Ул чакта Польшадан килгән татар оешмасы вәкилләре андагы татар авыллары турында да мәгълүмат бирде. Менә шул очрашудан соң Бохоники һәм Крушиняны дигән татар авыллары һәм андагы татар эзләре белән якыннанрак танышу теләге туды.

Мария безне үзләренә дәште. Әйткәнемчә, Польшада яшәүче татарларыбыз татар телен белми, алар поляк телендә аралаша. Рус телен камил белгән Мария сәфәребез дәвамында тәрҗемәче булып та озатып йөрде, милләттәшләребез белән очрашуларыбызны да оештырды.

## Хазбиевичлар гаиләсе

Шулай итеп без Польшада гомер итүче татарлар Мария һәм Томаш Хазбиевичлар гаиләсендә. Томашның мулла кушкан татарча исеме – Тамерлан. Ул морзалар нәселеннән. Аларның туганнары профессор, Польша татарлары арасында бик тә танылган һәм хөрмәткә ия галим Сәлим Хәзбиевич бу нәселнең XV гасырдан башлап, шәҗәрәсен дә төзегән. Шәҗәрә башында Ушан* атлы бабайлары торган. Заманында князь Хәзбиевичларның үз герблары да булган. Аны да тарихи документларга нигезләп торгызганнар. Ул герб Тамерланнар гаиләсендә дә бар. Тамерланның әтисе Александр, әнисе Ләйлә исемле булган. Хәзер инде икесе дә мәрхүмнәр. Бохоники авылындагы татар зиратында җирләнгәннәр. Ләйлә ханымның тормыштагы бар максаты – улын татар кызына өйләндерү була. Ананың ул теләге тормышка аша. Бервакыт Сокулка шәһәрендә татарлар җыелып корбан ашы уздыралар. Монда тирә-күрше шәһәрләрдән, авыллардан да милләттәшләр җыела. Кунаклар арасында Белосток егете Тамерлан һәм Белорусиядән туганнарына кунакка килгән Мария дә була. Яшьләр бер күрешүдә бер-берсенә гашыйк булалар. Җиде айга якын аралашканнан соң, барлык туганнарны җыеп, никах укытып туй ясыйлар. Бу 1999-нчы ел була. Хәзер инде әлеге гаиләнең мәхәббәт җимешләре – ике уллары Давыт белән Арслан үсеп килә. Хазбиевичлар гаиләсендә татарлыкны саклый торган шактый мирас тупланган: дини китаплар, Польша татарларының тарихын чагылдырган елъязмалар... «Иң кадерлесе – 1907-нче елда нәшер ителгән Коръән китабы», – ди Тамерлан.

«Очраклы очраштык, Ходай кушуы буенча өйләнештек, әти-әнинең хәер-фатыйхасын алып яшибез», – диләр Томаш белән Мария бәхетле елмаеп. «Минем татар егетенә кияүгә чыгуыма әбиемнән дә ныграк шатлан-

* Татар кабиләсе «уйшын» атамасыннан алынган булса кирәк (Редакция)

ган кеше булмагандыр. Әнием башка милләт кешесе. Әби үстерде безне, абыем белән мине татар итеп, мөселман кешесе итеп тәрбияләде. Ул 103 яшендә, күптән түгел генә вафат булды. Мин әбиемне бик яраттым, әле дә аның белән бәйле матур хатирәләрне күңелемдә саклыйм. Без дә балаларыбыз, үзебезнең әби-бабайлар кебек үзләренең татар икәнлекләрен белеп үссеннәр өчен тырышабыз. Улыбыз Давытка хәзер 15 яшь. Татарча сөйләшергә, татар җырларын җырларга, татарча биергә өйрәнсен, халкыбызның йолаларын, гореф-гадәтләрен белсен дип без аны биш яшьтән үк якшәмбе татар мәктәбенә бирдек», – ди Мария. Давыт ут уйната торган егет булып үсеп килә. «Мин татар баласы. Шуның белән горурланам да. Татарча ныклап сөйләшергә өйрәнергә телим. Ансамбльгә йөрим. Анда татарча җырлыйм, биим. Кырым татар биюе «Кайтарма»ны яратам. «Ай, былбылым» җыры миңа бик ошый. Киләчәктә мин татар гаиләсе корырга телим. Интернет аша татар кызлары белән аралашам», – ди Давыт. Бер генә мәдәни чара да Хазбиевичлар гаиләсеннән башка узмый. Ә Давыт һәрвакыт үзәктә. Аның бар теләге Казанга килү, татар телен камил өйрәнү. Ул максатчан бала. Без аны Казанда көтәбез.

**Адамовичлар**

Сәяхәтебезнең беренче көнендә, соңгарак калсак та, без тагын бер гаилә – Ян һәм Джанетта Адамовичлар белән дә аралашырга өлгердек. Польшада 1925-нче елдан бирле төзелгән, 90 еллык тарихы булган оешмалар бар. Болар – Мөселман дини оешмасы һәм Польша татарлары җәмгыяте. Бу оешмалар тарафыннан татар мәдәнияте фестивальләре, төрле фәнни-гамәли конференцияләр уза икән. Ян әфәнде шушы Польша татарлары җәмгыяте белән алты ел җитәкчелек итә. Шунысын әйтеп китү урынлы булыр, Польша татарларының бер генә чарасы да Джанетта ханымның кул эшләреннән башка узмый. Ул шамаилләр, төрле матур милли бизәкләр чигә. «Польша татарлары, гомерләр узып, татар телен онытсалар да, милли гореф- гадәтләрне, йолаларны, татар ризыкларын олылап яши. Урамда узганда без – татарлар бер-беребезне таныйбыз, сәламлибез», – ди Джанетта ханым.

Ул безне үзе пешергән милли ризыгыбыз – алма ләвәше белән сыйлады.

**Литва – Польша татарларының кыскача тарихы**

Татарларны бик хөрмәт итәләр Польшада. Без моның шулай икәнен кем белән генә очрашсак, аралашсак, күрешсәк тә аңладык.

Тарихи мәгълүматлардан билгеле булганча, 1242–1256-нчы елларда Бату хан Көнчыгыш Европаны буйсындырып, татар йогынтысын Поль-

шада ныгыткан. Туктамыш хан һәм Нугай Урдасы әмире бәрелешләреннән соң Туктамыш гаскәренең бер өлеше Бөек Литва кенәзлегенә китәргә мәҗбүр булган. XV гасырда Литвада өч татар кенәзлеге: Мансур кенәзлеге, Җагалдай төмәнлеге һәм Курск төмәнлеге оеша. Грюнвальд сугышында татар гаскәре Җәләл-әд-Дин җитәкчелегендә катнашкан, гомуми литва-татар-славян җиңүендә хәлиткеч роль уйнаган. Витовт Грюнвальд сугышында татарларга, тугры булганнары өчен, Литвада җир алу хокукы һәм мәчетләр төзүгә рөхсәт бирә. Шул вакыттан башлап татарлар Литваның (1569-нчы елдан – Речь Посполита) чикләрен саклаганнар.

Польшадагы татар гаскәре 1683-нче елда Вена шәһәре янында сугышта катнаша. Җиңү яулый. Татар гаскәренең дәрәҗәсе югары була. 1667-нче елда Польша Сеймы татарларының дини иреклеген чикләргә тели, ләкин татар гаскәре бу дини чикләүләргә каршы Подолиядә баш күтәрә. 1679-нчы елда Польша Сеймы татарларга дин иреклеге һәм өстен хокукларын кире кайтарырга мәҗбүр була. Польша короле Ян III Собеский (1674-1696) Брест, Гродно, Кобрина шәһәрләре янында татарларга җир биргән. Менә шунда Крушиняны һәм Богоники дигән татар авыллары барлыкка килә.

300 елдан артык тарихны, татар эзләрен саклаган авыллар бүген дә яши. Дөрес, хәзер аларда татарлар күп түгел. Авыл саен 4-5 кенә йорт. Шулай да алар татарның йөзен, рухын, кыйбласын саклый.

Милләттәшләребез, аларның тормышлары белән якыннанрак танышу теләген тормышка ашыру өчен без икенче көнне Крушиняны авылына юл тоттык. Экскурсоводыбыз да, йөртүчебез дә, әлбәттә инде, Мария Хазбиевич. Ул машинада гел татар җырларын тыңлап йөри. «Сүзләрен аңламасам да, көе үзәккә үтеп керә. Башкалар җырын да тыңлап карыйм мин, алай түгел», – ди ул. Белостоктан Крушиняныга кадәр 50 чакрым юл.

## Крушиняны авылында

Татарча җыр, кирәкле мәгълүматны тыңлый-тыңлый берничә гасыр элек нигез салынган Крушиняны дигән татар авылына юл тотабыз. Экскурсоводыбыз да, йөртүчебез дә, әйткәнебезчә, бер кеше – Мария Хазбиевич. Аның машинасында татарча җыр тыңлый-тыңлый авылга барабыз. Көн матур, күңел күтәренке. Җирле татарлар белән очрашасы килү теләге дә көчле.

Менә без – Крушиняныда. Иң элек Польша татарларының Крушинянылдагы мөселман мәгарифе һәм мәдәнияте үзәгенә тукталдык. Безне әлеге үзәкнең җитәкчесе Бронислав Тальковский каршы алды һәм үзәкнең яшәеше, биредә башкарылган эшләр, гомумән биредәге татарлар тарихы белән таныштырды. Ул яңа бина төзелеше эшен башлап йөргән кеше. «Бу

эшне мин татарларым өчен эшлим. Биредә минем әби-бабайларым, әти-әнием күмелгән. Үзем монда тудым, оныкларым биредә. Туган авылымны яратам», – ди Бронислав Тальковский.

## Дини һәм мәдәни үзәк

Бронислав әфәнденең әйтүе буенча, үзәкнең җирләре бер гектардан артык мәйданны били. Искиткеч зәвык белән төзелгән әлеге бина яңа гына сафка басса да, туристларның мәхәббәтен яуларга өлгергән инде. 1000 квадратлы әлеге йорт үз эченә татарлар тарихын туплаган музейны, никах залын, мәдәни чаралар өчен махсус залны, кунакханәне, ритуаль хезмәтләр, намаз бүлмәсен сыйдырган. Бу бинаны төзергә Евросоюз, Польша хөкүмәте, Кувейт дәүләте финанс ярдәм күрсәткән. Субсидия хисабына төзелгәнгә, бирегә килгән кеше биш ел дәвамында музей белән бушка таныша ала. Туристларда бу җирлек, Польша татарлары тарихы белән кызыксыну көчле. Көнгә йөзләрчә кунак кабул итәләр биредә. Польшадан гына түгел, дөньяның төрле илләреннән киләләр. Иң зур кунак – британ шаһзадәсе Чарльз була. Польшага эшлекле сәфәре вакытында ул 38 миллион католик яшәгән илдә гасырлар буе мөселман мәхәлләсенең саклануын, аларның үз мәчетләрен тотуы белән танышасы килү максатыннан килә Крушиняныга. Җыйнак кына салынган агач мәчеттә булганнан соң, Британия принцын «Татар юртасы» ресторанына алып кереп, татар ашлары белән сыйлыйлар. Хуҗалар әйтүенә караганда, Чарльзнең күңеленә татар пәрәмәче хуш килгән.

Татар морзасы Бронислав Тальковский үзенең татар булуы белән горурлана. Ул нәсел тарихын яхшы белә, аны туплый, саклый. Тел онытылса да, татарлык, дин аларның күңел түрендә. Әкрен генә музей бүлмәсенә узам. Монда милләт рухы саклана кебек. Пыяла астындагы тарихи фотосурәтләргә күз салам. Баһадирдай татар ир-атлары, татар морзалары. Яннарында калфак кигән ханымнары, бала-чагалары. Күңелне ниндидер хис биләп ала. Аңлата алмыйм: ул үткәнне сагынумы, халкымның язмышы өчен сыкранумы, татарларның дөнья буйлап сибелүләренә рәнҗүме, күп кыерсытулардан соң да милләтебезнең сакланып калуына, батырлыгына горурланумы, белмим...

Икенче шкафларда – борынгы Коръәннәр. Иң борынгысы 1899-нчы елда нәшер ителгән. Араларында кулдан язылганнары да бар. Бу җирләрдә милли тормышта нинди вакыйга булуын вакытында көндәлек итеп терки барганнар: кем туган, кем вафат булган, кемгә исем кушканнар, никах туе үткәргәннәр... Барысын да яза барганнар. Бүген инде ул тарих елъязмалары. Моннан 100 еллар элек милләттәшебезнең хаҗга барган сандыгы да ядкарь урынында монда. Авыл мулласы булган Мостафа Ясин исемен белмәгән татар юк. Ул 103 яшенә кадәр яшәп, дини тәрбия

биреп, бик күп шәкертләрен калдырып 2015-нче елда вафат булган остаз. Аның шәхси әйберләре дә музейда бик кадерләп саклана.

Игътибарымны җәлеп иткән тагын бер әйберне атыйсым килә. Ул – милли киемнәр һәм татар сугышчыларының, офицерларының мундирлары, баш киемнәре. Сугышчыларның өс киемнәре якаларына татар икәнлекләрен аңлатып торсын өчен ай тамгасы төшерелгән була. Бу киемнәрне Варшавадан, дәүләт музееннан алганнар.

Әлеге үзәк бикләнми, аның каравылчысы да юк. Татарлар үзләре килеп карап, кадерләп саклап торалар.

## Авыл тарихы

Авыл табигатьнең матур урынында урнашкан. Әллә ни зур түгел. Нибарысы 160 хуҗалык. Шуларның бишесендә генә татарлар яши. Шулай да Крушиняны татар авылы исәпләнә, чөнки аңа XVII гасырда милләттәшләребез нигез салган.

Тарихы болайрак икән. Татарлар Речь Посполитаяда гаскәри катлау була. Безнекеләрнең җиңел атлы гаскәре кылган гамәлләре, батырлыклары белән бөтен Европада дан ала. 1683-нче елда Вена янындагы бәрелештә Польша армиясе төрекләргә каршы сугышта көндәшен җиңүгә ирешә. Монда татар гаскәре дә катнаша. Шул сугышта татар отряды командиры, полковник Самуель Мурза Кшечковский Польша короле Ян III Собескийның гомерен саклап кала. Шул хөрмәткә, шулай ук тугры хезмәтләре өчен король татарларга хәзерге Белорусия чикләреннән ерак булмаган, табигате белән бик матур булган уңдырышлы җирләрне бүләк итә. Татар сугышчылары яңа җирләргә килеп төпләнә. Әкренләп алар үзләренең яңа ватаннарына ияләнәләр. Бүген дә Крушиняны авылы халкы кайчандыр Кшечковскийның утары булган урынны хәтерендә саклый. Ул чорда үскән юкәләр килгән кунакларны бүген дә сәламли.

Иң беренче эш итеп алар агач мәчет төзетәләр. Өч гасырдан артык тарихлы мәчет хәзер инде хөкүмәт тарафыннан авылдагы төп архитектура объекты, тарихи һәйкәл булып санала. Бүген ул туристларның да яраткан урыны. Дөнья илләреннән мөселманнар бирегә хаҗга барган кебек күпләп агыла. Дүртпочмаклы, биек булмаган өч манаралы мәчеткә гыйбадәт кылырга ирләр дә, хатын-кызлар да килә ала. Хатын-кызлар өчен бүлеп куелган аерым бүлмә дә бар. Җәмил Гембицкий – мәчеттә экскурсияләр оештыручы. Ул безгә русча белән полякчаны бергә кушып, кыскача авыл тарихын да, мәчет тарихын да сөйләп чыкты. Польшада яшәүче кардәшләребез гарәп телен белмәсәләр дә, Коръәнне гарәпчә укыйлар, дип аңлатты безгә Җәмил.

Авылның тагын бер истәлекле урыны – мөселман зираты. Бирердәге татарлар аны мизар дип атый. Монда гарәп телендә язылган бик борынгы

кабер ташлары саклана. Барысы да Мәккә ягына каратып куелган. Бу мизарда бүгенге Польша татарларының әби-бабайлары, әти-әниләре. Монда яңа каберләр юк дәрәҗәсендә. Милләттәшләребез илнең кайсы почмагында гына вафат булса да, аларны Боһоники авылындагы мөселман зиратына – мизарга алып кайтып күмәләр икән.

## Татар юртасы

Дини һәм мәдәни үзәк каршында «Татар юрта»сы урнашкан. Аның хуҗабикәсе – Джэнетта Богданович. Бу ханым ачык йөзе, уңганлыгы, булганлыгы белән бу төбәктә генә түгел, ил күләмендә танылу алган кеше. Без дә Джэнеттаның кунакчыл ресторанына узабыз. Ул татарча «киенгән»: стеналарда бу гаиләнең борынгы фотолары, татар милли киемнәре, борынгы Коръән китаплары. Бу шәхси әйберләр килгән кешеләргә үткәнне күзалларга һәм татар мәдәнияте белән танышырга ярдәм итә. Ә кеше күп биредә, ресторан гөжләп тора. Тәмле ризык, хуш исле үлән чәе исе борынны кытыклый. Богдановичлар гаиләсе Крушиняныда авыл туризмын булдырганнар. Туристлар Крушиняна авылына килеп Джэнетта һәм аның кызлары әзерләгән татар милли ризыкларыннан да авыз итәләр, татарларның яшәешләре белән дә танышалар. Теләсәләр кунып та кала алалар. 16 кешелек кунакханәләре дә бар аларның.

Нинди генә татар ризыклары әзерләнми ресторанда! Бәлеш, токмачлы аш, ит пәрәмәче, өчпочмак, чәк-чәк кебек милли ризыклар белән сыйлыйлар туристларны кызлар. Ә менә перекачевник – гадәт буенча Рамазан аенда әзерләнә торган иң популяр милли ризык. Ул бик юка, үтә күренмәле камырга төрле эчлек салып әзерләнә. Эчлеге баллы эремчек, йөзем, кара җимеш яки сарык, бозау, каз яки күркә ите булырга мөмкин. Эчлек салынган камырны рулет формасында төреп табадага салалар да, ике сәгать мичтә пешерәләр икән. Бик тәмле! Без дә авыз итеп карадык. Әйтелгәнчә, Британия принцы Чарльз да тәмләп караган бу затлы ризыкны, бик канәгать калган, рәхмәтен дә әйткән. Перекачевник – Евросоюз билгесен алып, каталогларга кертелгән милли ризык.

Милли ризыклар пешерү белән Джэнетта 12 ел шөгыльләнә. Бу эшнең тарихы болайрак. Моннан 30 еллар элек туризм өлкәсендәге белгеч буларак Джэнетта Польша, Белоруссия чикләрендәге хуторлар, бәләкәй авыллар буйлап экскурсияләр оештыра. Нәкъ шул чорда ул Крушиняны авылына да килә. Польшаның төньяк-көнчыгышындагы гади, тыныч җирдә утырган бу авыл үзенең зөбәрҗәт мәчете белән игътибарын җәлеп итә. Кызның күңелендә бу яртылаш онытылган мирасны уятучы, яктыртучы маяк булып кабына. Шул ук сәфәрендә ул урман йота барган татар зиратында – мизарда булып, мүк белән капланган кабер ташларын күреп, аның ата-бабаларыныкы икәнен дә аңлый. «Бу минем тормышым-

ны, дөньяга карашымны үзгәрткән көн булды. Мизарда басып торганда ата-бабаларның җан авазын ишеткәндәй булдым. Беренче тапкыр үзем турында татар кызы бит мин дип уйладым. Мин бу җиргә кабат кайтырга тиеш, дидем», – ди Джэнетта. Бу вакытта кызга егерме яшь була. Кире Белостокка кайтып укуын дәвам итә ул. Шул шәһәрдә үзенең булачак ирен, Крушиняны авылы егете (!) Мирекны очратып гаилә дә корып җибәрәләр. Әлеге авыл килене буларак үзенең экскурсия маршрутларына Джэнетта Крушиняны авылын да кертә башлый. Соңыннан Богдановичлар гаиләсе кайчандыр Польша короле Ян III Собеский биргән җирне, бабалары нигезенә яңа сулыш бирәләр. Крушиняныга килгән туристларга ял итәргә, тамак ялгап алырга бернинди дә шарт булмый. Татарча кунакчыллык күрсәтеп, үзләренең йортларында туристларга утырып ял итәргә эскәмия, чәй эчәргә, ашап алырга өстәлләр куялар. Иң башта ук алар кунакларга милли татар ашлары тәкъдим итәләр. Бу хәзерге «Татар юрта»сының беренче адымнары була. Вакытлар узу белән Богдановичлар өч кызлары: Тамира, Эльвира, Җәмилә белән бергәләп йортларын яңарталар, үзләре икенче катта яши башлыйлар, ә беренче катта килгән кунакларны кабул итәләр. 2003-нче елдан ныклап төп нигезгә кайтып төпләнәләр. Туризм сезоны Крушиняныда яздан көзгә кадәр дәвам итә.

«Кухняда әни җитәкче. Барысын да ул үзе пешерә. Без булышабыз. Милли ашларның рецептларын әниебез Польша буйлап барлык татар гаиләләреннән җыйды. Алар хәзер бер китап чыгарырлык. Барысы да татар милли ашлары. Мин ул тәмле әйберләрне балачакта ук мөселман бәйрәмнәрендә ашаганымны хәтерлим», – ди Джэнетта белән Мирекның кызлары Җәмилә. «Минем хатынымны барысы да ярата, хөрмәт итә. Ул әзерләгән ризыкларны тәмләп, яратып ашыйлар. Мин моңа куанам гына. Эшебез уртак. 15 гектар җиребез бар: ресторан өчен кирәкле барлык җиләк-җимеш, яшелчәләрне үзебез үстерәбез. 6 баш атыбыз бар. Килгән туристлар кызыксынсалар, атта да йөри алалар. Бу безнең өчен бик кадерле бабайларыбыз җире. Без аны сакларга, буыннан буынга тапшырырга тиеш», – ди Мирек. Бүген алар бергәләп гаилә бизнесын да гөрләтәләр, әби-бабай рухын да ныгыталар, киләчәк буынга үрнәк булырлык гамәлләр дә кылалар, Польша татарлары тарихын да саклыйлар.

Мирек белән Джэнетта, аларның кызлары, кияүләре, ике оныклары – Әмир белән Миа безгә татарның Мәккәсе дип саналган Казанга сәлам әйтергә кушып озатып калдылар.

### Мәдәни тормыш

Крушиняны авылының башка авыллардан аерылып тора торган тагын бер үзенчәлекле матур ягы бар. Богдановичлар гаиләсе ярдәмендә биредә

мөселман бәйрәмнәре һәм мәдәни фестивальләр яңарыш кичерә. Татар мәдәниятен торгызу өчен даими чараларның кирәклеген Джэнетта яхшы аңлый. Моннан дистә еллар элек беренче тапкыр ул авылда Польша татарлары гореф-гадәтләрен торгызу максатыннан фестиваль оештыра. Ул фестиваль татарча җырлар, биюләр, милли ризык әзерләү, кул эшләреннән күргәзмә оештыру, атта йөрү, уктан ату кебек төрле юнәлешне колачлый. Халыкның кызыксынуы артканын күрә, сизә Джэнетта. «Крушиняныга кабат тормыш, туганлык рухы кайтты. Күпләр кайчандыр мин 30 ел элек ишеткән җан авазын тойды. Күбесенең ата-баба туфрагына кайтасы килү теләге көчәйде», – ди ул.

Ун ел элек Джэнеттаның теләге, ярдәме белән биредә беренче тапкыр Сабантуй бәйрәме узган. Дистә ел дәвамында милли бәйрәмебез борынгы Крушиняны авылында гөрли. Соңгы елларда бәйрәм Татарстан ярдәме белән баетыла. Казаннан килгән сәнгать осталары бу җирләрдә гомер итүче халкыбызга милли җыр-моңнарыбызны тапшыра. Әлбәттә, бәйрәмнең үзәгендә 16 еллык тарихы булган Польша татарларының «Бунчук» ансамбле. Бунчук – аңлатулары буенча Польша татарлары сугышчылары байрагы була. Бу ансамбльгә 5 яшьтән алып 55 яшькәчә барлыгы егермеләп кеше йөри. Алар татар халык җырларын да үз репертуарларына алганнар, татар биюләрен дә бииләр. «Безнең максатыбыз үз җырларыбызны, үз биюләребезне саклап, туплап, өйрәнеп башкаларга да җиткерү. 600 елдан артык Польшада гомер иткән татарларыбыз туган телне хәтерләми. Без татарларыбызга татар теленең аһәңен дә ишеттерергә телибез», – диләр «Бунчук» ансамбленә йөрүчеләр.

2013-нче елның 2 сентябрендә бер төркем татарлар «Польша татарлары мәдәни-иҗтимагый Фонд»ын оештыра. Алар арасында Эва Якубович, Роза Хазбиевич, Адам Якубовский, Мария Хазбиевич һәм башка милләтпәрвәр татарларыбыз бар. Әле оешып киткәннәренә күп вакыт узмаса да, Фондның башкарган эшләре байтак. Алар Польша хөкүмәтенә проектлар тапшырып грандлар оталар. 2014–2016-нчы елларга татарларга кагылышлы мәгълүматлар туплап календарь чыгарганнар. Шулай ук мәгариф юнәлешендә дә эш алып баралар. Мәктәпләрдә, гимназияләрдә татар тарихы буенча дәресләр, татар ризыкларын әзерләү, уктан ату, татар биюләре буенча мастер-класслар уздыралар икән. Вокал буенча да проектлары бар аларның. Давид Хазбиевич, Александра Якубовская, Жанетта Хазбиевичларның татарча башкарган җырларыннан диск та әзерләгәннәр. Шулай ук халкыбызның тарихына, мәдәниятенә кагылышлы материаллардан, танылган шәхесләре белән әңгәмәләрдән торган «Татар сандугачы» дигән журнал да нәшер итә башлаганннар. Бүген бу Фонд белән Роза Хазбиевич җитәкчелек итә. Алар шулай ук милли киемнәр

дә тегәләр, татар курчаклары да ясыйлар. «Польшада татарлар азая бара. Ләкин без югалырга тиеш түгел. Үзебезне саклау, яклау безнең эшебез булырга тиеш», – ди Фонд әгъзасы Адам Якубовский.

Менә шулай, татарларыбыз белән аралашып, уй-фикерләрен ишетеп, истә калырлык мизгелләр белән очрашып кайттык без Крушиняны авылыннан. Килгән һәркемне алар татарларга хас кунакчыллык, якты йөз, сый-хөрмәт белән каршы алачаклар. Польша татарларының үткәне, бүгенгесе белән очрашасыгыз килсә, татар эзләре буйлап Крушиняныга барыгыз.

## Боһоники авылы

Боһоники авылы да Белостоктан 50 чакрым ераклыкта. Ул Польшаның Соколка районында урнашкан ике татар авылының берсе. Бу авылга да нәкъ менә Крушиняны авылы белән бер чорда нигез салына. Боһоники зур авыл түгел. Бүгенге көндә авылда 30 йорт бар, шуларның дүртесендә генә татарлар яши. Тагын 4 гаилә йорт сала башлаган. Яшьләр ата-бабалары җиренә кайта. 2006-нчы елда авылда 100 кеше яшәсә, шуның 14е татарлар.

Бу авылның да горурлыгы – татарлар төзегән мәчет. Иң беренче итеп без мәчеткә уздык. Туристлар шактый. Аларга экскурсияне, соңыннан таныштык, Евгения Радкевич үткәрә иде. Боһоники мәчете тарихи чыганакларда 1717-нче елда ук телгә алына. Ул авылның көнчыгышында, мөселман зираты – мизар янында урнашкан. Польшадагы актив биш мәчетнең берсе. Икенче Бөтендөнья сугышы елларында мәчет фашистлар тарафыннан җимерелә һәм кыр госпитале булып хезмәт итә. 1945-нче елдан соң ул төзекләндерелә. 2005-нче елда Боһоники мәчете тулысынча реставрацияләнә. 2012-нче елның 22 октябрендә ул Польша тарихы һәйкәле дип игълан ителә.

Авылда мизарлар икәү. Аның беренчесенә инде вафат булганнарны күммиләр. Ул борынгы каберстан. Яңасына, инде алда язып үткәнемчә, татарларны илнең төрле җирләреннән ата-баба туфрагына алып кайтып җирлиләр.

Боһоники авылында да туристларны бик җылы кабул итәләр. Туристик сезон авылда майдан августкача бара. Монда туристлар мөселман бәйрәмнәрендә – Рамазан, Корбан, Гашура көне, Мәүлид бәйрәмендә катнаша, татар милли ризыкларыннан авыз итә ала.

Авыл, мәчет тарихы белән таныштырган Евгения ханымның колагында татар алкасы. Башында түбәтәй. Минем яулыгыма күзе төште дә, үзен дә татарчалап яулык ябарга өйрәтүемне сорады. «Мин моннан соң гел шулай яулыктан, аны татарча итеп бәйләп йөриячәкмен», – диде ул.

«Балаларым да, оныкларым да ата-баба җирен ярата, хөрмәтли. Авылда төпләнәселәре килә. Яңа төзелеп килүче йортлар аларныкы», – дип горурланып та алды ул.

Боһоники авылы җирлеге башлыгы Матвей Шеснович та авылы, татарлыгы белән горурлана. Крушиняныдагы кебек милли ризыклар пешерә торган ашханә ачу да бар аның хыялында. Дөрес, бу борынгы җиргә аяк баскан туристлар үләнле хуш исле чәйдән, милли татар ризыкларыннан биредә дә авыз итә ала. Шулай ук туристлар өчен кул эшләреннән милли сувенерлар эшләп сатуны да оештырырга теләкләре бар. Теләк булса, Ходай ярдәменнән ташламас.

Польшада узган сәяхәтебезнең һәр мизгеле гаҗәпләнү, горурлану хисләре белән катыш булды. Без «татарларыбыз» дип мактанып та, горурланып та кайттык. Башка җирләрдәге кебек төрле милләт халыклары да хөрмәтлиләр кардәшләребезне. Башкарган эшләре, кылган гамәлләре уңышлы булсын.

*Казан–Белосток–Крушиняны–Боһоники–Казан.*

## Ирек мәйданы: бәхәс клубы

## Площадь свободы: дискуссионный клуб

*Фанис Набиуллин*

### ТРАВМЫ НАРОДА

Травмы народа, травмы человека… Согласно существующему принципу аналогий или соответствий, любое системное правило действует или проявляется в любых системах неким единым – подобным образом, тем самым подтверждая организованность, структурированность, как во времени и в содержании, так и в форме всей Вселенной, функционирующей по принципу саморегуляции. Сказанное выше относится и к любым человеческим системам и сообществам: будь-то страна, государство, наполненное людьми или любой этнос, отличающийся от других рядом определённых признаков.

Каждая травма или рана имеют свою глубину, свою локальность. Каждый болевой симптом опосредованно, через различные психические символы-смыслы, привязан к конкретному органу или участку тела. Психосоматические связи в коммуникациях «человек–болезнь» сегодня для многих бесспорны. Существо же человека многомерно и многосложно. Для немногих будут понятными выражения «групповая душа», «родовая совесть», «родовое поле» или «безусловное право принадлежности к роду-народу». Существует ли условное «тело» рода или народа? Если да, то как оно влияет на нас? Через совесть? А если его у человека мало? Может ли быть травмирован целый народ? Как излечить эти травмы? Если мы сможем ответить на эти вопросы, мы сможем выработать какие-то первичные этапные стратегии, обозначить конкретные шаги их реализации.

Прежде всего, травмы и раны сопровождаются болью, несут те или иные страдания. Как и тело, человеческую психику можно травмировать. Это представление сложно опровергнуть, в то же время оно не особо распространено и, тем более, осознано. По сегодняшний день много людей причиняют другим людям психическую боль, наносят душевные раны, но они не желают признавать, что тем самым проявляют свою низкую нравственную культуру, вульгарность или слабую психическую устойчивость, очевидное непонимание эволюционных процессов и своего места в них. Любые травмы являются порождением внутренних или внешних

конфликтов. Даже травма потери близкого человека является следствием внутреннего, психически более сложного конфликта, порождённого неготовностью, несогласием с «преждевременным» уходом, с потерей важной, значимой фигуры. При этом в эволюционирующей природе нет понятия «преждевременности», всё происходит своевременно в рамках природных закономерностей, в соответствии с принципом причины и следствия.

Локальные конфликты при неправильном или несвоевременном анализе, при неверной интерпретации могут выливаться в более масштабные конфликты – войны. И необходимо признать, что любая война не только убивает и калечит людей, но и наносит серьёзный вред душам выживших, людям телесно целым и невредимым. Война, как большой конфликт, не только формирует ряды жертв «здесь и теперь», но и оставляет, продолжает нести свой след во многих последующих поколениях, не позволяя жить полноценно. Последствиями влияния войны на психику людей бывают поражены не только потомки жертв, но и потомки насильников. С точки зрения человеческой души после войны, большой или малой, не бывает победителей, есть одни поражённые.

С развитием человечества, совершенствованием отношений, к сожалению, «совершенствуются» и методы борьбы и соперничества. Недостойные, манипулятивные разрушительные стратегии и цели, нарушая принципы полносоставности, вуалируются под благовидные внешние лозунги. В грандиозных масштабах происходит дезориентирование, зомбирование и деградирование человеческих масс. Одни группы искусно противопоставляются другим группам, формируется неприязнь, отторжение, превосходство одних над другими, как-будто столетиями и по нынешний день, какая-то невежественная сила через эмоциональную вовлечённость, страх управляет неорганизованным человечеством. При этом в невидимых и неосознаваемых мирским человеком исторических хрониках нашей планеты фиксируются все экстремумы, весь опыт, к которому можно приложить такие критерии, как осознанный или неосознанный, с позиции уроков, как освоенные или неосвоенные. И великий зодчий, высший архитектор, не вмешиваясь явно в процесс обучения, через свои физические и психические законы, через боль и страдания незримо регулирует и утверждает свои эволюционные задачи.

Войны и по сей день продолжают жить среди нас: информационные, технологические, политические, экономические, войны этнические, религиозные, внутрисемейные… и, наконец, войны в сознании самого человека. В итоге, нередко человек перестаёт быть цельной натурой, самим собой. Он теряет своё назначение, у него меняются цели, он мельчает. У

человека нынешней эпохи нарушилось, исказилось мировосприятие. Это очень важный критерий – Миропонимание. Этот критерий должен находиться на достойной высоте, особенно в период смены эпох и укладов. Мало кто знает, что змея, скидывая старую омертвевшую мешающую кожу, слепнет. В этот период она становится особенно уязвимой. Так и человеческое сообщество, человеческие группы в переходные, сложные периоды теряют ориентиры, цели, так как меняется среда, а они упускают из виду скрытые, но неизменные ценности. И нет смысла пенять на обстоятельства, обстоятельства – лишь необходимые препятствия для роста духа личности, слагающего свой народ.

Процесс сложения народа пробуждающимися личностями имеет свою уникальность. Этот процесс подобен процессу пробуждения в нас божественной силы, когда мы побуждаем всё своё существо населить и проявлять все истинные добродетели в наших мыслях и поступках. И лишь тогда, когда мы признаём своё место в семье, в роду, в своём народе, в семье народов, т.е. в самой жизни, лучшим образом, из глубины источника или резервуара Жизни нам предоставляется многогранный накопленный всеми предыдущими поколениями опыт, который как нельзя лучше позволяет сформировать нашу безопасность и безопасность будущих жизней.

Опыт – это то, что важно уметь аккумулировать, сохранять, уметь им пользоваться, а ещё и уметь передавать. И если продолжать игнорировать свою принадлежность (принадлежности) в каждой неожиданной ситуации заново будет изобретаться велосипед и то тем самым проявляться невежество по отношению к мудрой Природе. Как следствие, мудрая Природа закрывает свои информационные и ресурсные кладовые, включает болевые механизмы в целях обучения невежественных.

Обучение всему всегда происходило от малого к большому. Согласие на присутствие и гармоничную самореализацию соседствующих народов достойным приложимым образом может происходить на основе базовых уроков согласия со своими родителями, братьями и сёстрами, такими, какие они есть. Не принявший кровного брата, данного свыше, может попадать в иллюзию приятия соседствующего этноса, публично величая его братским народом. Но лишь время и сами жизненные испытания выявляют цельность, прочность и надёжность слов. И это – проблема планетарного масштаба, прежде всего, проблема России со множеством населяющих её народов.

И те, кто находится на верхнем ярусе экономической иерархии, на уровне материально-политического превосходства, в реальности не способны решить и решать эти вопросы, потому что за долиной Знания

в глобальной вселенской школе для многих следует недосягаемая долина Раскаяния (Аль-Газали, «О 7 долинах человеческого сознания»). Долина Знания формирует в человеке или его группе (сообществе) иллюзию особенности, исключительности, избранности, даёт право на научное, техническое, экономическое, военное или иное превосходство. Однако, лишь знающие процессы развития рас и подрас, вникающие в процессы трансформации и трансмутации человеческих групп в глобальных масштабах времени могут понимать, почему во вселенской школе эго-превосходство должно быть опущено на уровень боли и потерь, на уровень условного «унижения». При этом «униженность» – это лишь внутреннее состояние индивида или его группы, это непонимание процесса сменяемости спада и подъёма. Абсолютная реальность не ведает унижения. И поэтому осиленный путь в долине Раскаяния, обильно оплодотворённый болью потерь, позволяет обрести иной, обогащённый опытом вид Знания.

Сегодня специалисты-системщики, изучающие динамику развития семейно-родовых систем, наблюдают, что за поколениями агрессоров-насильников следуют поколения жертв, а из поколения жертв вновь возрождаются поколения «восстановителей справедливости». Совершенно закономерным в семейных кланах выглядят процессы, когда дети на любом из временных этапов не могут удержать, бездарно «спускают сквозь пальцы», добро родителей, полученное путём различных политических и экономических манипуляций в период своей конъюнктурной фаворы.

Разбирая вопросы о травмах и конфликтах народов, необходимо затронуть понятие о порядке или порядках. Вселенский принцип, трактующий о том, что всегда существовал и будет существовать некий порядок явлений, событий, законов и вещей даже в относительно изменяющемся мире, позволяет нам заявить следующее. Много проблем возникает из-за того, что человек считает, что он может взять верх над порядком, используя различные ресурсы: силу, количество, время, логические умозаключения или любые иные усилия. На самом деле порядок является заданным принципом, на котором всё построено, и его невозможно чем-либо заменить, даже любовью. Любовь может лишь помочь восстановить порядок. Решая любые глобальные и малые вопросы, нужно понять: необходимо возвращаться к порядку, к точке истины. Только так можно найти решение.

Чтобы быть последовательным и продуктивным в изложении своей мысли, думаю, важным будет ввести такой термин, как Урок. Слепой не увидит уроков в практике каждого дня. Поэтому не видать ему и роста. В одной из своих статей я описывал процесс взаимодействия личной и

родовой совести – личное вплетено в общее, и общее незримо и независимо от расстояний, влияет на личное, если личное недооценивает задачи общего. Но и общее меняется под влиянием личного: в одних случаях общее разбавляется, теряет силу, свой статус, в других – собирает силу, поддерживает личное. Судьба человека – судьба народа, судьба народа – судьба человека.

Существует интересное выражение – «Родовой урок», это о том, как бессознательное (Природой всё осознано!), неосвоенное одним поколением, передаётся дальше потомкам (трансгенерирует – науч.термин) и может многократно повторяться в тех или иных формах, но с очевидным смысловым уроком. Могут повторяться даты, имена, территории, события, как бы наталкивая на переосмысление, переработку и иной подход.

Соответственно, несложно догадаться, что существуют и уроки для народа и народов. И травма, боль, болезнь как нельзя лучше заставляют нас обратить на это внимание.

У каждого народа есть свои непройденные уроки: и у татарского, и у чеченского, и у русского, и у китайского, и у еврейского… Абсолютно свободных от уроков народов нет. Те, которые заявляют о себе, что они в этом плане особенны, остаются вне решения проблем. Есть особенности в каждом народе, и всё лучшее каждого народа предназначено для общего, для семьи народов, для всего человечества. Таково предназначение планетарной колыбели для всего живого, для всего сущего. Плавильный котёл подразумевает доведение всего содержимого до однородной однотипной массы. Но у мудрой Природы, у Высшего Архитектора нет такой задачи. Индивидуальность должна быть сохранена. И любой, действующий вопреки, в будущем обречён, и это обречение он возлагает на потомков. Если внимательно изучать судьбы тысяч родовых систем, то заключение «Дети отвечают за поступки родителей», неоспоримо и непререкаемо. Человек, проявляющий насилие над другими людьми, закладывает в своих потомков элементы жертв и внутренний конфликт. Народ, подавляющий другие народы, медленно, но верно толкает своих потомков к будущей подавленности и страданиям.

*(Продолжение следует)*

## Шәхесләребез

## Известные личности

*Фәрит Фаткуллин*

# ЛИДЕРЛАР КАРТЛЫККА БИРЕШМИ
## Филология фәннәре докторы, профессор Рәиф Әмировка – 75 яшь

Педагог, язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе, филология фәннәре докторы, профессор, Халыкара югары уку йортлары академиясе әгъзасы... Республикабызның рухият өлкәсендә ярты гасырдан артык фидакарь эшләгән бу шәхесне берничә буын укытучылар, журналистлар, әдипләр, галимнәр ихлас остаз буларак хөрмәт итә. Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе, Халыкара Кол Гали исемендәге һәм мари халкының Яныш Ялкайн исемендәге премияләре лауреаты рәсми хакимият тарафыннан да, иҗтимагый җәмәгатьчелектә дә киң танылу яулады. Башы яңадан-яңа идеяләр белән тулы, һәрчак каядыр ашыгучы, җитез хәрәкәтле Рәиф Кадим улының шундый яшьтә булуына ышанасы да килми. Ә чәчләре... Алар яшь чакта ук чалланган иде.

Аның турында мин беренче тапкыр язучы Сәгыйть Агишның, 1974-нче елда булса кирәк, «Агыйдел» журналындагы әңгәмәсеннән белдем. «Әле генә минем янда Рәиф Әмиров дигән яшь галим булып китте. Бөре педагогия институтында эшләгән, күптән түгел Уфага күчкән икән. Кыюлыгы, яңалыкка омтылуы белән бик ошады ул миңа. Әдәбият гыйлеменә шундый яшь талантлар килүе шатландыра», – дип язган «башкорт прозасы Чеховы».

Әлеге мәкаләне язар алдыннан Рәиф Кадим улы белән сөйләшкәндә шушы фактны искә төшергәч, ул да хатирәләргә бирелде:

– 1967 ел. Мәскәүдә Н. К. Крупская исемендәге педагогия институты аспирантурасында укуым тәмамлану алдында тора иде. СССР язучылар съездына ничектер эләктем. Фойеда, бер як читтә, Сәгыйть ага таягын тукылдатып йөренеп тора. Кәефсез. «Борис Пастернак китабын саттылар, миңа җитмәде», – ди. Аның делегат мандатын алдым да киттем. «Бу нихәл ул? Карачай-Черкес республикасы язучылары бөтенләй Пастернаксыз калган», – дидем Кавказ халыклары акценты белән. «Сезгә ничәү кирәк»? – ди сатучы ханым. Аңа да, үземә дә алдым.

Бөредә эшлим. Шуңа игътибар итәм – биографияләре буенча язучыларыбыз барысы да... ярлы крестьян, батрак балалары, имеш. Гамәлдә бит алай түгел, аларның күпләре эти-әниләренең сәүдәгәр, эшкуар, дин әһеле булганлыгын яшергән. Шуларны дөресләп белешмә чыгарасы килә. Социаль чыгышларын дөрес күрсәтүләрен сорап, язучыларга 100 хат җибәрдем. Берсеннән дә җавап юк.



Ул арада Уфага эшкә күчтем. Хатларым артыннан һәркемнең өенә барырга булдым. Сәгыйть агадан башладым. Мәскәүдәге кыска вакытлы очрашуга байтак еллар үтсә дә ул мине шундук таныды. «Теге заманнар кире кайтмагае, дип куркалар», – дип аңлатты каләмдәшләренең минем мөрәҗәгатькә дәшми калуларын.

Башкорт совет очеркы буенча якланган диссертациям өстендә ничек эшләвемне бик кызыксынып тыңлады. 1920-нче елларда гарәп им-

ласында чыккан китапларны карт кешеләрдән укытырга мәҗбүр идек. Мәскәүдә шундый бер өлкән милләттәшебез миңа Мөхетдин Корбангалиевның гарәп имласына өйрәтү китабын бирде. Чынлап та бер атнадан мин инде үзем укый башладым. Сәгыйть ага минем бу гамәлемне бик ошатты – теге интервьюда да шул хакта телгә ала...

Рәиф Әмировка 2018-нче елның 3 ноябрендә 75 яшь тулды. Бу көн аның тормышында өч вакыйга белән билгеләнә. Дөньяга килгән көн. Бу вакытта яшь әти – колхоз тракторчысы Кадим өч ай инде фронтта дошманнарга каршы көрәшә; яшь ана Җәмигага, зур гына хуҗалыкны алып бару белән бергә, туганнарыннан калган ике кечкенә сабые турында хәстәрлек күрү дә йөкләтелгән. Тагын да өч елдан нәкъ шушы көнне Кадим солдатның һәлак булуы хакында «кара кәгазь»гә кул куела. Мәрхүмнең бердәнбер улы 1972-нче елда әтисенең ерак Лиепая шәһәрендәге (Латвия) каберен барып таба. Һәм янә килеп, 3 ноябрьдә Рәифнең тәүге улы Марсель туган.

Әтисен бервакытта да күрмичә, аның сөекле хатынын һәм баласын яратучы, кешелекле һәм кыю образын фронт хатлары, туган-тумачаларның сөйләве буенча гына күз алдына китереп үскән Рәиф балачакта тимер юлчы булырга хыяллана. Ләкин бу хыял өлкәннәрнең, яшь бала әллә кая китеп югалыр дип куркып, аның документларын яшереп куюлары аркасында җимерелә. Бу хәл җиденче сыйныфтан соң була. Тормышка ашмаган хыял урынын токарь булу теләге били. Үзе кебек үсмер белән Уфа янындагы Ново-Александровка бистәсендә урнашкан 4-нче һөнәрчелек училищесына юл тота. Киләләр, барлык укучыларның да акбурга буялып беткән кара комбинезонда йөргәнлеген күрәләр. Шуларның берсе болар янына килә: «Малайлар, сез кайдан?». «Балтач районыннан». «Ничек укыдыгыз?» «Дүртле»гә, «бишле»гә. «Сез монда укырга кермәгез! Минем кебек «өчле» капчыкларына башкача барыр урын юк. Бер ел укыйм инде – токарь станогын якыннан күргәнем юк. Кара эштә көннәребез үтә».

Балтачлылар кире борыла. «Әни бит мине укытучы итеп күрәсе килә. Аның сүзен тыңларга кирәк шул», – дип уйланып кайта Рәиф. Хәер, алтынчы сыйныфта язма эштә үзе дә «Мөгаен, мин әдәбият укытучысы булырмын», дип язган.

Мәшһүр Батыршаның туган авылы Югары Карыш урта мәктәбен тәмамлагач, Рәиф Әмиров Бөре педагогия институтының филология факультетында укый. Студент чагында ук әдәбият кафедрасына эшкә алына, сабакташларына урыс, совет, чит ил әдәбиятлары буенча дәресләр бирә. 1962 елда матбугатта тәүге язмасы дөнья күрә – А. Солженицынның «Иван Денисовичның бер көне» повесте буенча студентлар конфе-

ренциясе үтүе турында мәкалә була ул. Солженицынның иҗаты җиде кат йозак астына алынганнан соң да аның әсәрләрен уку әмәлен таба. Рәиф Кадим улы бу уңайдан кызыклы хәлләрне искә төшерә: «Мәскәүдәге Ленин исемендәге китапханәдә аспирантлар тыелган әсәрләрне шундагы уку залында ук укый иде. Яшерен рәвештә үзнәшер ысулы белән басылган аерым битләр теләсә кем үрелеп алырлык киштәләрдә тезелеп торган Ленин томнары эчендә саклана. Ленин томын аласың да... Солженицынны укыйсың һәм урынына куясың. Китапханәчеләр бу турыда белсәләр дә күз йомганнардыр. Шунысы да кызыклы: аспирантлар нинди әсәрнең яки китапның рәхимсезлеккә тарыячагын алдан сизгәннәрдер кебек. Юрий Некричның «1941 ел, 22 июнь» китабын укып та өлгердек, аны тыйдылар да».

Хәтер янә студент елларына әйләнеп кайта. Рәиф Әмиров анда укудан, укытудан, комсомол эшләреннән һәм спорттан тыш та үзенә төрле шөгыльләр таба. Җәмәгать эшләре аша сәясәткә дә кереп киткәли. Гаделлекне, хакыйкатьне яклап чыгышлар ясарга да туры килә. Бервакыт студентларга «югарыдан» Двосья Львовна Соркина дигән укытучының дәресләренә йөрүдән баш тартырга, аңа каршы сөйләргә «тәкъдим итәләр». «Бер көн элек кенә зачеткаңа беренче һәм бердәнбер булган «өчле» куйды шушы начар укытучы, син аңа каршы эндәшми калырга тиеш түгелсең», – дип Рәифне дә котырталар. Ләкин ул җыелышта укытучыны яклап чыгыш ясый:

– «Өчле» алуымда мин үзем гаепле. Двосья Львовнага рәхмәтлемен, чөнки ул миндәге ялкаулыкны ачыклады, ялкаулык белән ерак китеп булмаячагын тагын бер тапкыр аңлатты.

Менә шундый гадел студентлар саклап кала укытучыны. Дөрес, соңрак аңа барыбер китәргә туры килә. Рәиф белән аның дусларча мөнәсәбәте озак еллар саклана.

Студентларны кирәкмәгән ыгы-зыгыларга җәлеп итү очраклары да булгалап тора. Мәсәлән, үзләре белән килешеп тә тормыйча, аларны Сталин урамының исемен Интернациональгә үзгәртүне таләп итүчеләр исәбенә кертергә телиләр. Монда да каршы чыгучы студентларның башында Әмиров тора. Аңлашыла ки, каршылык күрсәтүчеләрнең бу гамәле Сталинны яратудан түгел, үзләре белән исәпләшмәү аларның ачуын кузгата.

Рәиф Әмиров институттан соң Бөре районындагы бер мәктәптә бер ел эшләп ала. Ә инде Нуриман районындагы данлыклы яугир Ришат Исмәгыйлев җитәкчелек иткән Байгилде урта мәктәбендә директорның уку-укыту эшләре буенча урынбасары вазыйфасында үткән бер елны ул әлегәчә үзенең төп тормыш университетларының берсе дип исәпли. Мәк-

тәптә, авылда, колхозда ул искиткеч яхшы кешеләр белән очраша, аларның күпләре гомерлек дус булып кала.

Бу вакытта инде ул үзе кебек филолог Олия Нурулла кызы белән тормыш кора, Марсель исемле ул үстерәләр. Алгарак китеп әйткәндә, Әмировларның өч баласы – уллары Марсель, кызлары Динара, Гөлнара да табиб һөнәрен сайлаган.

Югарыда телгә алынганча, Рәиф Әмиров 1965–67-нче елларда Мәскәүдә аспирантура үтә. 1968-нче елда «Башкорт совет очеркы. 1917–41 еллар» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Шул ук елдан башлап Бөре дәүләт педагогия институтында өлкән укытучы, доцент булып эшли. Бөре картиналар галереясына нигез сала, җәмәгать башлангычында аның тәүге директоры эшен алып бара. Вуздагы мәдәният университеты ректоры буларак, студентларны урындагы шартларны исәпкә алып эстетик яктан тәрбияләү системасын эшләү һәм гамәлгә ашыру авторларының берсе булып таныла. «Яшьлек» татар-башкорт әдәби-иҗат берләшмәсен оештырып, әдәби фестивальләр үткәрүне җайга сала. Ул заманда «Яшьлек», гомумән, Бөре шәһәре, республиканың Уфадан соң икенче әдәби үзәгенә әверелеп ала, дисәк тә ялгыш булмастыр. Очрашуларга нинди генә язучылар, шагыйрьләр килми! Олы талант ияләре Әмир Мәхмүтов, Марис Нәзировлар нәкъ менә шушында иҗат канатларын ныгыта. Яшь доцент моннан тыш күренекле башкорт язучысы Һәдия Дәүләтшинаның тормыш юлын өйрәнүне, әсәрләрен халыкка тулырак җиткерүне оештыручыларның берсе дә.

Бу вакытта Рәиф Әмировка – тулар-тулмас 32 яшь. Тормыш баскычларына күз салсаң, авыл мәктәпләрендә эшләү аны мөстәкыйльлеккә, гап-гади кешеләр хәленә керә белергә өйрәткән, аспирантура киң әдәби һәм фәнни офыклар ачкан, Бөредә эшләү аны вуз укытучысы һәм җәмәгать эшлеклесе итеп формалаштырган.

Аңа проректор вазыйфасын тәкъдим итәләр. Ләкин ул аннан баш тартып, Башкортстан дәүләт педагогия институтында доцент булып эшен дәвам итүне өстен күрә. Бу – 1974-нче ел. Беренче курска кабул ителгәннәр арасында Әлшәй районыннан Рәүф Хәкимов дигән ут бөрчәсе кебек егет тә була. Әле ул – күренекле журналист, атказанган матбугат һәм киңкүләм мәгълүмат хезмәткәре, Шаһит Ходайбирдин исемендәге премия лауреаты. Укытучысы һәм остазы турында болай дип сөйли:

– Бәхетебезгә, Рәиф Кадим улы группабызның кураторы итеп билгеләнде. «Үзе артыннан яшьләрне ияртүче лидер, гыйлемле, кечелекле шәхес менә нинди була икән!» – дип сокландык без аңа тәүге көннәрдән үк. Бер ай гына укый идек әле. Бервакыт төркемебезне җыйды да Салават һәйкәле янына алып китте. «Бүген Рәүфкә – 18 яшь!» дип мине калкурак

урынга бастырды һәм шигырь сөйләргә кушты. Икенче бервакыт теплоходка төялешеп Кызыл Яр авылындагы Чапаев музеена юл тоттык. Кураторыбыз үзенең кечкенә өч баласын да иярткән иде. Әле алар белән, әле безнең белән мәш килеп, безгә ул эти кешенең үз сабыйларына мөнәсәбәт сабаклары да бирде.

Сентябрьдә үк татарча һәм башкортча иҗат итүче студентлар өчен «Тамчылар» әдәби берләшмәсе оештырды. Тәүге утырышка мин берүзем генә килгәнмен булып чыкты. Рәиф Кадим улы һич иренмичә сәгать буе минем шигырьләргә җентекле анализ ясады. Икенче утырышка Нур Шәфыйков, Әдһәм Әскаров дигән каләм тибрәтүчеләр килде. «Аңа әле озак кына укыйсы бар», – дип укытучыбыз мине берләшмәнең старостасы итеп билгеләде. «Иҗаттан беркайчан да туктамагыз», – дип безгә хикәя, новелла, шигырьләр язарга задание бирде. Ватман кәгазьләрен бер-берсенә ялгап, 5 метр озынлыкта стена гәзите чыгара башладык. Күптиражлы «Учитель» гәзите дә шигырьләребезгә урын бирде. «Тамчылар» елгага әверелде, биредә Әхмәр Үтәбаев, Инсур Шәңгәрәев кебек язучы-шагыйрьләр үсеп чыкты...

Рәиф Әмировның 1986-нчы елда яклаган докторлык диссертациясе «Башкорт әдәбиятында әдәби-публицистик жанрлар. Формалашуы һәм үсеше. XVI–XX гасырлар» дип атала. Биредә ул беренчеләрдән чәчәннәр, абызлар иҗатын халык фикерен чагылдыручы шәхесләр буларак тикшерә. Алар җитди гыйльми ачыш дип бәяләнә.

– Башкортның тарихы да, әдәбияты да публицистик характерда, – дип фәнни хезмәтенә кыскача гына анализ бирә аның авторы. – Хөкүмәткә халык исеменнән хатны гадәттә чәчәннәр, абызлар язган. Аларда чагучы образлар, фикерләр ялтырап калган. Мәхәббәт турында шигырьләр, җырлар тәэсир көчен арттыру өчен сүз уңаенда гына язылган.

Рәиф Әмиров хәзер М. Акмулла исемен йөртүче педагогия югары уку йортында 40 елга якын хезмәт салды. 1987-нче елда аңа профессор дәрәҗәсе бирелә. Доцент, факультет деканы, кафедра мөдире була. 1981-нче елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителә, берлекнең очерк һәм публицистика, тәнкыйть советлары, Башкортстан Язучылар берлеге идарәсе, «Агыйдел», «Русский язык в башкирской школе» журналларының мөхәрририят әгъзасы булып тора.

Егермеләп монография, уку әсбабы, 300 чамасы мәкалә һәм рецензия авторы. Хезмәтләре республикадан тыш Русия, СССР, чит илләр матбугатында басыла. Башкорт прозасы буенча Мәскәүдә һәм Уфада чыккан әдәби җыентыкларны төзүче.

Республика Язучылар берлегенең очерклар һәм публицистика секциясе рәисе буларак, Рәиф Әмиров 1980-90-нчы елларда әдип сүзенең

абруен күтәрүдә күп эшли. Аның башлангычы белән «Башкорт тарихи прозасы: табышлар һәм перспективалар», «Башкорт әдәбиятында һәм публицистикасында үзгәртеп кору һәм тарихи тема», «Республиканың гыйльми потенциалы һәм үзгәртеп коруда аның урыны» дигән темаларга «түгәрәк өстәл»ләр оештырыла. Экология темасына күчмә утырышлар язучы публицистларның һөнәри дәрәҗәсен күтәрергә, республиканың тарихының һәм хәзерге хәленең мөһим темаларын эшкәртергә булышлык итә. Ә инде «Су чисталыгын саклыйк», «Республикабыз урманнары: алар ни белән авырый?», «Икътисад һәм экология» темаларына «түгәрәк өстәл»ләр барган урын күпмедер вакытка республиканың үзенчәлекле бер «яшелләр хәрәкәте» үзәгенә әверелә.

Профессор Әхәт Нигъмәтуллин бер чыгышында Рәиф Әмировны Акмулла, Сергей Аксаков, Николай Крашенинников традицияләрен дәвам итүче, ягъни татар, башкорт, урыс, мари әдәбиятлары арасындагы дуслык, хезмәттәшлек, йола бәйләнешләрен фәнни тикшеренүче, гамәли пропагандалаучы дип телгә алган иде. Аның бу гамәлләре педагогик, гыйльми, әдәби һәм җәмәгать эшчәнлегендә төп юнәлеш булып тора. Күп кенә шәхесләрнең исемнәрен мәңгеләштерүдә, хезмәтләрен халыкка билгеле итүдә зур хезмәт салды һәм сала. Бу җәһәттән иң беренче булып мәшһүр райондашы Батыршаны телгә алырга кирәк. Мишкә районында туып-үскән ике күренекле зат – мәгърифәтче Васфи Гыйльмияров, фольклорчы, шагыйрь Яныш Ялкайн исемнәре нәкъ менә Рәиф Кадим улы фидакарьлеге белән безгә кайтты. Аларның тәүгесе белән ул Бөредә чакта шәхсән аралашкан, истәлекләрен дә яздырып калдырган һәм соңыннан күләмле документаль әсәр иҗат иткән. Мари халкының данлыклы улы Яныш Ялкайн исемендәге премия булдыру артыннан йөреп, кирәкле документларны эшләде. Нәтиҗәдә Мишкә һәм Калтасы район хакимиятләре бу премияне гамәлгә куялар.

Рәиф Әмировның тормышында җәмәгать эшләре зур урын биләве турында әйтә биреп куйган идем. Ул эшләр рәсмиләре белән шулкадәр бәйләнгән ки, тәүгеләре кайда тәмамланып, икенчеләре кайда башланганын да белер хәл юк. Һәм хикмәт монда бу шәхеснең ташып торган энергиясендә, хыял-омтылышларында гына түгел. Читләрнең кайгы-хәсрәтен дә ул йөрәгенә якын ала.

Сиксәненче еллар уртасында, СССР-ның башка халыкларындагы кебек, татарларда да милли хәрәкәт кузгала. Һәм Рәиф Әмиров аның лидерларының берсенә әверелә.

– Башкортстанда ул дәвердә Кәрим Яушев җитәкчелегендәге Татар иҗтимагый үзәге үзен реаль сәяси көч итеп танытты, югары даирәләр дә аның белән исәпләшә иде, – дип хатирәләргә бирелде Рәиф Кадим

улы. – «Азатлык» татар яшьләре берлеге, Морзалар мәҗлесе, Татар теле язучылар берлеге, «Ак калфак» һәм башка оешмалар аерым-аерым хәрәкәт итәләр, әмма кайбер мәсьәләләрдә фикер аерымлыклары килеп чыккалый, шуларны килештерергә, берләштерергә кирәк иде. Республика җитәкчелеге Башкортстан татарлары съезды үткәрергә карар итте, аңа әзерлек комиссиясе рәисе итеп Дәүләт җыелышы-Корылтайның Вәкилләр палатасы рәисе Миңнерәис Ишморатов билгеләнде, «Азатлык»тан Заһир Хәкимов белән мин аның ярдәмчеләре булдык. Съездның көн тәртибе, каралачак мәсьәләләр, проектлар әзерләп атна-ун көн иртәдән кичкә кадәр утырдык.

Бөтендөнья татар конгрессының барлык 5 съездында да делегат, тәүге ике чакырылышта идарә әгъзасы, шулай ук Башкортстан татарларының барлык 4 съездында да делегат һәм мәдәният-әдәбият комиссиясе рәисе булдым.

Казандагы беренче съезд вакытында республикабыз вәкилләре Риза Магазовны, Мадриль Гафуровны, Рәүф Хәсәновны һәм мине Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев кабул итте. Икенче көнне Шәймиевның киңәшчесе Рафаил Хәкимов, Кәрим Яушев һәм мин, төн буе утырып, Татарстан белән Башкортстанның мәдәният-мәгърифәт өлкәсендәге килешү проектын төзедек. Әйтергә кирәк, безнең шундагы күп кенә пунктлар соңрак ике республика арасындагы гомум килешүгә дә керде.

Бөтенрусия «Мәгариф» фондының Башкортстан буенча бүлеген оештырдык, аңа «Мәгърифәт» дип исем куштык. Спонсорлар табып, хәтта сәүдә белән шөгыльләнеп, иң тәүдә татар теле-әдәбияты укытучылары өчен методик әсбаплар, арытаба татарча, урысча шигырь, проза китаплары нәшер иттек. «Мәгърифәт»тә авыл укучыларын югары уку йортларына (беренче чиратта педагогия, медицина, авыл хуҗалыгы) керергә әзерләү курслары оештырдык, алар берничә ел эшләп килде...

Рәиф Кадим улы Әмиров – халкыбызның, милләтебезнең кайнар патриоты. Туган районына, авылына да бихисап изге гамәлләр кылган шәхес ул. Балтач районындагы Начара авылы мәктәпле, утлы, сулы булган икән, монда аның да тырышлыгы зур. Әле дә ул якташлары мәнфәгатен кайгыртучы проектларны гамәлгә ашыру артыннан йөри.

* * *

Рәиф агага исәнлек-саулык, бәхет һәм тыныч тормыш теләп кала «Туган җир. Родной край» журналы редакциясе.

**Татар рухы**

**Татарский дух**

*Руслан Айсин*

## ИСТОРИЯ ОДНОГО ПРЕДАТЕЛЬСТВА

Роман Гузель Яхиной «Зулейха открывает глаза» наделал много шума. Автор получила уже не одну награду, премии, признание. Но и критики хватает. Причём, критика вполне обоснованная и аргументированная.

Приступая к чтению романа, я уже имел общее представление о содержании этого повествования. Но рецензий умышленно не читал, дабы не смазывать собственное представление, чтобы моё восприятие было по возможности интимным, без примеси, если можно так выразиться, синдрома навязанного суждения. Уже после я прочитал пару рецензий, где были изложены, проверены, высвечены основные фактологические недочёты в романе, несоответствия исторической действительности, парадигмальные надломы повествования и т. д.

Особенно большую работу в этом плане провела М. Хабутдинова, которая по пунктам разобрала основные ошибки Гузель Яхиной в романе. Поэтому я не буду детально останавливаться на этом, а постараюсь обозначить, в чём же идеологический пафос сюжета, что двигало Яхину при написании этого по сути клеветнического на татарскую жизнь, на традиционный национальный уклад, на Ислам романа.

Я не буду политкорректен, оговорюсь сразу, так как сам роман неполиткорректен.

Этот роман не о любви, как может показаться кому-то на первый взгляд, и не о женской судьбе. Это роман об истории одного предательства. Роман о том, как ничтожен человек, лишившийся духовного измерения и подлинных корней!

Гузель Яхина создала своё пространство, где разрывается гомогенное поле татарского мировоззрения, идентичности, ткань иероистории. Они для неё не имеют особого сакрального смысла, не звучат прекрасной мелодией в сердце. Это всё она готова демонтировать.

Роман, как пишут «молодой татарской писательницы» (только вот в чём её татарскость, чем она заслужила статус называться «татарской писательницей»? У индусов есть такое понятие «хиндутва» – индусскость,

которое определяет, по каким критериям стоит считать человека индусом. Это же большая честь именоваться летописцем жизни, трагедии, переживаний, миросозерцания целого народа!), – это, конечно же, ода «безродному космополитизму» (уж, простите, за нарочитое использование терминов советской эпохи, так ведь роман тоже живописует картину тех лет).

Видимо, годы работы в пиар-агентстве Москвы наложили свой неизгладимый отпечаток на восприятии Гузель Яхиной. Она понимает все нюансы манипуляции, где и за какие рычаги нужно дёргать, какой несущий блок стоить убрать в основании коллективного бессознательного. Уж мы то знаем, как тамошние умельцы орудуют технологией чёрного пиара. «Очернить? Пожалуйста! Только заплатите вон в то окошечко!».

Долгие годы интеллектуального кружения в московско-либеральных кругах, где идейными попутчиками выступали всевозможные феминистки со смещённой оптикой восприятия – это тот ресурс и опыт, который Гузель Яхина перенесла в замысел романа.

Многие промоутеры Гузель Яхиной, даже не читавшие самого романа, полны восторга и восхищения: «Это прорыв, это про татар». В чём прорыв? В изящном навете на татарский традиционный уклад? Почему десятки блестящих романов талантливых татарских писателей не были столь восторженно встречены «знающей» публикой и властьимущими? Отчего такой непонятный интерес к Зулейхе? Не потому ли, что она вывернула историю наизнанку и выставила татар в неприглядном свете?

Роман готовы перевести на двадцать четыре языка мира. Одномоментно. С трудом верится в такое единовременное желание представителей двадцати четырёх национальностей рассказать своим соплеменникам о Зулейхе. Я не верю в такой «энтузиазм масс». За этим романом стоит чья-то мощная спина.

Роман, бесспорно, имеет идеологический окрас. Не в смысле того, что он ругает «красных в пользу белых» или наоборот. Гузель Яхина наносит точечные удары по узловым символам татарского народа. И это самое важное! Если убрать сюжетную надстройку романа, то перед нами ледяным торосом предстанет идеологический исполин, который с циничной и холодной расчётливостью выполняет своё дело по ментальному демонтажу символических и психосоматических основ татарского народа. Это своего рода роман Кочетова «Чего же ты хочешь?». Только написан более грамотно, тонко, местами провокативно и демонстративно шокирующе.

Конечно, она не пыталась показать лагерную жизнь людей 30-х годов прошлого века. И вряд ли при всём её таланте у неё бы это получилось. Для этого надо быть в этом, окунуть голову в холодной поток ужасного

бытия ГУЛАГов. Это удалось Варламу Шаламову, человеку, который провёл в ужасных сталинских лагерях 20 лет, но так и не был сломлен. Его «Колымские рассказы» – это голая фактология зверств режима, которая заставляет стучать сердце в ритме тех, кто стал жертвой преступлений «Вождя всех народов». И ты понимаешь: тут правда, мучительно-горькая, изматывающая душевные силы правда, а вот «Зулейха открывает глаза» – это неправда. И неправда не только потому, что там много несоответствий, ошибок, что сам сюжет ломанный, негладкий, а потому, что ты уже знаешь априори, изначально, ещё до того, как увидел цитату Улицкой на обложке книги – «Мощное произведение, прославляющее любовь и нежность в аду», что Яхина не может быть той, кто способен описывать драму татарского народа. Потому что это она не принадлежит к его культурно-духовному кругу.

Можно предположить, что через образ Зулейхи Яхина психологически оправдывает саму себя. Зулейха родилась татаркой, но так ей и не стала по-настоящему. Её образ соткан из сплошных противоречий, сомнений, разных лоскутов, содранных из плесневелых и заскорузлых одежд. Она, конечно же, не может рассуждать в идеологических терминах либерального мировосприятия о необходимости свободы, любви – она же «забитая» селянка! Но её внутренние импульсы – это такие волевые позывы, отсылающие нас к французским энциклопедистам, для которых человек, природа и есть основные силовые линии мироздания. Через наивное язычество Зулейхи Яхина и пытается продать нам эту мысль. Её Зулейха стихийная космополитка, но зажатая тисками национальной ретроградной традиции, семьи, религии. Муж Муртаза – тиран, безмолвный символ инерции.

Тут мы подходим к первому персонажу. Муртаза – это, без сомнения, на пару с его матерью, которую Зулейха издевательски называет Упыриха (столетняя слепая женщина), указание на сам татарский народ: патриархальный, могучий, но для женского восприятия грубый, замкнутый, находящий утешение лишь у матери своей. Тут Яхина наносит ещё один ощутимый удар по символам. Два столпа любого традиционного общества: мать – хранительница уклада и муж – воин-добытчик – предельно унижены Яхиной. Это делается сознательно, она их намеренно высмеивает, «опускает». Такая ненависть к патриархально-суровому принципу встречается у либерально-консюмеристской публики, которая не понимает, что есть вертикаль, а не только горизонт.

Муртаза, несмотря на свою монументальность и грозный вид, по сути лишь маменькин сынок. Мальчик-с-пальчик, от которого Зулейха понесла четыре раза, и все родившиеся на свет девочки умерли в самом младен-

честве. То есть Муртаза «неправильный» он не может зачать наследника мужчину, продолжателя рода. Впрочем, в итоге он родит наследника, но так и не узнает об этом. Наследника Юзуфа, который, по замыслу Яхиной, олицетворяет полную противоположность его отца – тонкий, отзывчивый, склонный к прекрасному, творчеству. Муртаза укоренённый в почве, Юзуф же – рождён вдали от родины, лишён связующей нити с корневищем, да и не рефлексирует на этот счёт. Он мечтает уехать, его ничто не связывает с магнетизмом почвы, и в итоге он устремляется в Ленинград.

Муртазу убивает чекист Игнатов, который становится впоследствии возлюбленным Зулейхи. Нет в книге сильных переживаний «безутешной вдовы». Да, умер, её осмысление этого факта – лишь сожаление об утрате привычного.

Игнатов со своими подчинёнными конвоирует татарских кулаков в Казань. И тут автор вводит в ткань сюжета один эпизод. По пути колонна арестованных останавливается в одном селе, где их для ночёвки размещают в мечети. И там этот самый Игнатов начинает совокупляться со своей сослуживицей Настасьей прямо в мечети… Для чего Яхина заостряет внимание на этом? Чтобы показать Игнатова полной антитезой Муртазе, который «не пропускал ни одном джумы»? Или чтобы ещё более отвратить читателя от этого чекиста, для которого нет ничего святого? Но тогда отвращение должна вызвать и сама Зулейха, прыгнувшая к этому извергу в кровать. Но нет, Яхина старательно обеляет её образ, рисуя её очень благовоспитанной, стесняющейся чужого мужского взгляда.

Игнатов типичный представитель того озлобленного поколения, которое прорвалось к власти, не гнушаясь ни чем для утверждения своего видения мира. Именно они сделали возможным массовой террор 1930-х годов. Они были церберами режима, покорно и услужливо выполняя их преступные приказы. Иван Игнатов развратник-убийца — вот кого полюбила «кроткая» Зулейха.

Важный эпизод связан с родами Зулейхи, которые принимает «коллега» по несчастью – Лейбе. Он, как нам сообщает Яхина, немец, профессор Казанского университета, светила науки, который был теоретиком медицины и практикующим хирургом, но его всегда увлекала гинекология (не будем здесь развивать тему фрейдизма, оставим этот аспект для специалистов). Лейбе страдает много лет необъяснимой болезнью. Он погружён в эскапизм, в вымышленный мир, его голову покрывает некий пузырь, который защищает его от суровой действительности внешнего мира. Он живёт в своём мире грёз, где всегда солнце и праздник. И вот он принимает роды, и эта слизь на голове мешает ему, противится тому,

чтобы он вытащил из утробы Зулейхи новую жизнь. В итоге он делает волевое решение, раз и навсегда отбрасывает этот кокон эскапизма со своих плеч.

Тут Яхина использует достаточно простой приём: Юзуф выступает как обновитель, как пульсирующий акт освобождения не только для Зулейхи, но и для больного Лейбе, долго мучившегося от непонятного состояния, то ли психологического, то ли физиологического. В какой-то момент кажется, что Яхина сорвётся в аллегоризм, в Евангелические сказания о Иисусе, который общался с людьми в яслях… Да и подобранная пара Юзуф-Зулейха тоже должны указывать подсознанию об известной притче о двух влюбленных – Юсуфе (пророке) и Зулейхе. Должны придать двум персонажам книги сакрально-святой ареол носителей образа чистой, божественной любви, переливающейся эфиром благодати через все мыслимые границы и преграды. Юзуф – это пророк обновления, утверждающий своим появлением новую эпоху.

Поселение, куда ссылают кулаков и прочий идеологически вредный элемент, это своеобразный полигон человечества, покинутый остров, где уживаются представители разных народов: чуваши, мари, татары, русские, северные народности, немцы, но нет, что удивительно, евреев! (может, цензоры не захотели, чтобы евреи присутствовали в этой фабрике по выращиванию нового Человека, евреи-то никогда не откажутся от своей национальной и религиозной идентичности). И вот в этой природной среде (вспомним вновь Руссо) вырастает новый человек – Юзуф, всечеловек, который интегрирует в себе все ипостаси универсального индивидуума: он знает французский (брал уроки у одной экзальтированной дамы интеллигентки), прекрасно рисует (учителем выступает один художник-арестант), знает азы медицины (обучен Лейбе), освоил охотничье, рыболовное дело. Короче, парень, лишённый опёки биологического отца Муртазы (который, это очевидно читается меж строк, ничего подобного бы сыну дать не мог, деревня, одним словом), вбирает в себя всё лучшее, что составляет матрицу «прекрасного». Намёк на то, что разорвав пуповину, связывающую его с национальным наследием предков, он обрёл подлинный смысл, узрел настоящее небо, смог реализовать в себе весь потенциал, который заложен в таком всечеловеке, лишённого предрассудков религии, национальности, традиции, патриархальности.

Юзуф не расспрашивает мать о своём биологическом отце, гены которого он носит, не интересуется своей национальной и религиозной принадлежностью. Французский язык важнее и нужнее татарского, искусство важнее веры.

Апофеозом романа становится карьерный крах Игнатова, которого увольняют из органов, но оставляют в поселении. Юзуф решает уехать в Ленинград и поступить там в академию художеств. Зулейха бросается к Игнатову с просьбой помочь. Тот, после недолгих раздумий, пока он ещё комендант лагеря и офицер НКВД, сжигает его метрику и выводит на бланке новую: «Иосиф Игнатов, 1930 года рождения. Мать Зулейха Валиева, крестьянка. Отец: Иван Игнатов, красноармеец» …

И вот уже не Юзуф, а Иосиф Игнатов на лодке уплывает по Ангаре в даль, оставив мать и нового «отца» друг с другом. Новый человек уплывает в новый светлый мир.

Таков итог долгого пути трансформации Юзуфа, который в итоге берёт новое ФИО – убийцы своего отца.

Это история одного большого предательства. История, которая разворачивается на глазах у нас, живущих сегодня в это смутно-испорченное время, народа, принимающего собственного убийцу за отца родного…

Это история космополитов-манкуртов, это идеологическая мантра для тех, кто бредит либеральным мифом о всечеловеке. О дереве без корней.

Это история об энтропии духа народа.

Это история о том, что уже происходит с нами, она напоминание всем тем, кто стоит крепко вопреки давлению циничного времени.

## КАТЛАУЛЫ СОРАУЛАРГА ГАДИ ҖАВАПЛАР

*(Дәвамы. Башын карагыз: № 1, 2019)*

***А. Г. Хәйретдинов***

## ҮЛЕМНЕҢ ЮКЛЫГЫ ТУРЫНДА

*Мәрхәмәт кыйлган Мәрхәмәтле Аллаһның исеме белән*

***Аннотация:*** *Мәкаләдә Ислам тәгълиматының әлегә кадәр игътибардан читтә торган мәсьәләләре турындагы сүз дәвам ителә. Биредә Коръән Кәрим айәтләренә нигезләнеп үлемнең юклыгы, чын кабернең кеше тәненнән гыйбарәт булуы, ул кабергә җаннарның иңдерелүе турында фикерләр әйтелә. Моннан тыш җирдә яшәүнең чынлыкта ни булуы һәм ул халәттән котылу юлы турында хәбәр бирелә.*

***Тамыр сүзләр:*** *Аллаһ, Коръәнне аңлау, барлык, үлем, җан, мәет, кабер газабы.*

Моннан алдагы язмабызны *барлык* Терек һәм Мәңгелек Аллаһы тәгаләдән гыйбарәт булганга күрә, ул *барлыкның* капма-каршысы мәгънәсендә булган үлемгә, ягъни *юклыкка* урын калмый, дигән фикер белән тәмамлаган идек.

Бу фикерне Коръән кәримнең ***«гамәлләре белән кайсыгызның яхшырак булуын сынау өчен үлемне һәм яшәешне халык кыйлды»*** [Коръән кәрим, 67. «әл-Мүлк» сүрәсе, 2-нче айәт кәримә], дигән айәте дә раслый. Бу айәт, беренче карашка, үлемнең барлыгы турында белдерә. Әмма үлемнең булдырылуы турында хәбәр бирү өчен кулланылган халәка фигыленә игътибар итсәк, караш үзгәрә.

Ошбу *халәка* фигыле турында моннан алда инде кат-кат әйтелгән иде. Аллаһ тәгалә нәрсәне дә булса булдыруы турында хәбәр иткәндә, Коръәндә нәкъ менә шушы фигыльне файдалана. Галәмнәр дә, күкләр дә, җир дә, кеше үзе дә, һәртөрле нигъмәтләр дә, кыскасы, бөтен *барлык* – болар һәммәсе халык кыйлынган, ягъни Аллаһ тәгалә булдырган һәрнәрсә теректер, һәрнәрсә тереклек итә. *Барлык* үзе дә терек, чөнки *барлык* ул нур, ә нур ул Аллаһның Үзе: ***«Аллаһ күкләрнең һәм җирнең нурыдыр»***. Болай булгач, үлем дигән нәрсә ул мәңге терек булган бу *барлык*ның, яки, башкача әйткәндә, тереклек халәтенең капма-каршысы булган терек булмау халәте дә түгел, юклык халәте дә түгел. Бөтен *барлык* мәңге терек Аллаһтан гына гыйбарәт булган хәлдә, терек булмаган берәр нәрсәнең булуын күз алдына китереп буламы? Юк, әлбәттә.

Һичшиксез, биредә: «Һәр кеше үлә ич, ничек инде үлем булмасын?», – дигән сорау туачак. Бу сорауга җавап бирер өчен, беренче чиратта, әнә шул кешенең үлүеннән гыйбарәт булган үлем төшенчәсенә якыннан багыйк, аңа Коръән кәрим күзлегеннән күз салыйк:

Димәк, кеше туа, яши һәм үлә. Яши торган кеше исән кеше була, үлгән кеше мәет була, шулаймы? Болай булгач, кешегә ике халәт хас: ул исән була, һәм ул мәет була. Коръән кәримдә дә мәет турында сүзләр бар: ***«чынлыкта, син мәетсең, һәм, чынлыкта, алар да мәетләрдер»*** [Коръән кәрим, 39. «әз-Зүмәр» сүрәсе, 30нчы айәт кәримә]. Әлеге айәт тере булып күренгән, үзләре турында «исәнмен, яшимен», дип әйтә алырлык кешеләргә карата әйтелгән: «сез – мәетләр», диелгән.

Әлеге айәт бик тирән мәгънәгә ия. Мондый сүзләрне ишеткән яки укыган һәркем сискәнеп куярга һәм: «Тукта әле! Мин – мәет, имеш! Әйләнә тирәмдәгеләр дә мәетләр, имеш! Моны ничек аңларга?», – дип уйга калырга тиеш. Бу айәт үз вакытында мине дә тетрәндерде һәм хакыйкатьнең миңа әлегә кадәр билгеле булмаган катламнарының, Аллаһы рәхмәте белән, ачылып китүенә сәбәпче булды. Чынлыкта, әлеге айәт нәкъ менә үлемнең юклыгын раслый. Коръән кәримдә андый айәтләр байтак. Әмма, монысы иң көчлесе, иң тәэсирлесе, иң турысын әйтеп бирә торганы.

Әлеге айәтне аңламаганга күрә, аны тәфсир кыйлучылар да, тәрҗемә итүчеләр дә тышкы кыяфәтен маңгай күзе белән генә күргәннәр һәм акыл белән генә кабул иткәннәр. Чыннан да, тән күзлегеннән караганда (ә маңгай күзе ул нәкъ менә тәннең бер өлеше дә инде) кеше яши, аннары үлә. Бу табигый тәртипкә карата акыл да ризасызлык белдерми. Әйе, үлгән кеше мәет була. Кеше үлгәннән соң, җирдә кабер казып аның үле гәүдәсен, ягъни мәетне шунда салалар да, күмеп куялар. Чынбарлыкны шул рәвешле генә аңлаган тәфсирчеләр һәм тәрҗемәчеләр шуңа күрә әлеге айәтне *«Чынлыкта, син үләчәксең, һәм, чынлыкта, алар да үләчәкләр»*, дип тәфсир кыйлалар һәм тәрҗемә итәләр. Болай итү Коръәннең мәгънәсен боза торган бик тупас хатадыр, ә тагын да дөресрәген әйткәндә – олы җинаятьтер, чөнки, Аллаһы бәян иткән хөкемне бозып аңлату нәтиҗәсендә кешеләрнең дөньяга карашлары, яшәеш мәгънәсен аңлаулары дөрес булып оешмый.

Алга таба атлар өчен бераз тын алыйк та, кайбер гади һәм һәр мөселманга мәгълүм булган нәрсәләрне исебезгә төшерик. Мәсәлән, Коръән кәримнең караңгылыктан яктылыкка чыгаручы китап буларак иңдерелгән булуын: ***«Әлиф-Ләм-Ра китаптыр. Аны сиңа кешеләрне Раббыларының рөхсәте белән караңгылыктан яктылыкка чыгартуың өчен иңдердек»*** [Коръән кәрим, 14. «Ибраһим» сүрәсе, 1-нче айәт кәримә].

Әгәр Коръән кәримне аңлату, тәфсир кыйлу эшенә яман ниятлеләр алынмаган булсалар иде, аның мәгънәләрен бозып аңлатмаган булсалар иде, мөселманнарны җәһәннәмгә әләгү белән куркытып Коръәнне укып аңларга тырышудан аермаган булсалар иде, әгәр Коръән өйрәнүне үзләренең шул тәфсирләрен укуга кайтарып калдырмаган булсалар иде, ислам диненең тарихы да башка булыр иде, мөселманнар да башка булыр иде, чөнки ул чакта Коръән кәрим, чыннан да, караңгылыктан яктылыкка чыгаручы китап, юл күрсәтүче һидаятьнамә булыр иде. Кызганыч, алай булмаган шул.

Чынлыкта, кабатлап әйтәм, ***«чынлыкта, син мәетсең, һәм, чынлыкта, алар да мәетләрдер»***, дигән айәт үлем дигән нәрсәнең юклыгын дәлилли. Ничек дәлиллиме? Әйдәгез, бер уйлап карыйк: Аллаһ тәгалә Коръән кәримне укыган һәркемгә: ***«син мәетсең»***, ди. Бу сүзләрне укыган кеше, әгәр аны укыганда маңгай күзен генә түгел, күңел күзен дә файдаланса, тирән уйга калырга тиеш. Әгәр Ходай тәгалә аның күңелен ачса, уйга чумган бу бәндәнең акылы түбәндәге фикер һәм нәтиҗәләр чылбырын тезеп чыгарга тиеш: «Мин исән-саумын. Мин яшим. Мин терекмен. Бу терек хәлемдә миңа атап ничек инде: ***«чынлыкта, син мәетсең»***, дип әйтеп булсын ди? Бу нинди хәл? Мин терек! Терекне мәет, дип атау дөресмени? Акылга сыймаган бер нәрсә! Әммә, моны әйтүче кем? Аллаһы тәгалә Үзе ич! Аллаһ тәгалә миңа мондый бәя биреп, миңа нәрсә җиткерергә, нәрсәне аңлатырга тели икән?».

Әлеге айәтнең чын мәгънәсенең аңлашылуы, аңлашылмавы исә уйга калган аптыраган бу бәндәнең эчке халәтендә бик мөһим үзгәрешнең булуына-булмавына бәйле булачак. Ул аның мәгънәсен маңгай күзе беләнме, әллә күңел күзе беләнме аңлаячак? Акылы беләнме, әллә күңеле беләнме?

Югарыда куелган сорауга әйләнеп кайтыйк. ***«Син мәетсең»***, диеп, Аллаһ тәгалә кемгә дәшә? Әлбәттә, үзен терек, исән-сау, дип уйлаган акыл белән эш итә торган кешегә түгел. ***«Син мәетсең, һәм алар да мәетләрдер»***, дигәндә, Аллаһы тәгалә җанга дәшә. Әйе, җанга дәшә, чөнки Коръәндә искә алынган килешү-гаһед карар кыйлынганда, килешүче ике тарафның берсе Аллаһ тәгалә Үзе булса, икенче тараф җаннар булган: ***«Раббың Адәм балаларыннан, аларның аркаларыннан аларның зөрриясен алып: «Мин түгелмени сезнең Раббыгыз!», дип, аларны үзләре өстеннән гуаһлык кыйлдырды. Алар: «Әйе! Без гуаһлык кыйлабыз!» – диделәр»*** [Коръән кәрим, 7. «Али Гыймран» сүрәсе, 172-нче айәт кәримә].

Биредә *зөррия*, дигән сүзгә игътибар итик. Сүзлектә ул *бала, токым* мәгънәсендә бирелә. Бу сүзнең тамырында яткан фигыль исә: 1) *кояш чыгу*; 2) *туу, барлыкка килү, хасил булу* мәгънәләрен белдерә. Димәк,

Адәм балаларының, ягъни Хабил белән Кабилнең аркаларыннан алынган *зөррияләре* дигәндә, шул икәүдән туачак кешеләрне күздә тоткан булып чыга. Хабил белән Кабилнең Аллаһны танулары турында шаһитлык кыйлуларының хаҗәте булмаган, чөнки алар икесе дә камил иман ияләре булганнар.

Болай булгач, Аллаһны Рабб буларак тану турындагы килешү әнә шул икәүдән туачак, әмма ул вакытта әле тумаган, җиргә басып йөрмәгән кешеләр белән корылганмы? Миңа калса, Аллаһны Рабб буларак танулары турында кешеләр түгел, ул кешеләргә иңәчәк җаннар гуаһлык кыйлганнар. Әмма, ана карынындагы яралгыга иңеп, ул яралгы өлгереп дөньяга килгәннән соң, ягъни бала булып туганнан соң, һәр җан үзенең бу гуаһлык кыйлган булуын оныта. Шуңа күрә, Коръән кәримдә кешегә карата *онытучы* мәгънәсенә ия булган *инсан* сүзе кулланыла күпчелек очракта.

Димәк, *инсан* сүзе кеше тәненә иңеп, үзенең гуаһлыгын оныткан җанны белдерә. Шуңа күрә, Аллаһ тәгалә Коръәндә кат-кат: ***«бәлки сез исегезгә төшерерсез»*** [Коръән кәрим, 16. «ән-Нәмел» сүрәсе, 90нчы айәт кәримә], дип теләген белдерә. *Кем* искә төшерергә тиеш? *Нәрсәне* искә төшерегә тиеш? Аллаһны Рабб буларак таныганыңны искә төшерергә кирәк. Моны *кем* искә төшерергә тиеш? Әлбәттә, җан искә төшерергә тиеш. Кеше моны исенә төшерә алмый, чөнки кешенең бөтен белгәннәре, укыганнары, ишеткәннәре, күргәннәре акылында, хәтерендә саклана. Ә ул акылда, ул хәтердә Аллаһ дигән зат юк, чөнки кешегә бирелгән маңгай күзенең Аллаһны күргәне юк. Аллаһны аның җаны күргән. Шуңа күрә Аллаһны искә төшереп Рабб итеп тану да җаннан көтелә.

Димәк, акылга ия булган кеше, хәтергә ия булган кеше, берничек тә Аллаһны исенә төшерә алмый, Аны үзенең Раббы буларак таныган шәһадәтен, гуаһлыгын исенә төшерә алмый, чөнки гуаһлык кыйлган мәлдә кеше әле булмаган. Шуңа күрә, Коръән кәримдә акыл дөньяны танып белү чарасы буларак, әйләнә-тирәдәге, дөньядагы күренешләрдән гыйбрәт алу чарасы буларак, гыйбрәт алып уйлану һәм шуннан нәтиҗәләр ясау чарасы буларак телгә алына. Шул нәтиҗәләр ахыр чиктә кешене мөселман булуга таба, ягъни гыйбадәт кылуга таба этәрергә тиешләр.

Югарыда үлемнең юклыгын дәлилли торган айәтләр Корәндә бик күп диелгән иде. Андыйлардан, мәсәлән, түбәндәгеләр: ***«Чынлыкта, син мәетләргә ишеттерә алмыйсың һәм чукракларга да ошбу чакыруны ишеттерә алмыйсың...»*** [27:80; 30:52]; ***«Терeләр белән мәетләр тиңләшмәячәкләр. Чынлыкта, Аллаһ Үзе теләгәнгә ишеттерә, ә син каберләрдәгеләргә ишеттерә алмыйсың»*** [35:22].

Югарыда китерелгән айәтләрдә Аллаһы тәгалә Үзенең мөбарәк рәсүленә (сгв) әйләнә тирәсендәгеләрнең күбесенең мәетләр булуын

аңлата, аның дәгъвәтен ишетмәүләре өчен көенмәскә куша. Ягъни, пәйгамбәр (сгв) белән бер заманда яшәгән тере кешеләр, тере булуларына карамастан, чынлыкта мәетләр булганнар. Мәет булу үле булу димәктер. Болай булгач, югарыдагы айәтьләрдән аңлашылганча, исән-сау булып тирләп-пешеп тырышып-тырмашып дөнья көткән кеше чынлыкта үле булып чыга. Чын мәгънәдә терек булу җанның тере булуыдыр. Әгәр исән-сау булып күренгән кешенең җаны йоклый икән, андый кеше мәеттер. Шуңа күрә мәетләр алар без уйлаганча, каберләрдә ятмыйлар. Каберләрдә әле нинди генә хәрәкәт кайнап тора, нинди генә химик процесслар бармый: миллионлаган микроорганизмнар кешенең туфрактан, биниһая химик матдәләрнең үзара укмашуыннан тукылган гәүдәсен кире туфракка әверелдерәләр, аерым-аерым химик матдәләргә таркаталар. Ниһаять, ул гәүдәдән кальций исемле табигый химик матдәдән гыйбарәт булган сөякләр генә кала. Ә кайчак алары да калмый. Шуңа күрә үлем дигән нәрсәнең безгә генә шулай үлем булып күренүен аңларга тиешбез.

Димәк, бу мәгънәдә мәет булу, үле булу тәннең тере булуына бәйле түгел, тәннең тере булуыннан тормый. Айәтләрдә искә алынган мәгънәдә мәет булу, үле булу кешене терек хәлдә тоткан, хәрәкәтләндергән җанның Аллаһтан аерылган булуына, Аллаһны оныткан булуына кайтып кала. Аллаһ тарафыннан бирелгән *җан* булсын, *рух* булсын, *кот* булсын – болар Үзләрен булдырган Раббылары белән кавышканга кадәр мәет булырга дучар ителгәннәр. Бу турыда Пәйгамбәребез (сгв) дә: *«Кешеләр йоклыйлар, үлгәндә алар уяналар»*, – дигән булган. Ягъни, кеше гәүдәсенә иңеп шул гәүдәгә юрганга төренгәндәй төренгән җаннар шул гәүдә эчендә йокыга талганнар. Әҗәл җиткәч, ягъни Аллаһы тәгалә карары белән бирелгән вакыт узгач, җаннар тәннәрдән кубарылалар һәм уятылалар, ягъни терелтеләләр. Димәк, җан биргән бәндәне соңгы юлга озатырга килгән кешеләр күзенә үлем булып күренгән бу хәл чынікта җаннарның мәҗбүри рәвештә уятылуыдыр, кубарылуыдыр. Мәҗбүри рәвештә булганга күрә җан бу хәлне бик авыр кичерә. Бу йөздән халыкта «үлем газабы», дигән гыйбарә юкка гына йөрми.

Гомумән алганда, Коръән айәтләре үлемнең юклыгы турындагы төшенчәне алга сөрә. Шундыйларның берсе болай тәрҗемә ителә: ***«Аллаһ юлында үтерелгәннәр турында «мәетләр», дип әйтмәгез. Юк, алар тереләр, тик сез моны тоймыйсыз»*** [2:154].

Бу айәттән күренгәнчә, кешеләр тарафыннан үлем буларак кабул ителгән нәрсә юкка чыгу, бетү мәгънәсендәге үлем түгел, ә бар булуның, яки яшәешнең башка рәвештә дәвам ителүе булып чыга. Дөрес, үлгән кешенең тәнен җиргә күмәләр. Әмма ул тәнне хәрәкәткә китергән җан тән белән бергә үлми. Ул бар булуын, яки, башкача әйткәндә, яшәвен дәвам

итә. Бу хакта Коръән кәримдә бигрәк тә зур тәэсир көченә ия булган бер айәт бар. Аның тәрҗемәсен китерик: ***«Без сезләр арасында үлемне кадер кыйлдык һәм дә рәвешләрегезне үзгәртеп сезне үзегез белмәгән бер нәрсәдә үстереп чыгаруыбызда Без узып кителүчеләрдән түгелбез»*** [56:60–61].

Югарыда китерелгән айәтләрдә, аңлашылганча, кабердә тән калдыклары ятса да, анда үлем юк. Мәет кабергә салынган булса да, аның үлемгә катнашы юк. Мәетнең үлеп ятарга «вакыты юк», чөнки әле кичә генә тереклек иткән тән кабергә салынгач бик актив рәвештә химик матдәләргә таркалу процессын кичерә. Шуңа күрә үлем ул кабердә яту түгел. Үлем ул Аллаһы тәгалә белән булган бәйләнешне торгызмаган җанның халәте, Аллаһтан аерылганлык халәте. Мәет булу ул Раббысы белән элемтәне җуйган җанның кеше тәнендә кичергән халәтедер. Шуңа күрә чын мәетләр җирне таптап йөрүче кешеләрдән гыйбарәт. Әмма шул ук вакытта алар үзләренең мәет булуларын сизмиләр, аңламыйлар. Аллаһы тәгалә җанга бу шаккаттыргыч хакыйкатьне ачканчы, ул шундый тере мәет була бирә.

Биредә инде искә алынган айәтнең тәрҗемәсен тагын бер кат искәртеп узыйк: ***«Раббың Адәм балаларыннан, аларның аркаларыннан аларның зөрриясен алып: «Мин түгелмени сезнең Раббыгыз!», дип, аларны үзләре өстеннән гуаһлык кыйлдырды. Алар: «Әйе! Без гуаһлык кыйлабыз!» – диделәр»*** [Коръән кәрим, 7. «Али Гыймран» сүрәсе, 172нче айәт кәримә].

Ягъни, Адәм, галәйһис-с-сәламнең, токымын тәшкил итәчәк кешеләр җир йөзен таптап йөри башлаганчы ук инде ул кешеләргә иңдереләсе җаннар Аллаһыны үзләренең раббылары буларак таныячакларын вәгъдә иткән булганнар. Бу мөбарәк айәтне болай аңлаганда, алга таба китереләсе айәтне ничек аңларбыз икән, карыйк әле: ***«Аллаһ сезләрне булдырды, аннары Ул сезләрне ризыкландырды, аннары Ул сезләрне үлдерә, аннары Ул сезләрне терелтә...»*** [30: 40].

Ничек уйлыйсыз, ошбу мөбарәк айәт нәрсә турында хәбәр бирә? Беренче карашка, бар да аңлашыла кебек: Аллаһы тәгалә кешеләрне булдырган, ягъни кеше дөньяга китерелгән. Аннары Аллаһы тәгалә кешеләрне ризыкландыра, ягъни кешенең ашыйсы ризыгын, эчәсе эчемлеген, киясе киемен, торасы йортын билгеләп куя, дип аңлыйк, хата булмас, шәт. Аннары Аллаһы тәгалә кешеләрне үлдерә, ягъни кешегә үлем килә, ул мәет була, аны кабергә салалар. Монысы да дөрес. Аннары Аллаһы тәгалә кешеләрне терелтә, ягъни Ул үзе генә белгән бер көнне кыямәт башланачак, каберләр ачылачак, мәетләр терелеп кубарылачаклар да яшәгәндә кыйлган гамәлләре өчен Аллаһ хозурында җавап бирер өчен мәхшәр мәйда-

нына сөреләчәкләр. Әлбәттә, биредә искә алынган нәрсәләр һәр мөселманга мәгълүмдер. Әлеге айәтне маңгай күзе белән укыганда аны нәкъ әнә шулай аңлыйсың, да инде.

Тик бу айәтне башкача да аңлап була. Башкача аңлау аны күңел күзе белән укыганда ачыла. Әйдәгез, айәтнең гыйбарәләренә күңел күзе белән багып аның мәгънәләрен берәм-берәм барлап чыгыйк.

***«Аллаһ сезләрне булдырды...».***

Миңа калса, биредә сүз Аллаһының тәннәрне түгел, ә нәкъ менә югарыда искә алынган җаннарны булдыруы турында бара. Җаннар булдырылдылар һәм Аллаһы тәгаләне раббылары итеп таныячаклары турында гуаһлык кыйлдылар, ягъни сүз бирделәр. Аерым игътибар ителәсе нәрсә биредә *халәка-кум*, ягъни *сезләрне булдырды*, дигән фигыль. Ул үткән заман шәкелендә куелган. Ягъни җаннарның булдырылуы – тәмамланган эш: ***«Адәм балаларыннан, аларның аркаларыннан аларның зөрриясен алып»***, дигәндә, сүз саннары билгеле булган җаннар турында бара.

***«...аннары Ул сезләрне ризыкландырды...».***

Җаннарны булдыргач, Аллаһы тәгалә ул җаннарның һәммәсенә кайсы атадан кайсы анага иңеп гәүдәләнәчәген, кайчан һәм кайда туачагын, ашыйсы ризыгын, эчәсе эчемлеген, киясе киемен, торасы йортын билгеләп куйды. Монда да *разәка-кум*, ягъни *сезләрне ризыкландырды*, дигән сүзтезмәдә *разәка* фигыле үткән заман шәкелендә кулланылган. Ягъни эш тәмам, җан иңдереләчәк кеше гәүдәсенең никадәр сулыш алачагына кадәр, аның йөрәге ничә мәртәбә тибәчәгенә кадәр исәпләнеп куелган.

***«...аннары Ул сезләрне үлдерә...».***

Уйлап карыйк: җанны үлдереп буламыни? Әле бая гына үлем юк дигән идек! Әйе, җан өчен үлем юк. Әмма Аллаһны онытудан, Аннан «аерылудан» гыйбарәт булган үлем халәте бар. Әйтелгән иде ич, Раббысыннан «аерылган» җан үле була, мәет була, дип. «Аерылган» сүзе тик томалдан гына куштырнкаларга алынмады, чөнки язмабызның беренче кисәгендә аңлатылганча, Аллаһы тәгаләдән аерылып булмый. Аңардан аерылу өчен нинди дә булса аулак урын юк. Була да алмый. Шуңа күрә «аерылуны» Аллаһны оныту буларак аңларга кирәк. Коръәндә кешегә карата *инсан* дигән сүз юкка гына кулланылмаган: *инсан* сүзе «онытырга», дигән мәгънәгә ия булган *нсй* тамырыннан ясалган һәм аның чын мәгънәсе «онытучы», «оныткан берәү» булып чыга. Димәк, *инсан* дип кешегә түгел, Аллаһыны шул кешеләрне терек хәлдә тотучы һәм шул ук вакытта Аллаһны оныткан җаннарга дәшелә.

Инде кабат уйлап карыйк: ***«Ул сезләрне үлдерә»***, дигән айәт җаннарның үлдерелүен бәян итә. Җан өчен үлдерелү ни ул? Җан өчен үлдерелү ул аның кабергә салынуы. Тик бу очракта кабер җирдә казылган чокыр түгел,

ә җан иңдерелә торган кеше гәүдәсе ул. Баксаң, кеше гәүдәсе ул чып-чын кабер ич, чөнки гәүдә җирдән алынган химик элементлардан тукыла, шул матдәләр исәбенә үсә. Гәүдәдән җан алынгач, ул гәүдә кире химик матдәләргә әверелә, туфрак хәленә килә. Шулай булгач, кешенең тәне җанлану аркасында гына терек мәхлукка әйләнгән туфрак булмый ни булсын?

Димәк, кеше гәүдәсе туфрактан тукылган, шуңа күрә вакыты җиткәч ул туфракка әйләнә. Җан әнә шул туфракка иңдерелә дә инде, шуңа күрә җанның гәүдәгә иңдерелүе аның кабергә иңдерелүедер. Кабергә иңдерелгәннән соң җан өчен сынау башлана: беренчедән, ул Аллаһыны оныта, Аның белән бәйләнештә булырга тиешле булуын да оныта, ягъни мәет кебек була. Алга таба сынау җанның әнә шул мәет хәленнән яңадан терек хәлгә килүеннән гыйбарәт була. Никадәр тиз тереләчәк? Монысын Аллаһ үзе генә белә. Әмма терелү мөмкин кадәр тизрәк булсын өчен, Аллаһ Аны оныткан җаннарга, ягъни инсаннарга ярдәм кулын суза. Аның ***«...аннары Ул сезләрне терелтә...»***, дигән сүзләре нәкъ әнә шул ярдәмгә ишарә итә дә инде. Ягъни, Аллаһ тәгалә җаннарны терелтер өчен барлык мөмкинлкеләрне булдырган һәм армый-талмыйча, йокламый-йокымсырамыйча бу ***«...эшне башкара...»*** [13:2], ягъни җаннарны караңгылыктан яктылыкка таба, тәмугътан оҗмахка таба юнәлтә.

Ниһаять, соңгы ике гыйбарәдә кулланылган фигыльләргә игътибар итик. Алар биредә икәү: *үлдерә* (*йумиту*-күм) һәм *терелтә* (*йухьйи*-күм). Фигыльләрнең икесе дә хәзерге заман шәкелендә кулланылган. Димәк, җаннарны үлдерү һәм терелтү даими булып тора торган эш. Ул үлдерү һәм терелтелү процессы элек тә булган, хәзерге вакытта да дәвам ителә, алга таба да дәвам ителәчәк. Кыскасы, Аллаһ ***«...эшне башкара...»*** [13:2]. Аның кайчаннан башланып, кайчан бетәчәген Аллаһы тәгалә үзе генә белә.

Җаннарны *«үлдерү»* һәм *«терелтү»* ни өчен кирәк? Бу эшне Аллаһы тәгалә җир йөзендә хәлифә булдыру өчен башлаган, димәк *«үлдерү»* һәм *«терелтү»* процессы да әнә шул хәлифәне булдыру өчен кирәк. Бу турыда ***«Һичшиксез, Мин җир йөзендә хәлифә урнаштыручымын»*** [2:30], дигән айәт хәбәр бирә.

Бу айәттә «урнаштыручы», дигән сүзнең гарәпчәсе *җәгылүн* буларак яңгырый. Ясалышы буенча бу сүз төп юнәлештәге сыйфат фигыльдер. Гадәттә, бу айәтне урысчага булсын, татарчага булсын тәрҗемә иткәндә, әлеге үзенчәлеккә игътибар итмиләр һәм нәтиҗәдә аның мәгънәсен бик тупас сурәттә бозалар. Мәсәлән, Р.Батулла тәрҗемәсендә айәт болай яңгырый: *«Һичшиксез, Мин Җир йөзендә бер хәлифә барлыкка китерәчәкмен»* [Коръән: 2012. 16 б.]. Габделбари Исаевның тәрҗемәсендә карыйк: *«Мин җирдә бер алышына торган кеше яратмакчы булам»* [Исаев: 2018. 552 б.], диелгән.

Ягъни әлеге тәрҗемәләрнең икесендә дә сыйфат фигыль урынына киләчәк заман фигыле кулланылган. Нәтиҗәдә, айәтнең мәгънәсе үзгәрүе сәбәпле җир йөзендә хәлифәне Аллаһ кайчандыр киләчәктә барлыкка китерәчәк, дигән мәгънә килеп чыга. Тик Аллаһы тәгалә Коръәндә алай димәгән! Ул сыйфат фигыле кулланган. Сыйфат фигыле хәзерге вакытта дәвам итеп торган эш, халәт яки процессны белдерә. Мәсәлән, «ул язучы», дигән җөмләне «ул язачак», дип тәрҗемә итү нинди зур хата булса, әлеге айәттә ***«Мин җир йөзендә хәлифә урнаштыручымын»***, дигән җөмләне *«Мин җир йөзендә бер хәлифә барлыкка китерәчәкмен»*, дип тәрҗемә итү, гомумән, бик тә хәтәр хатадыр, чөнки болай итү Аллаһының бер мәгънә белән әйткән сүзен башка мәгънәгә күчерә.

Болары аңлашылды кебек.

Аллаһ тәгалә җаннарны булдырган һәм ул җаннарны кеше гәүдәләренә иңдереп сынаулар аша үткәрер өчен җиргә китереп тора. Җан өчен төп сынау Аллаһыны исенә төшерүеннән, Раббысы белән бәйләнештә булуын исенә төшерүеннән гыйбарәт. Боларны искә төшергәнче җан тән эчендә булып, кабердә яткан мәет кебек бер халәттә була. Тәннән гыйбарәт булган кабердә ятканда җан кабер газаплары кичерә. Кабер газаплары дигәнем, ул кеше тәнендәге җанның кичергән төрледән төрле кайгы-хәсрәтләре, югалтулары, бәла-казалары, чир вә авыруларыдыр. Болар барысы да җанны интектерә, утта яндыргандай газаплый. Әйе, кеше гәүдәсендә газап кичергән җан, чынлыкта, җәһәннәм газабын кичерә. Җәһәннәм ул әллә кайда киләчәктә түгел, ул нәкъ менә шушы минутта, һәр тере кеше өчен дәвам ителә торган халәттер.

Миңа бу хакыйкать Аллаһының рәхмәте белән ачылды. Без җәһәннәмдә икәнбез. Ә бит бу җәһәннәм, беренче карашка яшәргә ярап тора, монда хәтта берникадәр рәхәтлекләр, шатлыклар да бар. Шушындый шартлар булдырып, шул шартларда җаннарны үстерүче, көчәйтүче Аллаһ та мәрхәмәт иясе булмый, кем булсын ди? Бу хакыйкатьне үзлегемнән аңламага минем ни белемем, ни акылым җитмәс иде. Шул минутта гына мин Аллаһы тәгаләнең Үзен ни өчен *әр-Рахман әр-Рәхим* дип атаганын аңладым. *Әр-Рахман әр-Рәхим*нең мәгънәсе Мәрхәмәт кыйлучы Мәрхәмәт Иясседер. Коръән кәримдә Аллаһы тәгалә һәр сүрәне юкка гына шулы исеме белән башламый. Ул: *«Мин йомшаклык иясемен, миннән дә йомшак күңелле башка берәү юк. Шул йомшаклыгым белән мин сезләргә кабер газабыннан котылу юлын күрсәттем!»*, – ди кебек.

Чыннан да, җаннар зур үзгәрешләр һәм сынаулар уза алсыннар өчен Аллаһы тәгалә *дөнья* дигән урын булдырган. Шушында рухи үсеш-үзгәреш кичереп, олы тәҗрибәләр туплап җаннар Раббылары белән кавышуга сусау кичерә башлыйлар да Раббыларына таба омтыла башлыйлар,

Аның белән кавышу юлларын эзли башлыйлар. Болар барысы да *дөнья* дигән җәһәннәмдә башлана. Дөньяның җәһәннәмнең бер төре булуын тирәнрәк аңлар өчен, аның Коръәндә *әл-хәйату-д-дуньйа*, дип аталган булуына игътибар итик. Ягъни, үзенә күрә аерым һәм мөстәкыйль нәрсә буларак *дөнья* дигән төшенчә юк. Без *дөнья* буларак күздә тоткан нәрсә Коръәндә *әс-сәмәвату вә-л-ард* (күкләр һәм җир), дип атала. *Дөнья* сүзе дә Коръәни сүз, тик ул җан яшәешенең бер дәрәҗәсен, ул да булса аның иң түбән дәрәҗәсен белдерә. *Әл-хәйату-д-дуньйа* гыйбарәсен тәрҗемә итсәк, *түбән булган яшәеш* килеп чыга. Мәсәлән: ***«Сез түбән булган яшәешне өстен күрәсез»*** [87:16]; ***«болар барысы да түбән булган яшәешнең рәхәтлекләредер»*** [43:35].

*Әл-хәйату-д-дуньйа* гыйбарәсен тәрҗемә итүдәге бер тупас хата турында да әйтеп узарга кирәк. Мәсәлән, Г. Исаев бу [43:35] аятендәге *әл-хәйату-д-дуньйа*, дигән гыйбарәне *дөнья тормышы*, дип тәрҗемә иткән. Р. Батулла исә (87:16) аятдәге *әл-хәйату-д-дуньйа*, дигән гыйбарәне *дөнья тормышы*, дип тәрҗемә иткән. Болай итү дөрес түгел, чөнки, 1) беренчедән, Коръәндә аергычлы (атрибутив) сүзтезмә булып килгән гыйбарә тәрҗемәдә изафә шәкелендә, ягъни бер исемне башка бер исем белән аерымландырган сүзтезмәгә әверелдерелә. Аергычлы сүзтезмәдә нәрсәнең дә булса сыйфаты белдерелә. Мәсәлән, *борынгы китап*. Изафәле сүзтезмәдә исә нәрсәнең дә булса кемнеке, яки нәрсәнеке булуы белдерелә. Бу очракта *борынгының китабы*, дигән сүзтезмә килеп чыга. 2) Икенчедән, татарча *дөнья тормышы*, дигән изафәле гыйбарәне кире гарәп теленә тәрҗемә итсәк, Коръәндә килгән *әл-хәйату-д-дуньйа*, гыйбарәсе килеп чыкмаячак, *хәйату-д-дуньйа*, булачак, ягъни изафәле сүзтезмә булачак. Башка мисал ярдәмендә күрсәтсәк, *борынгы китап* дигән гыйбарә урынына *борынгының китабы*, дип әйтү кебек. Күргәнегезчә, мәгънә бик нык үзгәрә, асыл мәгънәнең хәтта эсәре дә калмый. Шуңа күрә, һич тә *дөнья тормышы* түгел, ә нәкъ менә *түбән булган яшәеш*, *түбән яшәеш*. Һәм, ниһаять, 3) *дөнья тормышы*, дигәндә уйга калырга сәбәп юк, кешеләр болай да инде дөнья белән мавыгалар, нинди сорау тусын ди? Ә *түбән булган яшәеш*, дигәндә, телисеңме, теләмисеңме: «югары булган яшәеш тә бармы икән?», – дип уйга калу өчен нигез бар. Коръән дә бит кешене уйланырга чакыра.

Димәк, җәһәннәм ул җаннар кичерә торган, җаннар кичерергә тиешле булган һәм котылгысыз рәвештә кичерәчәк бер халәттер. Җәһәннәмнән котылу юк. Моның шулай булуы Коръәндә белдерелгән: ***«арагызда анда керми калган берәүнең генә булса да юклыгы Раббыңның катгый карарыдыр»*** [19:71]. Биредә ***«анда»***, димәк ни димәктер? Нәрсә күздә тотыла? Моннан алдагы аятьләргә карасаң, сүзнең җәһәннәм турында баруы

көн кебек ачык: ***«Раббың белән ант итәмен ки, Без аларны һәм шайтаннарны һичшиксез җыябыз да, җәһәннәм әйләнәсендә тезләндереп куябыз»*** (19:68); ***«Аннары һичшиксез һәр төркемнән әр-Рәхманга буйсынмауда иң нык булганнарны аерып алачакбыз»*** [19:69]; ***«Аннары да Бездер шунда беренчеләрдән булып яндырылачакларның кемнәр икәнлеген иң яхшы белүчеләр»*** [19:70]; ***«Арагызда анда керми калган берәүнең генә булса да юклыгы Раббыңның катгый карарыдыр»*** [19:71].

Бу айәтләрне «Намаз уку ул җәһәннәмгә эләкмәс өчен кирәк», – дип әйтә торган мөселманнарга күрсәткәнем бар иде. Минем: «Бу айәт кемнәргә карата әйтелгән?», – дип соравыма: «Кәферләргә карата!», – дип җавап бирелә иде. «Соң, кәферләр Коръәнне укымыйлар ич!», – дигәнемнән аптырап калалар иде дә, соңрак: «Бу айәт мөселманнар кәферләргә аларны ни көткәнен җиткерсеннәр өчен бирелгән», – диләр иде. Ягъни, намаз ияләре әлеге айәттә әйтелгәннәрне һич тә үзләренә карата әйтелгән сүз буларак кабул итә алмыйлар иде. Тик, әйтелгән бит, ни кыйлыйк: ***«Арагызда анда*** [җәһәннәмгә] ***керми калган берәүнең генә булса да юклыгы Раббыңның катгый карарыдыр»*** [19:71]. Аллаһының ***«катгый карары»***ның нинди булуын танырга теләмәгәндә үзеңне: «Мин мөселман! Мин Аллаһыга гыйбадәт кыйлам! Ә син намаз укыйсыңмы?», – дип лаф орып йөрүдән ни мәгънә? Бәлки, иң элек Коръәннең әлеге айәтен нәкъ менә сиңа карата туры бәреп әйтелгән булуын танырга кирәктер? Аны аңларга, аны кабул итәргә һәм аның мәгънәсенә таянып яшәеш мәгънәсе турындагы күзаллавыңны үзгәртергә тырышырга кирәктер?

Югарыда әйтелгәннәрдән мин бер нәтиҗә чыгардым: җәһәннәмдә булуның ояты юк. Монда булуыбызны Аллаһ карар кыйлган. Бу мәктәп кебек: беренче сыйныфтан башлыйсың, икенче сыйныф, өченче... шулай итеп соңгы сыйныфка кадәр. Сыйныф тәмамланган саен имтихан. Мәктәп мөдире дә беренче сыйныфта укыган баланы беренче сыйныфта укыганы өчен сүкми. Ул аның сынауны үтеп, югарырак сыйныфка күчүен тели. Моның өчен мөдир баланың тиешле күләмдә белем алуын, үсешенең дәвам ителүен тәэмин итә, шартлар тудыра, укытучылар таба, уку-укыту әсбапларын булдыра, балага һәрвакыт булыша, ярдәм итә.

Әгәр кеше гәүдәсенә бикләнгән җан Аллаһны исенә төшермәсә, Раббысы белән бәйләнештә булуын аңларлык дәрәҗәгә җитмәсә, ул кабердә яткан мәет булып кала. Андый җаннар әҗәлләре* җиткәч уятылалар: ***«Сезләргә вәкил кыйлынган үлем фәрештәсе сезне тулысынча ала,***

* *Әҗәл* сүзен үлем мәгънәсендә кабул итү күнегелгән, мәсәлән, *әҗәле җитте*, ягъни *үлде*. Әмма бу сүз асылда бер ара, вакыт өзеге; (срок, период) мәгънәсенә ия. Шуңа күрә аны Аллаһ тарафыннан җанга кеше гәүдәсендә үткәрәчәк вакыт буларак тану дөресрәк була. Вакыт – гарәп теленнән кергән сүз. Борынгы төрки телебездә вакыт төшенчәсе *йай/җай* сүзе белән белдерелгән. Мәсәлән, *җаем чыкмады*, ягъни *вакытым булмады*.

***аннары Раббыгызга кайтарыласыз»*** [32:11]. Биредә *йәтәваффә-кум*, дигән сүзтезмәдә *йәтәваффә* фигыле кулланылган. Ул хәзерге заман шәкелендә килә. Аны *«сезнең җанны ала»* (Г. Исаев), дип тә, *«җаныгызны алачак»* (Р. Батулла), дип тә тәрҗемә итәләр. И. Крачковский: *«приемлет вашу кончину»*, дип биргән. Нигә биредә мин бу *йәтәваффә-кум* сүзтезмәсен ***«сезне тулаем ала»***, дип тәрҗемә иттем? Чөнки ошбу фигыль кайтым юнәлешендә булганда гына, ягъни *йүтәваффә* (үлдерелә) шәкелендә генә *үләргә*, дигән мәгънәгә ия. Әле бу кадәре дә дөрес булмыйча, асыл мәгънәсе *казанганына ирештерелде*, булырга мөмкин. Әмма без караган айәттә ул төп юнәлештә куелган. Болай булганда әлеге фигыль *тулаем алу, тулысынча алу*, мәгънәләрен белдерә. Димәк, әлеге фигыль үлем фәрештәсенең әҗәлләре җиткән җаннарны тулысынча алуын белдерә. Җан тулысынча алынмаган чаклар да бар. Ул да булса, йокы, мәрткә китү, аңны югалту, клиник үлем һәм башка хәлләр. Ә биредә җанның кеше дип аталган кабердә булуына нокта куела да, ул кубарылып, җавап бирүгә тартыла.

Тыштан караганда, җанның кубарылуы безгә берәүнең үлеме булып күренә. Шулай да, чынлыкта, аның җан биргәнен дә беләбез, шуңа күрә *җан бирде*, диябез. Акылга сыймаслык, без белмәгән хәл түгел. Ул хәл һәммәбезне көтә. Тик без кешенең гүәдәсе җирдә казылган кабергә озатылган минутларда шул гәүдәдә еллар үткәргән җанның тән дип аталган кабердән кубарылуын аңлап бетермибез. Тән дигән кабердән кубарылган җан Раббысы хозурына җавап бирергә тартыла. Ул, әлбәттә, кабердә ятып калмый. Кабердә ниләр калганын без моңарчы инде әйтеп уздык.

### Әдәбият

Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре. Бишенче басма. Төрле галимнәрнең тәрҗемәләре һәм шәрехләреннән файдаланып матбугатка әзерләүче Мөхлисулла углы Рабит Батулла. Казан: «Җыен» нәшрияты, 2012.

Габделбари хәзрәт Низаметдин улы Исаев. Коръән Кәрим тәрҗемәсе / Фәнни мөхәррире Ә. К. Бостанов. – Казан: Издательский дом «Казанская недвижимость», 2018.

## Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар

## Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики

### ХРОНИКА.

8 февраля 2019 г. на базе Юлбатской школы Сабинского района РТ начало свою работу отделение Республиканского клуба «Юный краевед» (руководитель – заслуженный учитель РТ И. Ф. Сафин).

Сабинское отделение клуба «Юный краевед» было создано на базе ранее существовавшего краеведческого кружка Юлбатской школы. Отметим, что на базе школы действует уже много лет краеведческий музей. В летнее время учащиеся школы под руководством учителя истории И. Ф. Сафина ездят по историческим местам района и республики, принимают активное участие в конкурсах, олимпиадах и конференциях.

Недавно И. Ф. Сафин провел очередное занятие кружка «Юный краевед». Мероприятие было посвящено 30-летию вывода советских войск из Афганистана и Дню рождения и 75-летию памяти подвига татарского поэта, Героя Советского Союза Мусы Джалиля и его соратников. Ильдар Фатхуллович презентовал учащимся собранные материалы о сабинцах, участниках боевых действий в Афганистане.

* * *

2019-нчы елның 1–3-нче мартларында Казан шәһәреннән бер төркем (Дамир Исхаков, Руслан Айсин, Рәис Яушев) татар милләте активистлары чакыруы буенча Алма-Ата (Казахстан) шәһәрендә булып кайттылар. Бу Казахстанга сәяхәт Ренат Сәйфуллин, Илдар Измайлов һәм Рәшид Емелеев инициативасы буенча һәм алар ярдәме нигезендә, җирле татарлар белән очрашу үткәрү өчен башкарылды. 2-нче март көнне җыелган татар җәмәгатьчелеге каршында тарих фәннәре докторы, «Туган җир. Родной край» журналының баш мөхәррире Дамир Исхаков татар халкының тарихы турында чыгыш ясады, күп санлы сорауларга җавап бирде. Руслан Айсин хәзерге сәяси вәзгыятькә тукталды, татар халкының үсеш стратегиясе турында сөйләде. Очрашуда өлкән яшьтәге күренекле шәхесләр белән бергә (М. Ерзин, Г. Хәйруллин һ. б.) яшьләр дә күп иде. Җыенда катнашучыларга «История рода Яушевых в средневековый период и кимакская проблема» (авторы – Д. Исхаков) китабын алу мөмкинлеге булдырылды.

* * *

Казан шәһәрендәге 15-нче татар гимназиясендә 19 март көнне «Укучыларның милли үзаңын формалаштыру һәм үстерүдә туган якны өйрәнү музейларының роле» дип аталган семинар үтте. Семинар эшендә шәһәрдәге татар гимназияләреннән җыелган укытучылар каршында «Туган җир. Родной край» журналының баш мөхәррире, тарих фәннәре докторы Д. М. Исхаков чыгыш ясады. Күп кенә башка чаралар белән бергә бу семинар вакытында Бишбалта бистәсендәге Казан Адмиралтействосы тарихына багышланган мәктәп музее белән танышу да үтте.

* * *

16 марта 2019 г. председатель Общества татарских краеведов РТ А. А. Бурханов встретился с коллективом Национальной (татарской) гимназии г. Саратова.

В ходе встречи А. А. Бурханов презентовал номера краеведческого журнала «Туган жир. Родной край» и призвал саратовцев писать свои статьи для этого издания.

* * *

16 марта 2019 г. в Саратовской областной научной библиотеке состоялась презентация книги А. А. Хабибуллина «История татарского села Верхазовка» (Саратов, ИЦ «Наука», 2018, 300 с. с иллюстрациями, 18 п.л., тираж 200). В мероприятии приняли участие ученые, краеведы, общественные деятели, работники культуры и образования, представители духовенства и СМИ, жители с. Верхазовка Дергачевского района. В мероприятии принял участие председатель Общества татарских краеведов РТ А. А. Бурханов, отметивший важность изучения исчезнувших сел и определения стратегии развития наших деревень и сел. Затем он презентовал номера краеведческого журнала «Туган жир. Родной край», экземпляры которых были переданы в Областную библиотеку и в фонды татарских общественных организаций.

* * *

2019-нчы елның 23-нче мартында Кукмара районы Ядегәр авылында урнашкан урта мәктәптә «Эзләнүләр аша камиллеккә» дип аталган Габдулхак Каюмов исемен йөртүче укучылар, студентлар һәм педагогларның III Республика укулары үтте. Чара К(И)ФУның Филология һәм мәдәниятара коммуникация институты катнашында Татарстанның күп төбәкләреннән килгән укучы балаларның төрле фәннәр (тарих, филология, табигый фәннәр һ. б.) буенча татар телендә эшләнгән докладла-

рының конкурсы рәвешендә оештырылып, гаять эчтәлекле иде. «Туган җир. Родной край» журналының баш мөхәррире, тарих фәннәре докторы Д.М.Исхаков «Төбәк тарихын өйрәнү» секциясе эшен эксперт буларак җитәкләп, уңышлы докладлар ясаган укучы балаларга докладлары нигезендә мәкаләләр язып, аларны журналда бастырырга тәкъдим итте. Казаннан килгән экспертлар арасында университет укытучылары һәм башка белгечләр дә бар иде. Мондый чаралар тәҗрибәсе, һичшиксез, башка районнар өчен дә үрнәк булып тора ала.

* * *

2019-нчы елның 28-нче март көнендә БТК бинасында «Туган җир. Родной край» журналы редакциясе инициативасы белән оештырылган «Ирек мәйданы» клубы эшчәнлеге башланып китте. Беренче утырышта Р.С.Вәлиев авторлыгында нәшер ителгән «Автономное плавание. Хроника жизни российских татар на стыке двух веков» (Казань, 2018) исемле РФда хәрәкәт итүче татар автономияләре турындагы китабын тәкъдим итү булды һәм бүгенге сәяси шартларда милли оешмаларыбызның иҗтимагый активлыгы мәсьәләсе тикшерелде. Чыгыш ясаучылар арасында Р.С.Вәлиев, Р.З.Закиров, Д.М.Исхаков һәм чарада катнашкан журналистлар Р.В.Айсин, А.Ж.Исмәгыйлева, И.И.Ярхамов бар иде. Ахырдан утырышта катнашучыларга Клуб эшчәнлегенең алдагы планнары турында игълан ителде.

* * *

29 марта на базе Сарабикуловской школы Лениногорского района РТ прошли Сарабикуловские историко-краеведческие чтения – Всероссийская научно-практическая, историко-краеведческая конференция «Человек и природа в Лениногорском районе и Юго-Восточном Татарстане. Село Сарабикулово и Шешминско-Черемшанское междуречье: проблемы истории и культуры».

В работе конференции приняли участие более 120 человек, в рамках которой работали 2 секции: «Проблемы региональной истории Юго-Восточного Татарстана. Жизнь и деятельность выдающихся земляков»; «Историко-краеведческая и музейная работа. Возрождение национальных традиций, обрядов и праздников. Вопросы патриотического и нравственного воспитания молодого поколения». В двух секционных заседаниях конференции были заслушаны доклады и сообщения 51 участников.

В конференции принял участие председатель Общества татарских краеведов РТ – начальник Комитета Исполкома ВКТ А.А.Бурханов.

* * *

4 апрель көнне Бөтендөнья татар конгрессында «Ирек мәйданы» клубының «Тарихи романнар һәм милли үзаң» темасына багышланган чираттагы утырышы узды. Чарада язучылар, галимнәр, милли сәясәтчеләр, татар зыялылары катнашты.

Гаять җитди һәм әһәмиятле бу сөйләшүдә клуб җитәкчеләре, тарихчы Дамир Исхаков, Римзил Вәлиев, язучылар Вахит Имамов, Фәүзия Бәйрәмова, Данил Салихов, Марат Әмирханов, Рәдиф Гаташ, Камил Кәримов, Солтан Шәмси, Галимҗан Гыйльманов, галимнәр Фәйзелхак Ислаев, Фәрит Яхин, милли сәясәтчеләр Руслан Айсин, Айрат Фәйзрахманов, журналистлар Рәмис Латыйпов, Рәшит Минһаҗев һәм башкалар чыгыш ясады.

Сөйләшү барышында тарихи романнарда милләт язмышы тасвирлануы, аларның милли аң формалашуга тәэсире зур булуы турында әйтелде.

* * *

С 19 по 21 апреля 2019 г. в г. Тара и г. Омске прошла Международная научно-практическая конференция «Татары Омского Прииртышья: историко-культурное наследие и их вклад в развитие региона».

Конференция проводилась в рамках подготовки к 75-летию Победы советского народа в Великой Отечественной войне и была посвящена 100-летию со дня рождения уроженца д. Яланкуль Большереченского района Омской области, видного отечественного историка и этнографа, доктора исторических наук, заслуженного деятеля науки Республики Татарстан Фоата Валеева и 90-летию со дня рождения учителя истории Уленкульской средней школы Большереченского района, известного краеведа Манвии Шиховой.

Первый этап конференции прошел на базе Тарского культурно-досугового центра «Север». Перед началом конференции гости и участники конференции посетили выставку «Быт сибирских татар», организованной Центром татарской культуры «Нур» ОНК Дома дружбы города Тара.

В рамках работы конференции состоялся круглый стол «Культура татар в этнической мозаике Омского Прииртышья на современном этапе».

В рамках проведения конференции в г. Тара состоялась презентация книг историка, краеведа, почетного гражданина Большереченского района М. Х. Шиховой «Село Яланкуль и его жители – потомки Авасбакы-шейха. Шаджара» (составители: З. А. Рахмангулова и С. Н. Корусенко. Омск, 2018) и местного поэта Р. Г. Якубовой «Сөю хакына» («Во имя любви»).

Прибывший из г. Казани председатель РОО «Общество татарских краеведов РТ» при ВКТ А. А. Бурханов передал в местную библиотеку и краеведам научные и научно-популярные книги по истории татар и Та-

тарстана. Затем А. А. Бурханов и Г. Г. Ахунжаков (Казахстан) в сопровождении одного из членов Оргкомитета Н. А. Мубарякова посетили татарское село Большие Туралы и Больше-Туралинскую СОШ, где состоялась встреча с главой сельского поселения А. Ю. Юнусовым и директором школы Л. Р. Гатауллиной. В библиотеку школы А. А. Бурхановым были переданы несколько книг по истории татар.

I этап Международной конференции в г. Тара завершился концертной программой с участием Народного татаро-башкирского фольклорного ансамбля «Умырзая» (г. Омск), Народного вокального ансамбля «Нур», детских вокальных коллективов «Йолдызчыклар» и «Якташ», гимнастки Элины Зимаковой (спортивно-танцевальная студия «Горошинки» –руководитель – С. М. Мурзалиева).

II этап конференции продолжился в городе Омске, где в областном Театре юного зрителя (ТЮЗе) состоялся большой торжественный вечер-концерт, посвященный 30-летию Народного татаро-башкирского фольклорного ансамбля «Умырзая» («Подснежник») с участием артистов и почетных гостей из Татарстана, Республики Казахстан, Турции, Дании, Финляндии и областей Сибирского региона.

* * *

30 апреля 2019 г. в с. Зиреклы (Ерыклы) Новошешминского района Татарстана, на базе Зиреклинского лицея и Музея народного творчества и быта, состоялась Всероссийская (с международным участием) научно-практическая, историко-краеведческая конференция на тему: «Человек и природа в бассейне рек Шешма и Кичуй. Татарские села Зиреклы и Утяшкино: проблемы истории и культуры».

На конференцию прибыли делегации из 12 районов Татарстана, как Высокогорский, Новошешминский, Рыбно-Слободский, Чистопольский, Балтасинский, Азнакаевский, Лениногорский, Сармановский, Мензелинский, Бугульминский, Тукаевский, Альметьевский. из гг. Казань, Альметьевск, Лениногорск, Чистополь, Нижнекамск, Азнакаево, Бугульма, Туймазы и Октябрьский Башкортстана. Участвовали граждане Афганистана: Асефи Мухаммад Шариф председатель РОО РТ «Единство Афганистана» и Асефи Фарит из Кабула, а также Сердар Абдуллаев из г. Мары (Туркменистан) – всего 69 участников.

Конференция работала в трёх секциях:

1, «Человек и природа в бассейне рек Кама, Шешма и Кичуй: история и современность», где с докладом выступили 7 человек.

2, «Проблемы региональной истории Центрального и Восточного Закамья», где выступили 11 человек.

3, Третья секция была посвящена историко-краеведческой работе и вопросам преподавания учебных дисциплин в школе, где были прослушаны 8 докладов.

По отзывам руководителей и участников секций все выступления были конкретными, деловыми, с результатом своих поисков и находок, отметили их результативность, что такое бывает редко на больших конференциях.

* * *

7 мая 2019 г. на базе Городского Дворца детского творчества им. А. Алиша города Казани состоялась Республиканская научно-практическая, краеведческая конференция учащихся «Хроника победы: освобождение», посвященная 75-летию освобождения территории СССР от немецко-фашистских захватчиков в 1944 г. Организаторы конференции школьников: Министерство образования и науки РТ, Республиканский Центр воспитательной работы, Управление образования Исполкома г. Казани, Музей-мемориал Великой Отечественной войны 1941–45 гг. Национального музея РТ, Общество татарских краеведов РТ при Всемирном конгрессе татар, Главная Редакция «Книги памяти» РТ и ГДДТ им. А. Алиша г. Казани.

В работе конференции приняли участие учащиеся школ и гимназий, активисты детских клубов и кружков при домах детского творчества районов гг. Казани, Бугульмы и Зеленодольска, Аксубаевского, Алькеевского, Алексеевского, Бугульминского, Высокогорского, Заинского, Зеленодольского, Пестречинского, Тюлячинского и Мамадышского районов Татарстана.

Работа конференции проводилась в формате пленарного, 7 секционных и итогового заседаний. В составе жюри и руководителей секций были известные специалисты по направлениям.

По решению Оргкомитета и Жюри победители и призеры были награждены Грамотами I, II и III степени, а также ценными подарками (книгами и дисками, связанными с историей Татарстана и татарского народа, Великой Отечественной войны и подвигами наших земляков на фронтах и тылу в годы ВОВ). Победители и призеры вместе с членами Оргкомитета затем поехали к Памятнику участникам ВОВ в г. Казани для возложения венка и цветов.

Принято решение о проведении конференции ежегодно.

* * *

7 мая 2019 г. в мечети «Миргазиян» г. Казани проводился ифтар, в котором участвовал главный редактор журнала «Туган җир. Родной край»

Д. М. Исхаков. В ходе мероприятия состоялось заинтересованное обсуждение проблемы исламского фактора при подготовке «Стратегии развития татарского народа».

* * *

2019-нчы елның 19 маенда Казан шәһәрендә инициатив төркем тарафыннан ата-аналар өчен иҗтимагый конференция оештырылды. Чарада Татарстанның төрле шәһәрләреннән һәм районнарыннан, Мәскәүдән, Пензадан, Мордовиядән, Мари Элдан галимнәр, укытучылар, иҗтимагый оешмалар һәм ата-аналар, барлыгы 70 кеше катнашты. Конференциядә ислам динен тотучы гражданнарның балаларының хокуклары, дини тәрбиянең җәмгыятькә уңай әхлакый йогынтысы, Татарстанның татар мәктәпләрен татар укыту теленә кайтару, ата-аналарның мәгариф өлкәсендәге хокуклары, милли(дини) тәрбиянең баланың киләчәгендә чагылуы, читтән торып укуның уңай һәм тискәре яклары һәм башка актуаль сораулар яктыртылды. Барлыгы 13 чыгыш тыңланды. Конференциядә «Туган җир. Родной край» журналының баш мөхәррире Д. М. Исхаков «Татар милләтенең үсеш стратегиясендә ислам диненең һәм милли мәгарифнең урыны» дигән темага чыгыш ясады.

* * *

## Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр

## Информация о краеведческих трудах. Рецензии

# О КНИГЕ Б. Р. РАХИМЗЯНОВА «МОСКВА И ТАТАРСКИЙ МИР: СОТРУДНИЧЕСТВО И ПРОТИВОСТОЯНИЕ В ЭПОХУ ПЕРЕМЕН, XV–XVI вв.» СПб.: Евразия, 2016. 396 с.




Монография Б. Р. Рахимзянова «Москва и татарский мир: сотрудничество и противостояние в эпоху перемен, XV–XVI вв.» рассматривает отношения Москвы и степи, содержит много новых наблюдений, например,

таких, как манипуляция московскими официальными лицами понятиями «дань» и «поминки» в отношениях со своими восточными соседями. Б. Р. Рахимзянов показывает, что Москва обладала всеми необходимыми навыками и умениями «игры» на позднезолотоордынской политической арене с позиций внутреннего участника событий. В работе позиция автора книги в вопросе татарского влияния на Московское государство не вполне ясна. Тем не менее эта монография является серьезным вкладом в понимание не только взаимоотношений Москвы и степи, но и Московского государства и татарского общества. Книга рассчитана на специалистов, но с ней могут ознакомиться и представители широкого круга читателей.

* * *

## О ПРЕЗЕНТАЦИЯХ КНИГИ ЗУФАРА МАХМУТОВА «ИСТОРИЯ ТАТАР КОКШЕТАУ И АКМОЛИНСКОЙ ОБЛАСТИ»



13 и 14 апреля в с. Имантау (Северо-Казахстанская область Республика Казахстан) и в г. Кокшетау (Акмолинская область Республики Казахстан) состоялись презентации книги Зуфара Махмутова «История татар Кокшетау и Акмолинской области». Автор монографии – старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани. Ранее увидели свет его труды по истории татар Петропавловска и Нур-Султана (Астаны).

В книге рассматривается история татар Кокшетау и Акмолинской области, их вклад в политическое, экономическое, демографическое, социальное и культурное развитие региона. Она написана на основе анализа широкого круга источников: статистических и документальных материалов, периодических изданий дореволюционного, советского и современного времени, интервью, воспоминаний, мемуаров жителей области. Данная работа стала продолжением комплексного исследования татар в разных регионах Казахстана.

## ТҮБӘН АБДУЛНЫҢ ДАНЛЫ ТАРИХЫ

*(Рецензия)*

Чал тарих өстендә утырган һәм бүгенге тормышы да шуңа лаек булган гаҗәеп татар авыллары бар, Әлмәт районындагы Түбән Абдул авылы әнә шундыйлардан. Хәер, бу авыл Шушма елгасындагы күпер аша Иске Бәгрәҗ авылы белән кушылып, халык телендә барысын Елховой, дип тә атап йөртәләр. Чирмешән районы чигенә урнашкан бу татар-мишәр авылы үзенең холык-характеры, аннан чыккан танылган шәхесләре белән дә данлыклы. Һәм, ниһаять, Түбән Абдул турында да тарихи-публицистик китап дөнья күрде, китап бик саллы – 415 биттән тора, яхшы кәгазьгә басылган, төсле фотолар белән баетылган, узган заманнарның сирәк документлары, карталары, шәҗәрәләре, кабер ташлары, халык авыз иҗаты урын алган. (Илдус Габдуллин, Әсгать, Миләүшә Закировлар. Түбән Абдул. – Казан, 2018.) Дөрес, аңа кадәр дә бу төбәк тарихы турында Әсгать Сәлаховның «Бараж токымы» һәм тарих фәннәре кандидаты Таһир Кәримовның «Нәселе барның – иле бар» дип аталган китаплары басылып чыккан иде. «Түбән Абдул» китабы исә үткәннәргә тагы да тирәнрәк үтеп керүе, аны шушы төбәк тарихы белән бәйләп, гомуммилләт тарихына әйләндерә алуы, күп материалларның фәнни әйләнешкә беренче тапкыр кертелүе белән дә кыйммәтле һәм кадерле.

Китапның үзенә анализ ясауга күчкәнче, иң беренче аның авторлары белән таныштырып үтәргә кирәк. Илдус Рәшит улы Габдуллин исеме тарихчыларга яхшы таныш, ул Әлмәт энциклопедиясен төзүчеләрнең берсе, Башкортстанның Чакмагыш авылында яши. Илдус Габдуллин аеруча мишәрләр тарихына һәм татарларны көчләп чукындырулар темасына зур игътибар бирә, шуңа күрә аның бу китапка автордаш булуып катнашуы гаҗәп түгел. Галим моңа кадәр дә «От служилых татар к татарскому дворянству», «Из истории Чекмагушевского района Республики Башкортостан», «Движение крещенных татар Альметьевского региона по возвращению в мусульманство», «Татары и башкиры в войнах с Францией в конце XVIII – начале XIX вв.», «Деревня Нижнее Абдулово Альметьевского района: к истокам рода Гаяза Исхаки», «Сравнительный анализ тамг населения Восточного Закамья (XVIII–XIX вв.)», «Аит Уразметов (новые штрихи к биографии)» кебек фәнни хезмәтләре белән укучыларга таныш шәхес. Бу китапта исә Илдус Габдуллин «На Мещерской земле», «Основание деревни», «Отпадение» в ислам крещенных татар Альметьевского региона», «Гаяз Исхаки и Альметьевский край: к истокам рода» һәм башка язмалары белән катнашкан. Күргәнебезчә, аның язмалары русча, китапның калган өлеше тулысынча диярлек татар телендә.

Илдус Габдуллин хезмәтләренә әле яңадан әйләнеп кайтырбыз, хәзер исә башка авторлар белән таныштыруыбызны дәвам итәбез.

Ирле-хатынлы Әсгать һәм Миләүшә Закировлар китапның төп авторлары булып торалар, күпчелек язмалар аларныкы, китапны төзүчеләр дә алар. Әсгать әфәнде шушы Түбән Абдул авылында туган, Елховой урта мәктәбен тәмамлап, алга таба укуын Бөгелмәдә дәвам иткән. Без аның әле туксанынчы елларда ук Бөгелмә телевидениесенең татар редакциясендә эшләвен, ә инде 2003-нче елда Бөгелмәдә «Сандугач» дип аталган татар радиосы оештырып, шуны җитәкләвен хәтерлибез. Әсгать Закиров шулай ук «Уртабызда шәм яна» (2000 ел), «Офык» (2003), «Глюк түгел, чынбарлык» (2016) китаплары авторы да. Бүгенгесе көндә ул җәмәгате Миләүшә ханым белән берлектә татар шәҗәрәләрен төзү белән шөгыльләнә, алар инде йөздән артык милләттәшебезгә нәсел тарихларын торгызырга ярдәм иткәннәр. Әсгать һәм Миләүшә Закировларның уртак хезмәтләре булып төбәк тарихын өйрәнү буенча чыккан җыентыкларын – «Вакыт дәрьясында Иске Үтәмеш», «Тойгелде: җуелмас тарих», «Үтәмеш. Буыннар чылбыры» китапларын әйтеп китәргә кирәк. Шулай ук алар «Татарский центр радоведения» сайтын да булдырдылар. Ягъни, «Түбән Абдул» китабына тотынганда аларның инде төбәк тарихын өйрәнү буенча бай тәҗрибәләре була һәм бу хезмәтнең уңышлы чыгуына нигез булып тора.

Китапта шулай ук Әлмәт төбәге тарихын өйрәнүче журналист, милләтпәрвәр Дамир Таҗиевның да «Түбән Абдул мәчетләре», «Иске Баграж-Елховой мәчетләре» дип аталган язмалары урын алган. Аның шушы яклар тарихы турында саллы кулъязма хезмәтен дә заманында укырга һәм кереш сүз язарга туры килгән иде, әмма ул әле һаман китап булып дөнья күрмәде. Шуңа күрә Дамир Таҗиның Түбән Абдул-Елховой авылы мәчетләре, аларның имамнары турында язмасын, тарихи фотоларын бу китапка бирүе хезмәтне тагы да баеткан, күпкырлы иткән. Әлмәт шәһәрендә яшәүче милләттәшебезнең алга таба үз китабын да көтеп калабыз!

Инде «Түбән Абдул» китабының үзенә килик. Авторлар авыл тарихына күчкәнче, гомуммилләт, борынгы төрки-татар тарихына тирән анализ ясаганнар, аеруча мишәрләрнең килеп чыгышы турында күп мәгълүмат биргәннәр. Бу тарих Нух пәйгамбәр заманнарыннан ук башлана, төрки каганатлар аша, болгар-буртас чорларына килеп җитә, бу күзәтүләр Альфред Халиков, Марсель Әхмәтҗанов, Нурихан Фәттах, Фәүзия Бәйрәмова, Вахит Имамов, Дефак Рәхмәти һәм башкаларның фикерләре белән ныгытылган. Мисал өчен, моннан егерме ел элек Әлмәт төбәге кабер ташларын өйрәнгән галим Марсель Әхмәтҗанов болай дип язган:

«Мөселман татарлар Әлмәт төбәгенең төп халкы булып торалар. Аларның асыл бабалары бу җирләрдә инде борынгы Төрки каһанлык чорларында ук (VI–VII йөзләрдә) гомер иткәннәр. Төбәктә шул ерак гасырлардан килгән һәйкәлләр дә саклана икән. Аның кызыклы үрнәге, борынгы төркиләргә бәйле булган бер таш балбал сыны рәвешендә, Түбән Абдул кырында бүген дә тора» («Түбән Абдул» китабында 19-нчы биттә).

Чыннан да, авыл янындагы тугайлыкта бар андый Торататш сыны, ул монгол далаларындагы һәм Хакасия-Тыва җирләрендәге таш балбалларга охшаган. Шулай ук мин Түбән Абдул авылы музеенда таштан ясалган бик зур кеше башы да күрдем, аның янына 668 ел, дип язып куелган иде. Хәтерем ялгышмаса, аны да, шулай ук музейдагы мөгезборын һәм бизон сөякләрен дә Шушма елгасы буеннан тапканнар. Бу үзе үк биредә меңнәрчә еллар элек тормыш барганлыгын күрсәтә. Ә «Изгеләр зираты»ндагы кабер ташлары исә, галим Марсель Әхмәтҗановның язуынча, Алтын Урда чорына карый икән. Китап авторлары язуынча, аларның бабайлары бирегә Тау ягыннан да күчеп утырганнар, «Түбән Абдул – чиста мишәрләрдән торган авыл. Бу метрикалар, «Ревизские сказки» кебек документлар белән раслана», – дип ассызыклый алар.

Рәсми чыганакларда, шул исәптән, «Татар энциклопедик сүзлеге»ндә (2002) һәм «Населенные пункты Республики Татарстан» китабында (1997), Түбән Абдул һәм Иске Бәгрәҗ-Елховой авылларына нигез салу вакыты итеп 1730-нчы еллар күрсәтелгән, әмма бу дөреслеккә туры килми. Моңа каршы Алтын Урда чорыннан калган кабер ташлары да, фәнни әйләнешкә кертеп җибәрелгән кайбер яңа чыганаклар да дәлил булып тора. Илдус Габдуллин мәкаләсендә дә бу җирләрнең Петр патша тарафыннан 1697–1698 елларда ук йомышлы татарларга бүләк итеп бирелгәне әйтелә. Инде 1745-нче елда ук Түбән Абдулда 63 ир-ат яшәгән икән, моңа тагы шуның кадәр хатын-кызларны һәм дистәләгән балаларны да кушсаң, ул вакыт өчен шактый зур сан килеп чыга. Димәк, бу җирләр йомышлы татарларга, мишәр морзаларына авыллары белән бергә бирелгән, ягъни, Түбән Абдул һәм Елховой җир бүләк ителгәч кенә барлыкка килмәгән, ахыры. Авторларның язуынча, «Түбән Абдул авылына 13 төрле авылдан күченеп төпләнеп калган 44 баш баба нигез салган». Китапта ул авылларга һәм ул «баш бабаларга» да шактый зур урын бирелгән, өстәмә материал җитәрлек. Әмма кайвакытта бу өстәмә материал артык күбәеп тә китә кебек, ул китапны кабул итүне авырайта.

Әмма бу илдә син мишәр морзасы булсаң да, йомышлы татар булсаң да, җирләрне сиңа патша үзе бүләк итсә дә, бары тик чукынып христиан динен кабул итсәң генә бу милекне үзеңдә калдыра аласың. Һәм бу афәт Түбән Абдул өстенә дә килә, халыкның бае-ярлысы җирсез генә

түгел, иманын да югалту куркынычы астында кала. Архив документларыннан күренгәнчә, XIX гасыр башында инде Түбән Абдулда (Степановка) яңа чукындырылганнардан 72 ир-ат, 70 хатын-кыз теркәлүе билгеле. Янәшәдәге Иске Бәгрәҗ-Елховода алты йортта яңа чукындырылган 8 ир-ат, 6 хатын-кыз яшәгән. Әлбәттә, болар барысы да татар-мишәрләр булган, һәм алар барысы да үз теләкләреннән башка көчләп чукындырылган. «Новокрещены же деревень Нижнее Абдулово и Старый Багряж-Елхово (из тех же служилых татар) были христианизированы в период действий в Поволжье Конторы новокрещенских дел в 1740–1750-х гг. На территории Альметьевского региона миссионеры побывали в начале 1740-х гг., когда были разрушены мечети в деревнях Нижнее Абдулово и Старый Багряж-Елхово», – дип яза тарихчы Илдус Габдуллин бу хакта.

Әлбәттә, көчләп чукындырылган бу татарларның күпчелеге кәгазьдә генә керәшен була, ә үзләре кача-поса да, ачыктан-ачык та ислам динен тотуны дәвам итә. Әйтик, Түбән Абдул авылыннан Елена Дорофеева (Колшәрипова) сорау алганда үзенең ислам дине йолаларын үтәвен, урыс динен бөтенләй белмәвен, балаларының да мулла кушкан исем белән яшәүләрен, иренең икенче хатыны булуын да әйтә. Авыл халкы ике исем, ике дин, ике тормыш белән яшәргә мәҗбүр ителсә дә, барыбер үзенекенә тарта – үлем, сөрген куркыныч астында булса да, үз динендә – исламда кала. Моңа урыс поплары да игътибар итә һәм алар өстеннән әләкне яудырып кына тора:

«Характеризуя альметьевских крещенных татар, приходской священник в своем докладе епископу Самарскому и Ставропольскому Феофилу пишет, что они «бросили православие так, что трудно отличить их от татар не только по внутреннему, но и внешнему образу их жизни… В какой дом не войдешь, везде видна обстановка татарская, спросишь ли имя хозяина, он с трудом назовет себя и нередко другим именем, не говоря уже о их семейных. Крестов на себе не носят, креститься не умеют, говорить по-русски тоже, постов не соблюдают, едят лошадиное мясо, держат татарскую уразу, ходят в мечеть, одним словом не крещенные татары» (Китапта – 51-не бит).

Әлбәттә, бу татарлар рәсми рәвештә дә исламга кайту өчен барысын да эшләп караган, ә ул бик катлаулы булган, хәтта патша фәрманыннан яки суд карарыннан башка мөмкин дә булмаган. Инде бу хәлләргә чыдый алмаган Түбән Абдул халкы 1845-нче елда үзләрен мөселман дип игълан итәләр һәм мәчет салырга тотыналар. Бу мәкруһ татарларга каршы тикшерү эшләре башлана, халык моңа җавап итеп баш күтәрә, казыкка тотына. Хөкүмәт аларны бастыру өчен көч куллана, авыл халкының бер өлешен 1849-нчы елда, патша фәрманы белән, Чиләбе төбәгендәге

урыс авылларына һәм Бөгелмә өязе христианнары арасына көчләп күчерәләр. Илдус Габдуллинның язуынча, татарлар монда да үзләренекен бирмиләр – ислам динендә калалар. Әле 1905-нче елгы дин иреге турында патша указы чыкканчы ук, Түбән Абдул авылының күпчелек халкы ислам диненә кайтып беткән була инде.

Чукындыру темасына китапта тагы бер мәгълүматлы язма бар, ул – шул чорда яшәгән М.Гребневның «Нижнее-Абдуловские, Старо-Багряжские и Беркет-Ключские татары вероотступники» дип атала. Гребнев Түбән Абдул (Степановка) авылында христиан диненнән чыккан йөз кеше барлыгын хәбәр итә, аларга карата 1851-нче елны чиркәү суды башланып китүен әйтә. Урыс побы Спиридонов Түбән Абдулда була, халык белән очраша, әмма татарлар аңа авыз ачарга да ирек бирмиләр, үзләрен чын мөселманнар, диләр, попның әйтүе буенча, аны мыскыл итәләр һәм ташлап чыгып китәләр. Спиридонов бу авыл халкын яманлап, «... крестьяне д. Нижнее-Абдулово буйного характера, издавна промышляли грабежом и наездничеством (своего рода спорт)», – дип әләкли (Китапта – 57-нче биттә). Һәм ул губернаторларга, епископларга язып, христиан диненнән кайткан татарларны җир читенә – Амур буйларына, кыргыз-кайсак далаларына сөрүне сорый, «алар янына бер мулла да барып җитәрлек булмасын», – ди. Әмма бу хәл инде 1863-нче елларда була, патша хөкүмәте дә үзенең мөселман-татарларга карата алып барган ялгышларын аңлый башлый. «Бу холыксыз, усал татарларны каядыр сөрергә түгел, үз телләрендә урыс динен укытып, чиркәүгә тартырга кирәк», – дигән фикергә киләләр. Әмма тарих күрсәтте – аларның бу планнары да барып чыкмый, татар үз теленнән, үз диненнән аерылмый, Түбән Абдул һәм Иске Бәгрәҗ-Елховой авылы халкы да үз милли һәм дини хокукларын әнә шулай көрәшеп яулап алалар, шулай сакланып калалар.

Авыл тарихының һәр чорына диярлек китапта аерым бүлек бирелгән – монда патша армиясендә хезмәт иткән мишәрләрнең исемлеген дә, дингә, мәчетләргә, имамнарга багышланган зур-зур язмаларны да күрергә була. Шулай ук дәһшәтле ачлык еллары турында тетрәндергеч хатирәләрне дә, репрессия-золым корбаннары турында да, канкойгыч сугыш, сугыштан соңгы авыр еллар, авылның әкренләп күтәрелүе, җир тетрәтеп эшләгән данлы ир-егетләре һәм хатын-кызлары, җитәкчеләр, укытучылар, Түбән Абдулдан чыккан танылган кешеләр – барысы хакында да бик тулы мәгълүмат, кызыклы язмалар бар. Түбән Абдул авылының элеккеге җир-су атамалары, кушаматлар, халык авыз иҗаты үрнәкләре, тел-милләт тарихы, халыкның бүгенге хәле турында да рәхәтләнеп укырга була. XVIII–XIX гасырлардагы бөтен ревизия материалларыннан башлап, йомышлы татарларның һәм морзаларның исемлеге, бөтен сугышларда

катнашучыларның исемлеге, сугыш вакытында алып барган хуҗалык кенәгәләрендәге исем-фамилияләргә хәтле бирелгән. Бу – Илдус Габдуллиннан да, Әсгать һәм Миләүшә Закировлардан да бик күп көч һәм вакыт таләп иткән, алар аны югары дәрәҗәдә башкарып чыга алганнар.

Әйткәнебезчә, авылның дин тарихына аерата нык игътибар бирелгән. Патша заманында ислам дине никадәр кысылса да, 1917-нче елга кадәр Түбән Абдулда өч мәчет була, һәрберсе каршында мәдрәсә эшләп тора. Әйтик, 1913-нче елда беренче мәдрәсәдә 74 ир бала укый, икенчесендә – 71, өченчесендә 106 үсмер белем ала, китапта аларның барысының да исемлекләре бирелгән. Совет чорында бу мәчет-мәдрәсәләрнең барысы да ябыла, муллалар хөкем ителеп, сөргенгә сөрелә. Нинди чор булса да, авыл халкы динне ташламый, үзгәртеп корулар башлангач, 1989-нчы елда Әлмәт районында беренче мәчет шушы Түбән Абдул авылында ачыла. Хәзер авылда ике мәчет, янәшәдәге Иске Бәгрәҗ-Елховойда өч мәчет бар. Түбән Абдулда әле 1961-нче елда ук ачылган гаҗәеп «Авыл тарихы музее» барлыгын, Елховойда урта мәктәп эшләп торуын да әйтеп үтәргә кирәк. Бу төбәк үзенең тарихы, мәдәнияте һәм мәгърифәте, традицияләре, хәтта холык-фигыле белән дә аерылып тора. Юкка гынамы алардан хәтта патша хакимияте дә куркып торган, ә урыс поплары Түбән Абдул белән Иске Бәгрәҗ-Елховойны әйләнеп үтә торган булганнар...

Китапта авылдан чыккан танылган кешеләргә дә шактый урын бирелгән, ә алар күп һәм бөтен дөнья буйлап таралганнар. Әйткәнебезчә, Гаяз Исхакыйның да нәсел тамырлары Түбән Абдулга барып тоташа икән. Тарихчы Илдус Габдуллин 1834-нче елгы ревизия материалларына таянып, Гаяз Исхакыйның бабасы Исхак Мөхәммәтшәриповның 1807-нче елда Түбән Абдулда тууын исбатлый, 1851-нче елда ул күрше Лашман авылында имам булып тора. Аның улы – Гыйләҗетдин, Гыйләҗетдиннең улы – Мөхәммәтгаяз Исхаков. Бу борынгы мишәр морзалары нәселе Түбән Абдулга XVIII гасыр урталарында хәзерге Буа районының Яңа Суыксу авылыннан күчкән булалар, ул чагында Измайловлар фамилиясен йөртәләр. Кыскасы, Гаяз Исхакыйның дүрт буын ата-бабалары Түбән Абдул авылында яшиләр, ул чагында ук милләт юлбашчылары булалар, биредә хәзер дә Исмәгыйлевләр фамилиясен йөртүчеләр арасында нәсел дәвамчылары бар.

Түбән Абдул-Елховойдан чыгып, дөнья буйлап таралган, дан-шөһрәт казанган татар-мишәрләр бихисап, алар арасында генераллар да, академиклар да, язучылар да, хөкемдарлар, дин әһелләре дә бар. Шулардан Әхмәтшин Равил – генерал-майор, юридик фәннәр кандидаты, Татарстанның Премьер-министр урынбасары, Татарстан Республикасының Рәсәй Федерациясендә тулы вәкаләтле вәкиле; Әхмәтшин Рафаэль – эчке

эшләр полковнигы, хәрбиләштерелгән янгын саклау отряды башлыгы; Салахов Ильяс – Халыкара Фәннәр академиясе академигы, Идел дәүләт су транспорты университетының Казан филиалы директоры, шушы китапны чыгаруны үз өстенә алган хәйрияче; Шәрифуллин Риф – Татарстан Республикасының атказанган юристы, 40 еллык судьялык стажының 25 елы – Татарстан Республикасы Югары суды рәисе урынбасары; язучылар – Ләбиб Гыйльми (репрессия корбаны), Әсгать Салах, Әхмәт Сәхапов, Сирень Якубова... Авылның үзенең рәссамнары да булган, алар – Түбән Абдул музеена нигез салучы һәм аны озак еллар җитәкләүче Хәлиулла Әхмәтшин һәм Рәшит Хәсәншин. Ә танылган дин әһеле, элеккеге хәрби, милләтпәрвәр, Казанның Кабан арты мәчетен кире кайтарып алган һәм анда имам булып торган, татар тарихы буенча күчле хезмәтләр язып калдырган Исхак хәзрәт Лотфуллинны белмәгән кеше юктыр, мөгаен, ул да шушы Елховой кешесе бит! Китапка кереп өлгермәгән, әмма үзем өчен бик якын булган тагы бер шәхесне әйтеп узмасам, язмам тулы булмас кебек. Ул – Елховойның булдыклы, иманлы, үткен мишәр кызы Рәйхана Ханнанова. Рәйхана ханым Әлмәттә ире белән «Тәскирә» мәчетен, «Айгөл» хәләл кафесын төзетте һәм тота, Кама аръягы мөслимәләре оешмасының җитәкчесе булып тора, төбәктә берсеннән-берсе кызыклы һәм кирәкле чаралар оештыра. Мине җитәкләп Елховой авылына алып кайтучы, аның мәчетләрен күрсәтеп йөрүче, Түбән Абдул авылы музее белән таныштыручы да ул булды, шуңа күрә, үз күзләрем белән күргәч, миңа бу китапка күзәтү ясау да җиңел.

Китапны бастыруда иң зур матди ярдәм күрсәтүчеләр – Салахов Ильяс Рәхимҗан улы һәм шулай ук ООО «Нефтестройэнерго» директоры Якупов Дамир Наил улы, авылдашлары Насыйров Гали Рәфгать улы булганнар. Күрәсез, мишәр морзаларының затлы нәселе бүген дә милләт мәйданында ат уйната, авылны гына түгел, нефть төбәген дә үз кулында тотып тора. Һәм алар турында китап та нәкъ менә шушындый – бай эчтәлекле һәм затлы булып чыгарга тиеш иде. Шулай булган да! Афәрин, егетләр, авылдашларыгыз кулына яхшы китап тоттырдыгыз, ә без аны бөтен милләт байлыгы итеп кабул итәбез.

*Фәүзия Бәйрәмова,*
*язучы, тарих фәннәре кандидаты.*

## Хушлашу

### Некрологи

### МИЛЛӘТНЕҢ АК БАЕ
### (некролог)

Татар дөньясында яхшы билгеле булган милләттәшебезнең – Эдуард Әнвәр улы Ганиевның кырыгы да узып китте, дөнья куласасы әйләнешен дәвам итә...

Эдуард әфәнде белән озак кына вакыт аралашып (БТКның Башкарма комитеты президиумы әгъзалары буларак та, төрле иҗтимагый эшләрне үтәгәндә дә) яшәргә туры килгәнлектән, мин безнең заман өчен шактый дәрәҗәдә уникаль булган бу шәхес турында, аның якты истәлегенә багышланган сүземне халыкка җиткерергә булдым. Кызганыч ки, татарлар, яһүдләрдән аермалы буларак, бер-берсенең кылган яхшылыклары, җәмгыять өчен башкарылган хезмәтләре турында сөйли белмиләр. Ә мондый хәтирәләр һәм язмалар бик кирәк, чөнки кемнең кем булганын халкыбыз да аера белергә тиеш.

Эдуард Әнвәр улы белән аралашудан сакланып калган төп хис – аның тыйнак, күп сөйләшмәүчән, бер дә мактаганны яратмаучы кеше булганлыгы турында. Әмма, «Гексар» ЯАҖ предприятиесенең генераль директоры һәм Ульян өлкәсе Иске Кулатка районы башлыгы, электротехника фәннәре докторы дәрәҗәле Әнвәр әфәнде күпне күргән, югары кәнәфиләрдә утыручылар белән аралашкан бизнесмен буларак, чынлыкта бер дә гади генә шәхес түгел иде. Шуңа күрә дә аның авызыннан кайбер очракларда Татарстанга яисә Мәскәү сәясәтенә кагылган үтә дә конфидинциаль мәгълүмат та ишетергә мөмкин иде. Гадәттә, андый әйберләрне ул бер дә ашыкмыйча әйтеп, сүз арасында кыстырып җибәреп, берәр әһәмиятле сәяси фигурадан ишеткәнлеге турында да өстәп бирүне хуп күрде.

Әле дә хәтеремдә – Бөтенроссия татар фольклоры фестивале «Түгәрәк уен» беренче мәртәбә Иске Кулаткада Әнвәр әфәнде ярдәме белән үтте. Бәлки, бу юнәлештә хәрәкәт итүенең бер сәбәбе – аның җиде ел буенча укытучы булып, аннан дүрт ел рәттән район мәдәният бүлегендә эшләгәнлегеннән килгәндер. Аның авызыннан еш кына «җыр-моң аша телебезне саклаганбыз, телебез аша без динне дә саклыйбыз», – дигән сүзләрне ишетергә туры килде.



Ә татар халкын, ислам динен якын итүе, яратуы – нәселдән килгән дип уйларга урын бар. Аның үзенең сөйләве буенча, Мәликә атлы әбисе бик укымышлы кеше, остабикә булып, Коръәнне яттан белгән (Уральск шәһәрендә абыйлары белән бергә мәдрәсәдә белем алганлыгы да билгеле). Ул әби Мосеевка авылындагы мәдрәсәдә хатын-кызларга дин сабаклары биреп, мөгаллимә булып эшләгән. Атасы ягыннан да Эдуард Әнвәр улының әби-бабалары дини һәм тәрбияле булганнар. Бу сыйфатлар гаиләләрендә дә дәвам иткән. Инде күптән билгеле – кешенең нинди булганлыгы гаилә белән бәйле, моны Э. Ә. Ганиев мисалында да күрә алабыз.

Аннан соң, гаиләдән килгән тагы бер әһәмиятле нәсихәт – Эдуард әфәнденең әнисе улына әйтә торган булган: «Сорап килгән кешене кире борма, булдыра алганча булыш аңа», – дип. Ананың васыятен ул гел истә тотып яшәде. Бик күпләргә билгеле булганча, Э. Ә. Ганиев зур меценат-

лык эше алып барды: мәчет-мәдрәсәләр салу, мәктәп-балалар бакчаларын, шифаханәләрне төзекләндерү, газ кертү дисеңме, мәктәп китапханәләренә китаплар кайтару, компьютер, транспорт белән тәэмин итү, хажга җибәрү, зиратларны төзекләндерү, төрле төбәк конференцияләрен уздыру һ.б. Ул район башлыгы булган дәвердә Иске Кулаткада егерме фатирлы йорт төзү дә шул ук рәткә кертелә ала. Болар барысы да аның тарафыннан чын мөселман буларак, зәкәт бирү таләбен үтәү йөзеннән эшләнгән саваплы эшләр. Ә бит нәкъ шул юлдан баручылар элек-электән халкыбызда «Ак байлар» буларак билгеле булганнар.

Әнвәр әфәнде милләтебезнең чын «Ак бае» иде, моны аның туган ягында да, башка татар җирлегендә дә яхшы беләләр, гел искә алалар. Мин үзем дә Казан шәһәренең 15-нче татар гимназиясендә Бишбалта (Адмиралтейство) тарихи-этнографик музеен төзегәндә аның ярдәмен күрдем. Шундый ук ярдәм турында – татар теленә багышланган конференция үткәргәндә, милләтебезнең танылган журналисты Руслан Айсин да сөйләгәне бар. Чынлыкта мондый хәйрия эшләрен Эдуард Әнвәр улы бик күп тапкырлар башкарган. Андый кешеләрне халкыбыз бервакытта да онытмый, милләтебезнең хәтер сандыкларында фәкать тик Ак байлар исемлегенә кергән шәхесләр генә сакланып кала. Үзләре өчен генә яшәгән Кара байлар аннан юыла, юкка чыга.

Эдуард әфәнде турында хәтер халкыбызда озак вакытлар сакланыр дип уйлыйм

*Дамир Исхаков,*
*тарих фәннәре докторы,*
*журналның баш мөхәррире.*

## Авторлар буенча белешмә

**Абукин Динар Марсель улы**, Төмән өлкәсе һәм себер татарларының МММ төбәкара иҗтимагый оешмасының Химаячеләр Идарәсе рәисе, Төмән шәһәре татарларының «Себертатарлар» МММ җирле иҗтимагый оешмасы Советы рәисе, Себер татарлары стратегиясен булдыру төркеме инициаторы һәм аның җитәкчесе.

**Айсин Руслан Валерьевич**, политолог.

**Биккинин Ирек Дамир улы**, шәхси эшмәкәр, төбәк тарихын өйрәнүче, журналист, юрист.

**Борһанов Альберт Әхмәтҗан улы**, тарих фәннәре кандидаты, профессор, ТР «Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте» рәисе, Гомумтатар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте Советы рәисенең беренче урынбасары.

**Бугарчёв Алексей Игоревич**, ТФА А. Х. Халиков исемендәге Археология институтының кече фәнни хезмәткәре.

**Бәйрәмова Фәүзия Әүхади кызы**, тарих фәннәре кандидаты, язучы, җәмәгать эшлеклесе.

**Габдуллин Илдус Рәшит улы**, тарихчы, төбәк тарихын өйрәнүче, «Әлмәт энциклопедиясе» иҗат төркеме инженеры.

**Газизов Радик Рәвкәт улы**, Самара округының аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү буенча «Яктылык» муниципаль белем бирү учреждениесе директоры.

**Гарифянова Миләүшә Рамиль кызы**, Кукмара муниципиаль районының МБГББУ «Псяк урта мәктәбе» укучысы.

**Измайлов Искәндәр Лерун улы**, тарих фәннәре докторы, ТФАның А. Х. Халиков исемендәге Археология институтының баш фәнни хезмәткәре.

**Искәндәров Гаяр Әхмәт улы**, «Мөселман халыклары үсеше фонды» иҗтимагый оешмасы рәисе.

**Исмәгыйлева Фәйрүзә Салихҗан кызы**, психология фәннәре докторы, профессор, Словения республикасы Любляна университетының визит-профессоры һәм чакырылган тикшеренүче.

**Исхаков Дамир Мәүләви улы**, тарих фәннәре докторы, РТФА академигы, БТК Милли Шура әгъзасы, журнал мөхәррире.

**Лотфуллин Марат Вазыйх улы**, «Мәгариф» ассоциациясе президенты.

**Мәхмүтов Фәрхәд Сабирҗан улы**, «Туган тел» Самара өлкәсе татарлары җәмгыяте директоры, Самара өлкәсе ТМММ башкарма директоры.

**Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы**, филология фәннәре докторы, доцент, ТФАның Г.Ибраһимов ис. ТӘСИның баш фәнни хезмәткәре, гыйльми совет әгъзасы.

**Надиров Азат Камил улы**, «Туган тел» Самара өлкәсе иҗтимагый оешмасы ветераны, Бөек Ватан сугышы ветераны – тыл хезмәтчәне.

**Нәбиуллин Фәнис Масабих улы**, табиб, психогенетик, гаилә-туганлык системалары буенча белгеч.

**Сибгатова Эльза Минәхмәт кызы**, төбәк тарихын өйрәнүче, педагогика хезмәте ветераны.

**Степанов Олег Витальевич**, нумизмат-тикшерүче, туган якны өйрәнүче, БТК каршындагы Гомумтатар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте идарәсе әгъзасы.

**Сяпуков Рәшид Жәфәр улы**, Мәскәүнең Люблино районы ТҖМММ иҗтимагый оешмасы рәисе.

**Таҗиев Дамир Нәзир улы**, РФ Журналистлар берлеге әгъзасы, Р.Төхфәтуллин исемендәге бүләк иясе, Әлмәт төбәгенең җәмәгать эшлеклесе, төбәк тарихын өйрәнүче.

**Фәткуллин Фәрит Миңнулла улы**, «Кызыл таң» гәҗитенең әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

**Хәйретдинов Айдар Гарәфетдин улы,** фәлсәфә фәннәре кандидаты, доцент, ТФАның Ш.Мәрҗани ис. Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре.

**Шәйхиева Гөлназ Фирдинат кызы**, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Мәгълүмати хезмәт һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә идарәсе җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

**Яхин Фәрит Зәки улы**, филология фәннәре докторы, профессор, ТФАның Г.Ибраһимов ис.ТӘСИ бүлеге мөдире.

**Әмирханов Рәфыйк Хәзыйм улы**, Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе, «Әлмәт энциклопедиясе» иҗат төркеме җитәкчесе, төбәк тарихын өйрәнүче.

## Сведения об авторах

**Абукин Динар Марсельевич,** председатель Попечительского Совета РОО НКА сибирских татар и татар Тюменской области, председатель Совета МОО НКА татар города Тюмени «Себертатарлар» (Сибирские татары), инициатор и руководитель группы создания Стратегии сибирских татар.

**Айсин Руслан Валерьевич**, политолог.

**Амирханов Рафик Хазимович**, заслуженный нефтяник РТ, руководитель творческой группы «Альметьевская энциклопедия», краевед.

**Байрамова Фаузия Аухадиевна**, кандидат исторических наук, писательница, общественный деятель.

**Биккинин Ирек Дамирович**, индивидуальный предприниматель, юрист, журналист, краевед.

**Бугарчёв Алексей Игоревич**, младший научный сотрудник Института археологии им. А. Х. Халикова АН РТ.

**Бурханов Альберт Ахметжанович**, кандидат исторических наук, профессор, заслуженный деятель науки РТ, первый заместитель председателя Совета ВОК, председатель РОО «Общество татарских краеведов» РТ.

**Габдуллин Илдус Рашитович**, историк-краевед, инженер творческой группы «Альметьевская энциклопедия».

**Газизов Радик Равгатович**, директор МБОУ «Школа «Яктылык» с углубленным изучением отдельных предметов городского округа Самара.

**Гарифянова Миляуша Рамилевна**, Ученица 8-го класса МБОУ «Псякская средняя школа» Кукморского муниципального района.

**Измайлов Искандер Лерунович**, доктор исторических наук, главный научный сотрудник Института археологии им. А. Х. Халикова Академии наук Республики Татарстан.

**Искандяров Гаяр Ахметович**, председатель Общественной организации «Фонд Развития Мусульманских народов».

**Исмагилова Файруза Салихджановна**, доктор психологических наук, профессор, приглашенный исследователь и визит-профессор Люблянского Университета, Республика Словения, г. Камник.

**Исхаков Дамир Мавлявеевич**, доктор исторических наук, академик РАЕН, член Национального Совета Всемирного конгресса татар, редактор журнала.

**Лотфуллин Марат Вазыхович**, президент Ассоциации «Мәгариф».

**Махмутов Фархад Сабирзянович**, директор Самарского областного татарского общества «Туган Тел» и исполнительный директор Самарской областной татарской национально-культурной автономии.

**Мухаметзянова Лилия Хатиповна**, доктор филологических наук, доцент, главный научный сотрудник ИЯЛИ имени Г. Ибрагимова АН РТ, член ученого совета.

**Набиуллин Фанис Масабихович**, врач, психогенетик, специалист по семейно-родовым системам.

**Надиров Азат Камилович**, ветеран СОТО «Туган тел», ветеран Великой Отечественной Войны – труженик тыла.

**Сибгатова Эльза Минахметовна**, краевед, ветеран педагогического труда.

**Степанов Олег Витальевич**, исследователь-нумизмат, краевед, член Совета Всетатарского общества краеведов Всемирного конгресса татар.

**Сяпуков Рашид Жафярович**, Председатель МОО ТНКА р-на Люблино г. Москвы.

**Тазиев Дамир Назирович**, краевед, член Союза журналистов РФ, лауреат премии имени Рафаила Тухватуллина, общественный деятель г. Альметьевска.

**Фаткуллин Фарит Миннуллович**, заведующий отделом литературы и искусства газеты «Кызыл таң», заслуженный работник культуры Башкортстана и Татарстана.

**Хайрутдинов Айдар Гарифутдинович**, кандидат философских наук, доцент, старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани АН РТ.

**Шайхиева Гульназ Фирдинатовна**, руководитель Управления информационной службы и связям СМИ Всемирного конгресса татар.

**Яхин Фарит Закиевич**, доктор филологических наук, профессор, заведующий отделом ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ.

# ИНФОРМАЦИЯ ДЛЯ АВТОРОВ

Редакционный совет журнала «Туган җир/Родной край» сообщает что к публикации принимаются статьи и материалы как на татарском, так и на русском языках. В этой связи обращаемся ко всем заинтересованным в развитии указанного журнала авторам с предложением принимать участие в его издании. Для этого необходимо подготовить и направить соответствующие статьи в наш адрес.

Рекомендуемая тематика публикаций:

- методика и методология историко-краеведческих исследований;
- история краеведения и историко-краеведческое наследие;
- проблемы региональной истории;
- новые археологические, нумизматические, фольклорные и эпиграфические находки;
- публикация источников;
- история конкретных сел и деревень;
- история музеев и публикация музейных коллекций;
- жизнь и деятельность выдающихся краеведов и земляков;
- использование краеведческих материалов и музейных коллекций в школе;
- популярные статьи по краеведению;
- краеведческая хроника (конференции, встречи и т.д.);
- рецензии, обзоры книг на краеведческую тематику.

Статьи оформляются согласно указываемым ниже требованиям:

### *Технические требования к оформлению статей*

1. *Внутри публикаций ссылки оформляются следующим образом* [Аминов 2017. С. 82.]*;* [Денисов 2012. С. 25; Черкас 2005. С. 16.]; [ГАОО. Ф 476. Оп. 3. Ед. хр. 609. Л. 6.]
2. Список использованной литературы оформляются согласно ГОСТу и приводятся в алфавитном порядке в конце статьи в виде нумерованного списка:

### *Источники и литература*

1. Аминов Р. Р. Татары-казаки в составе Оренбургского казачьего войска (1748–1917 гг.). Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2017. – 348 с.
2. Государственный архив Оренбургской области (ГАОО). Ф. 98. Оп. 2. Ед. 25.
3. ГАОО. Ф. 98. Оп. 2. Ед. 26.

4. *Денисов Д. Н.* Очерки по истории мусульманских общин Оренбургского края (XVIII – начало XX в.). М. – Н. Новгород: Издательский дом «Медина», 2012. – 410 с.
5. Черкас Т. Г. Хронограф города. Орск: [Б.и.], 2005. – 67 с.

***Редакционные требования к оформлению*:**

Инициалы и фамилия автора указываются справа, далее по центру публикации идет название статьи.

1. Текстовый редактор – Microsoft Word, в формате doc или docx.
2. А 4.
3. Поля: слева – 3 см., справа –1,5 см. сверху и снизу – 2 см. Нумерация страниц снизу справа.
4. Шрифт – Times New Roman
5. Размер шрифта – 14
6. Межстрочный интервал – 1,5
7. Абзацный отступ – 1,0

***Требования к иллюстративным материалам*:**

Фотоматериалы и рисунки (сканкопии) принимаются только качественные (в формате JPEG, объемом не менее 3,50 МБ).

Объем публикаций в пределах от 0,5 до 1,0 п. л. (20 000–40 000 знаков с пробелами). К публикациям прилагаются аннотации из 5–6 предложений, а также выделяются ключевые слова (4–5).

***Сведения об авторе:***

1. Фамилия, имя, отчество ____________________________
2. Ученая степень ____________________________________
3. Ученое звание _____________________________________
4. Занимаемая должность ______________________________
6. Почтовый адрес с индексом __________________________
7. Адрес электронной почты (e-mail) ____________________
8. Контактный телефон _______________________________

Редакция отмечает, что после получения статьи от автора и детального его изучения членами редколлегии она в случае соответствия всем требованиям передается в печать. Если материалы не соответствуют техническим и научным требованиям, статья возвращается автору с замечаниями для устранения недостатков. В связи с большим объемом поступающих материалов редколлегия может ограничиться пересылкой автору, в случае необходимости, соответствующих правил оформления для приведения ее в соответствие с требованиями.

Редколлегия оставляет за собой право размещения публикаций в журнале согласно рубрикаций и наличия мест в выпускаемых номерах. После выхода журнала авторы статей могут получить по одному экземпляру издания.

Авторам выплачивается гонорар. Для этого необходимо вместе с материалом прислать сканкопии паспорта, ИНН, СНИЛС, счет со всеми банковскими реквизитами.

Электронная версия журнала размещается на сайтах Всемирного конгресса татар и «Всетатарского общества краеведов».

Материалы следует присылать по эл.адресу: monitoring_vkt@mail.ru с указанием темы: «Для журнала «Туган җир/Родной край». Допускается и прямая передача публикаций в редакцию, но лишь в электронных версиях. Для этого указываем адрес нашего журнала: Казань, ул. А. Пушкина, 52, офис 303, редакция журнала «Туган җир/Родной край».

# Туган җир

*Төбәк тарихы буенча журнал*

# Родной край

*Краеведческий журнал*
2’2019

Подписано в печать 27.05.2019 г. Формат 70×100 1/16
Усл. печ. л. 19,5 Тираж 1000 экз.
Отпечатано с готового оригинал-макета.
в типографии ООО «Грумант»
В данном номере журнала использованы фотографии из личных архивов авторов



Крушиняны авылы (Польша) мәчете




Белосток  шәһәре (Польша) татарлары ТНВ журналисты
Л.Садретдинова белән




Язучы, тарих фәннәре кандидаты, җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова Самар ярымутравында




Самара шәһәрендә Сабантуй бәйрәме



«Яктылык» мәктәбе балалары (Самара)




«Яктылык» мәктәбенең этнография музеенда (Самара)



Самараның танылган «Ялкынлы яшьлек» ансамбле җитәкчесе –
Илгиз Колючев сабантуй аланында



Саратов шәһәрендә А. А. Хәбибуллинның «История татарского села
Верхазовка» китабын тәкъдим итү кичәсе



Казан шәһәрендәге 15-нче татар гимназиясе укучыларының семинар кысасында чыгышы



Сарабиккол авылында (Татарстан) фәнни-гамәли конференция



Тара шәһәрендә (Омск өлкәсе) фәнни-гамәли конференция



«Миргазиян» мәчетендә (Казан) ифтар

**921**-го году месяца (по татарски) Зулхитжа 23-го числа от Мухаммет Аминя Богодор хана честнейшим и во благоденство возраставшим родственником и честно воспитанным детям и в честь превознесенным даже до последнего веку всем мусулманским обладетелям и присудствующим чиновным и воинским и на одном месте пребывающим главным людям и редовым посланцом, куриером, судовым и пахотным людем, заставщиком, тамгачам и в царствующей Казане поселенным казну хранителям и от обид, вреда и бед защитителям оное объявляетца. Пожаловал Асылхожу Мизякова з детми ево Хасянем и Хусеином в тарханы и чтоб оным в отлучке в пути и где они будут жить как самим, так и людям и скоту ни в чем никому обид и утеснения чинить не касаться, ясаку с них и оброку и никаких мелких податей не требовать и насилством в домы не становиться и впредь их за знатнейших почитать.

*Тарханская грамота (в переводе на русский язык), выданная казанским ханом Мухамет-Амином предком Надыра Уразметова Асылхоже Мизякову и его сыновьям в 1516 году*